Забрали нас одновременно с моей племянницей Айшой (ее муж Наджиб Халфин был арестован одновременно с Газизом по одному делу). Итак, очутились мы с Айшой в одной тюрьме, в одной камере на 40 человек.

Все сокамерницы – жены ранее арестованных знатных людей города. Сидим молча. Тишина. Каждый думает о своем и никто не верит, что муж – враг народа. Айша молодец, не давала раскисать, лить слезы. Требовала следить за собой, не опускаться, причесываться, не падать духом.

Вскоре нам объявили приговор: меня на 5 лет, а Айшу на 8 лет лагерей. К сожалению, нас разлучили и мы разъехались по разным лагерям. Меня отправили в Карагандинские лагеря. Сначала повезли на грузовиках, затем на поезде с пересадками.

Сыновей своих я так и не увидела, не попрощалась с ними. О Газизе ничего не знаю.

Куда-то еду и еду, ничего не ведаю, не знаю. То слезы душат, то в каком-то забытье. Дни сменяются днями, жизнь бессмысленно тянется»

Все это эннэ рассказывает монотонно, бесстрастно, с потухшим взором.

Давно уже кончился наш ресторанный вечер. Все эти воспоминания, рассказанные в разные дни и часы, я с течением времени собрала воедино.

Итак, эннэ оказалась в лагерях казахстанской степи. Ни одного строения, ни одного жилья. Степь да степь кругом, да огромная луна. Вокруг такие же бедолаги, как и она, да охранники.

И никаких вестей ни о муже, ни о сыновьях.

Лагерная жизнь постепенно наладилась. Возвели своими руками ограду вокруг, в бараках установили нары, печки поставили и потекли безрадостные и бессмысленные дни.

Поскольку у эннэ были сердечно-сосудистые заболевания, ее поставили на легкие работы: убирать барак, топить печи и вязать варежки для фронтовиков. В том же бараке жили сестры Тухачевского, тихие скромные женщины, которые ни с кем не общались, держались особняком. Там же были жена и дочь брата Енукидзе. Работали пастухами, уходили ни свет, ни заря и возвращались поздно. Обе горемыки страдали сердечной недостаточностью, страшно опухали и вскоре умерли.

Прошло долгих лагерных пять лет. Эннэ вышла на свободу. Денег нет, одежда истлела, сыновья на фронте, о муже ничего не известно.

На руках лишь справка о том, что как жена изменника родины отбыла срок наказания и освобождена 15 октября 1942 года.

Шла Великая Отечественная война. Куда деваться с такой справкой?

От безысходности устроилась помогать по хозяйству в бедную многодетную казахскую семью. Хозяину-казаху батрачка приглянулась, и он предложил ей стать его второй женой (мусульманам разрешалось иметь две жены).

Эннэ рассказала ему о себе, о своем муже – знаменитом профессоре, о своей любви к нему и ожидании его до конца своих дней. Хозяин понял ее, больше этой темы не затрагивал. Жили бедно, впроголодь.

Иногда ночами эннэ выходила в поле, собирала там оставшиеся от прошлогоднего урожая зерна, варила на костре кашу и выла, выла, глядя на холодную луну, бесконечную степь и не видя конца своим мучениям, своему одиночеству.

Я живо представляю себе эту жуткую картину: лунная холодная ночь и одинокая сгорбленная фигура у костра.

Эта картина особенно ярко всплыла, когда прочла «Плаху» Чингиза Айтматова. Там тоже одинокая синеглазая красавица Акбара выла на луну, тоскуя по своим погибшим волчатам.

Для меня Акбара в некотором роде явилась прообразом эннэ. Злая судьба, злые люди не позволили обеим вкусить радости жизни. За что?!

С большим трудом эннэ перебралась в Казань, к сестре Зулейхе (мать Айши). В Казани жить не дозволено, поэтому поселилась под Казанью, в Юдино. Сняла хибарку с помощью сестры. Той тоже не легко, кое-как держится, дочь Айша все еще в лагерях. Так бедные сестры дотянули до конца войны.

Наконец вернулись с фронта сыновья. Освободилась и Айша.

Поселились все вместе в Козловке (Чувашия), где Айша работала ведущим акушером-гинекологом в больнице. Микаиль окончил 10-й класс и поступил в Казанский педагогический институт. И школу, и институт окончил с отличием. Он вообще был одаренный мальчик, много читал, был очень эрудирован. Вообще-то был ее любимцем, единственной радостью в жизни. Пока не появилась на свет его дочка – Гульнара. Вся ее любовь и радость сосредоточились на этой черноглазой очаровательной девочке – Гюлькяй, как ласково она ее величала. Все горести и беды эннэ забывала, видя как подрастает ее внученька. Первые ее шаги, первые слова приносили огромную радость и успокоение.

Когда много лет спустя мы уже жили вместе с эннэ в Баку, и на нее частенько нападала тоска и грусть, и слезы наворачивались, я придумала хитрый маневр: начинала расспрашивать ее о Гюлькяй (она с родителями тогда жила в Бугульме), слезы ее тут же высыхали, лицо светлело, и она могла часами рассказывать о внученьке, о ее детских шалостях и проказах. Что все-таки делает с человеком любовь?!

Как жаль, что она не увидела, как любимая внучка стала статной, красивой женщиной, выучилась на врача. У нее растет сын – Ильдар, уже студент Казанского химико-технологического института.

Не узнала она и о старшем своем внуке Эдуарде – сыне Сальмана, который стал крупным ученым, доктором философских наук, Академиком. Вот уж в ком она обнаружила бы гены своего Газиза ! Такой же одержимый, увлеченный ученый, такой же эрудит и трудоголик. Она гордилась бы своими внуками.

Не узнала она, что ее любимец Микаиль в одиночестве и больным закончил свою жизнь. К сожалению, трагическая судьба семьи отразилась больше всего на бедном Микаиле. Его нервная система, психика не выдержала испытаний. Он рас-стался

с семьей и последние годы проживал в Баку вместе с Айша апой, которая помнила наказ и просьбу Газиза и Рабиги в случае чего поддержать Микаиля и с честью выполнила их просьбу. Мы очень часто вспоминаем ее с благодарностью. Она вообще была уникальный человек. Я написала о ней статью «Айшэбез» в журнале «Соенбикэ» в 1991 году, но там нет той полноты, с которой хотелось бы о ней сказать. Недаром Гали Рахим посвятил ей свои сонеты, стихи и популярный романс «Кэккук».

Айша апа до конца своей жизни заботилась о больном Микаиле. Умерла она в 1979 году. Микаиль пережил ее на шесть лет.

В 1985 году Микаиль полетел на 80-летие Сальмана, но по пути внезапно скончался. Похоронили мы его в Казани, возле могил предков.

До конца своей жизни эннэ так и не узнала правду о своем Газизе.

Не узнала она, что его в октябре 1937 года расстреляли в застенках Бакинского НКВД. Может быть это и к лучшему?

Несмотря на свои страдания, эннэ ни словом, ни упреком не поминала власть. Никогда и никого не винила, не судила, а покорно воспринимала свою судьбу как рок, как богом данное испытание.

Однажды к эннэ пришла в гости такая же горемыка, с похожей судьбой Фатыма апа, вдова бывшего главного редактора газеты «Бакинский коммунист», тоже сгинувшего в 1937 году. Маленькая тихонькая старушка о чем-то пошепталась с эннэ, тихо поплакали вместе и разошлись. Через несколько дней после этого визита эннэ рассказала мне секрет этой маленькой старушки.

Будучи в лагерях, Фатыма апа родила сына. На свободе оставались двое ее старших детей. Фатыма апа, выйдя из лагерей, всем говорила, что ее мужа за примерное поведение и отличную работу отпустили на 10 дней в отпуск, который он провел вместе с ней, и в результате появился на свет ее третий ребенок. Эннэ при той встрече сказала ей, что позавидовала ей: провести с мужем 10 дней в те страшные годы – это невиданное счастье. Тут-то Фатыма апа и открыла ей свою тайну.

«Какой муж, какая встреча? Не было этого! Меня в лагере изнасиловали шесть охранников, в результате и появился сын. Эту легенду придумала я для своих детей. Они не знают правды, любят своего младшего брата, заботятся о нем».

Какая ужасная судьба? Какой злой смерч пронесся над судьбами этих несчастных женщин! И доживали они свой век без ро-

пота и упрека, смирившись со своим страшным прошлым, не смущая души своих детей.

Я благодарна судьбе, что встретила таких людей.

Такие маленькие и беззащитные, они мужественно несли свой крест, без нытья и жалоб, без жажды мести, не отравляя жизнь окружающих своими горестями.

Мне кажется, общаясь с ними, я стала другой, пересмотрела свои взгляды и моральные устои. По-моему, я стала лучше, чище, добрее. Встреча с такими, опаленными судьбой людьми и есть то самое главное и значительное, что произошло в моей судьбе.

Спасибо им!

Москва. Март 2001 г.

Газиз Гобәйдуллинның фәнни хезмәтләре

Научные труды Газиза Губайдуллина

«Сәед Баттал газый» хикәясе тугърысында

Хәтереңездәдер, төннең озын вакытларында безнең татар авылларында, калаларда, мастерскойларда эштән бушагач, кичатна көннәрендә, яшьләр җыелып, хикәятләр сөйләшәләр яисә сугыш вә гыйшык китаплары укып, вакытны хозур-хозур кичерәләр.

Бу китапларны безнең халкымыз милли булган «Бәдәвам», «Тәкый гаҗәп», «Йосыф» китаплары шикелле үк ярата.

Мин үзем дә кечкенә чагымда шул китапларны укыганны бик тыңлаучы һәм аңлаганнарны кычкырып укучы идем; шул заманда ук мин бу китапларны ярата, аларга бер әллә нинди якынлык хис итә идем. Заманнар үтте, мин тагы бу китапларны берән-берән алып укый башладым.

Миңа хәзер бу китапларда яңа бер галәм ачылган күк күренде. Әүвәлге миңа бары хыялый әһәмиятләре генә булган Сәед Баттал, Гали, Малик, Әждар, Сәгыд ибне Вәкъкас, Халид ибне Вәлидләрем хәзер миңа бөтенләй башка кешеләргә әйләнделәр. Хәзер алар миңа югалган чын милли каһарманнарның күләгәләре, аларның рухлары берлә рухланган гарәпләр күк тоела башладылар. Ул каһарманнарның характерларында мин чын милли каһарманнарымызның сурәтләрен күрә башладым. Шуңарга күрә дә бу китапларны тәнкыйтькә, аларны халкыбыз күз алдына яңадан менгезергә бер башлангыч булсын дип, «Сәед Баттал газый» хикәясе тугърысында бер нәрсә караларга карар бирдем.

Укучылар! Бу китапларны без үзебез онытсак та, Европа голямасы онытмады; алар тугърысында җилдләрчә китаплар яздылар. Мәсәлән, шул ук «Сәед Баттал газый» хикәясе тугърысында 1848 елда ук профессор *Fleisch* Саксония академиясенең бер нәшре әфкярендә озын-озын моталәгалар язган иде; шуның соңында, 20-25 еллар үткәч, аның шәкерте *Dr. Herman Ethe* исемле, Мюнхен дарелфөнуненең мөгаллимнәреннән бер немец бу китапны ике җилдкә бүлеп, үз теленә тәрҗемә итте. Тәрҗемә «тәнкыйтьле», ягъни күп бер-берсенә охшамаган җирләр булган нөсхәләрдән карап тәрҗемә ителгәнлектән, безнең өчен бик ка-

дерле әсәрдер. Шуның өстенә артындагы примечаниеләрен һәм әсәр тугрысында гомуми бер мөляхазә бәйан иткән мокаддимәсен алсак, әсәрнең кыйммәте тагын да арта.

Һәрничек әсәр иске төрек телендә булса да, белүемә күрә, төрекләр әсәргә һич игътибарларын салмадылар. Хәтта Шәмсетдин Сами бәк үзенең «Камусел-әгълям»ендә «Сәед Баттал газый» нам затның тарихи зат булганлыгын сөйләгәндә дә, шул зат тугрысындагы хикәя тугрысында бер сүз дә әйтми диярлек. Алда: «доктор *Ethe* төрле нөсхәләр таба» дигән идек, шул нөсхәләрне бәйан итеп китүне файдадан хали булмас дип уйлыйм.

Ethe алтыга якын бер-берсенә аз охшаган нөсхә таба. Дрезденда король китапханәсендә, Лейпцигта шәһәр китапханәсендә, Венадагы нөсхәләр, нинаять, профессор *Fleisch* ка татарларга бик мәгълүм булган әүвәлге Казан дарелфөнуне профессорларыннан Готвальд һәдия кылган татарча кулъязма нөсхә. *Ethe* соңгысына бик зур әһәмият биргәнен бәйан итә.

Мин файдаланган нөсхә исә һиҗри 1294 елда Истанбулда көрд Хөсәен әфәнденең матбагасында басылган китап. Татарча иске китапчы Шәмси тарафыннан басылган нөсхәне карасам да, шул төрек басмасының гайне булганлыгын белгәч, әһәмият бирмәдем.

Ethe ның язуына күрә, «Сәед Баттал газый» хикәясе XIV–XV гасры миладида халык телендә йөри торган яңа гарәп легендаларыннан җыелган әсәр. Китапның үзендә кем җыйганы тугрысында бер төрле киная генә дә табар хәл юк. Шул ук галимнең әйтүенә караганда, җыючы төрле заманга мәнсуб вакыйга һәм затларны бер җиргә җыйган; һәм бу вакыйганы *Ethe* халык әдәбиятының һәркаюсына махсус дип таба. Фәкать халык әдәбиятыннан икәнен әйткәндә, *Ethe* җәнабләре бер дә дәлилләр китерми. Шуңа күрә, мин үз тарафымнан исбат итәргә тырышмакчы булам.

Әсәрнең 86 нчы битендә 2 нче китапның башында шундый ике мисраглы бәет очрый:

«Җәмегъ идәнләр кыйссаның һәнкямәсен
Бөйлә димешләр хикәятнамәсен».

Менә бу сүздән туп-тугры «хикәятне җәмегъ иткәннәре», әмма бер кеше әсәре булмаганы күренеп тора. Дәхи дә әсәрнең «җәмегъ ителгәнен» кыйссаның эчендә, халык әдәбиятының «хасса»сында булган тәкрәрләр дә күрсәтеп торалар. «Кан илә чокырлар тулды», «кан сил күк акты», «бер нәгърә орды ки, сандылар сәбгы сәмәват бер-беренә тукынды», кайсарның сөенгәнен тасвир иткәндә «таҗын һавайа атты, кинә тотты» мисаллы тәкрәрләрне һәр сәхифәдә очратырга мөмкин.

Татар-кыргыз хикәятләрендәге күк, «Шаһнамә»дә Рөстәмнең диюне үтергәндәге күк, Сәед Батталның диюне күзен чыгарып үтерүе дә халык әдәбиятыннан булуын күрсәтә. Хәтта руслар былиналарында да Соловей Разбойникны (бу җанварны тасвир диюне тасвирга бик охшаштыр) Илья Муромец ук белән күзен чыгарып үтерә.

50, 70 цифрларын һәр җирдә истигъмале дә халык әдәбиятына махсус нокталарның бередер. Мәсәлән, «яһүди йитмеш елдыр тиҗарәт идәрем» ди, күп вакыт гаскәр 70 мең була, я 50 мең була. Шул дәлилләрне мин кыйссаның халык хикәясе,бер кешенең генә башыннан чыккан хикәя түгел дип әйтергә юл табам.

Китапны укып чыккан кешеләрнең хәтерләрендәдер: хикәянең каһарманы Сәед Баттал исемле, пәйгамбәр вә хәзрәти Гали нәселеннән килгән бер батыр. Без хәзер бу каһарманның тарихи затмы; әгәр алай булса, кайсы гасыр кешесе, кайсы милләттән икәне бәхәсенә киләбез.

Алда әйткән Шәмсетдин Сами бәк «Сәед Баттал»ны мөселман сугыш каһарманнарыннан берсе, 121 нче һиҗридә румнарга каршы булган сугышта үтерелгән, Ходавәндкяр вилайәтенең Искешәһәр касабасында «Сәед газый» кабере бар, имеш. Сәлҗук падишаһларыннан солтан Галәведдиннең анасы тарафыннан төрбә бина ителгән, төрек солтаннары тарафыннан мәсҗед вә тәкияләр бина ителгән, имеш һәм шәһәрнең исеме дә әүвәлдә Наколия булса да, хәзер «Сәед газый» дип йөртәләр, дип әйтеп китә. Шәмсетдин Сами бәк Сәед Баттал газыйны (622+121=743) VIII нче гасырның урталарында булган кеше итеп китереп чыгара.

Ләкин китапның үзеннән дә кай вакыттагы кеше икәнен бераз белергә була. Мәсәлән, пәйгамбәр заманасыннан килгән Габделваһаб исемле сахабә бер урында, гомерем 300 елдан артык булды, ди (300+622=922). Бу хәбәр буенча Сәед Баттал газый X гасыр кешесе, я IX нчы гасыр башындагы кеше була.

Китапта Сәед Батталның шактый гомер иткәч, Бәхтияр исемле падишаһ барлыгын сөйләнә. Бәхтияр исә «Камусел-әгълям»нең бәйанына күрә 356 һиҗридә падишаһлык сөргән кеше, бу хәбәр тагы X гасырны куәтли. Китапның бер җирендә хәлифәнең Кайсарга каршы кәмал газимәт белә килгәнен тасвир иткәндә Хәрәзем егетләре тугърысында сүзләр чыга: алар ук аталар, уклар белән хәлифәне саклыйлар. Бу Хәрәзем егетләре габбасилар заманында гарәп хәлифәләренә ялланып хезмәт иткән төрек гаскәре булырга кирәк. Мөәррих Леон Кагинның язуына күрә, төрек егетләре хәлифәләрдә IX гасырның ахырында хезмәт итә башладылар. Менә бу да X гасырны куәтлидер.

Хикәянең ахырында Сәед Батталның ялган пәйгамбәр Бабик белән сугышканын сөйли. А.Мюллерның «Тарихе ислам»ында әйткәненә күрә, Бабик Мәәмүн хәлифә заманында (240–819) елдан алып һәрвакытта каршы сугышып торсалар да, җиңә алмадылар. Бары 218–833 елларда гына Бабик һәм тарафдарлары җиңелгәннәр иде. Менә бу хәбәр исә Сәед Батталның IX гасырда булганлыгын белдерә.

Сәед Баттал төрекме йә гарәпме мәсьәләсе килеп чыга. Төрек дип әйтүе бик уңайсыз, чөнки X гасырда Малатия тирәсендә төрекләр урнашып җитүләре шөбһәле. Чөнки иң элек сәлҗук төрекләре Анатолиягә килеп чыгалар XI нче гасырда. Әмма сәлҗукләрдән элек килеп, башта гарәп хәлифәләрендә хезмәт итеп тә, ахырдан хәлифә тарафыннан бүләк итеп Малатия шәһәрен алган төрекләрдән булса, төрек булуы да бик ихтимал.

Хикәядә Сәед Баттал, төрек халкының «яхшылык»ка ул вакытта каравы ничек, шундый характерлар илә зиннәтләп тасвир ителгән. Билгеле, һәр халык әдәбиятындагы каһарман шул ук вакытта халыкның «вөҗданын, рухын» күрсәтә. Шуңа күрә Сәед Батталның характерындагы хосусый нокталарны бераз күреп китү файдадан хали булмас.

Аның анасына хөрмәте бик зур; сугыш алдыннан аның догасын ала. Сәед Баттал динле, тәкъвалыгы белән бөтен дөньяга мәшһүр. Хәтта 13 яшендә вакытта ук аны вәгазь сөйләргә хатыйб итеп, мөдәррис тәгаен итәләр. Ул христиан йә мәҗүс кызына никадәр гашыйк булса да, мөселман булмыйча (пакь булмыйча), янына да бармый. Аның фәкыйрь дәрвишлеге хәттин ашкан. Балаларының хәлфәләренә һәдия сәдака итәргә бер нәрсәсе юк: өстеннән чикмәнен салып бирә. Ул сугышта калган ганимәт малның һәммәсен дә фәкыйрьләргә, толларга өләшә.

Һәр сугыш кешесе күк, безнең каһарман да үзсүзле, каты күңелле. Ул үтерәм дигән кешесен Каф тагына барып булса да үтерә. Бөтен гомере кяфер үтерү белән уза. Ул кяфердән килгән посолларның колак вә борыннарын кисеп, иза вә җәфа кылырга куәте җитә.

Сәед Баттал бик гашыйкчан: күзе төшсә, сөя, хәзер өйләнә. Әмма үзе хатыннарын карый алмый. Хәтта бер хатын, бер тиене юк, җылынырга өе юк, кая барса, шунда өйләнә, ләкин хатыннарының күбесе аны үзләре димләп өйләндерәләр. Чөнки, Әмбәр Гомәрнең Сәед Батталга барасы килгән кызы әйтмешли, «Аның һәрбер ... лязем».

Шуларның барысының да өстенә Сәед Баттал бик хәйләкәр. Менә бу табигате дә Шәрекъ Шәвәлисен гаребнекеннән аера, аерым бер табигатенә Шәрекъ аһәңе бирә.

Сәед Батталны кыйсса заманасының иң галим кешесе итеп тасвир кыла. Ул анда әйткәнчә бик галим, христианнарны үз диннәренчә вәгазь кылып шаккаттыра. 70 төрле тел белә, «хвоячка» белә: ягъни, үз-үзен кешегә күрсәтми торган, үлгәч терелә торган догалар белә, шуңа мондый кешенең фикерен белү бик әһәмиятле. Аның бөтен тормыштан максаты да Румны мөселман итеп, Истанбулны харап итеп, кәлисәләрен егып, җиренә мәсҗед вә мәдрәсә салу. Менә шул җөмлә Сәед Батталның девизы диярга ярый. Картайгач «моңарчы нәрсәләр эшләдем, һәммәсе Алла ризасы өчен иде, инде ахирәткә хәзерләнергә кирәк», ди.

Әгәр Сәед Баттал китабының теленә күчсәк, *Ethe* нең сүзенә ышанырга кирәк була. Аның фикеренчә, хикәянең теле фарсы, гарәби һәм татар шивәсе катышкан госманлыларның борынгы телләре. Мәсәлән: «ваз кичтем» урынына иске «ваз кылдым» истигъмаль ителгән хикәянең җыючысы гарәп, фарсы сүзләрен дә күп урында бары матурлык өчен генә истигъмале күренеп тора. Хикәя бер җирдә «йир, күк бер-беренә тукынды» җөмләсен истигъмаль итсә, икенче урында матурлык өченме «сәбгы сәмәват бер-беренә тукынды» ди.

Ethe хикәянең стиле тугърысында: «*Der stillist der einfuchlte gon west* (стиль дөньяда иң садә стильләрдән берсе)» ди.

Бу хикәяттә иң кызык мәсьәлә – кеше исемнәре. Мәсәлән, грек кызларының исемнәре: «Маһипәрваз», «Диләфрүз». Ир кеше исемнәре дә күбесе фарсы-гарәп исемнәре. Җыючының юнан тормышыннан ерак торганы күренеп тора.

Хикәя ике төрле галәм таный: христиан (гомумән, кяфер) дөньясы, аның башында кайсары руми тора; мөселман дөньясы, башында «җир йөзенең хәлифәсе» тора.

Бу китапта тарих өчен дә шактый гына фактлар табарга мөмкин: кайсар «франк» (франк, славян, герман) халыклары князьләренең хезмәтләре хәлифәләр янында Хәрәзем егетләре, әһле салиб сугышларының хатирәсе, Бабик вакыйгасы.

Әһле салиб вакыйгасы бик сыек буяулар белән тасвир ителгән. Сугышларда бер дә чын бу мохарәбәләрдә булган каһарман юк. Христианнар һәм мөселманнар ягыннан җыелган гаскәрләрнең килгән җирләрен санаганда да чын, җир йөзендә бар вилайәт, мәмләкәтләрдән башка, хыялый мәмләкәтләр исемнәре бик күп. Бу вакыйганы ямьсез, кыска тасвир, хикәянең җыелган вакытының әһле салиб сугышларыннан күп соң булганлыгы күрсәтә. Хикәянең рухына фарсый легенда вә әдәбияты шактый гына тәэсир иткән.

Без монда «Шаһнамә»дәге диюләр, Җәмшид падишаһ җырларын, Дихәк исемнәрен, Фридон исемнәрен очратабыз.

Ethe нең әйтүенә күрә, хикәят, христиан динендә утка табына торган фарсылар дине белән саташтыра. Кяферләрнең «Нарнур»га табынганлыгын, аның наме белән ант итүләрен хикәят күп җирдә сөйли. Хәтта Хәсән, Хөсәен, Галине мактаганлыктан, алар тугърысында «Кәрәме Аллаһы вәҗһиһи» диюләрен Әбүбәкер тугърысында «Р.З.» дип тә әйтмәвен хисапка алсак, җыючы шыйга булуына да ышана башларлык. Әгәр аның өстенә Йәзидне сүгүләрне искә төшерсәк, бу фикер тагы да куәтләнә.

«Әлфе ләйлә вә ләйлә»нең дә, я аннан алып сөйләнгән хикәяләрнең дә хикәяткә тәәсире күп. Сәед Баттал белән җылан падишаһысы «Шаһмәран» кыйссасы, бөтенләә «Әлфе ләйлә»не хәтергә төшерә.

«Һарут вә Марут» исемле кяферләр белән сугышуы да бәйбал хорафатының тәәсирен күрсәтә.

Халык әдәбиятының һәркаюсына махсус булган сравнениеләр хикәядә бик күп. Матур-матур шагыйранә тасвирлар да очрыйлар: мәсәлән, әһле салиб сугышларын тасвир кылганда хәлифәне тасвир кылуын гына карагыз! Укучыны бөтенләә шул заманга кайтара, сине шул сугышларда сугышырга мәҗбүр итә.

(«Шура».– 1911.– №22.– Б. 682-685).

җилд – том
нәшре әфкяр – газета яки журнал
моталәга – бәхәс, фикер
дарелфөнун – университет
мөляхазә – фикерләү
мокаддимә – кереш
хали – башка, тыш
гайне – үзе
мәнсүб – нисбәтле
җәмегъ итү – туплау, җыйнау
дәхи – тагын
хасса – хасият
нәгърә ору – кычкыру
сәбгы сәмәват – җиде кат күк
истигъмаль – куллану
тиҗарәт – сәүдә
касаба – кечкенә шәһәр
кәмал газимәт – тулы җиңү
мөәррих – тарихчы
лязем – тиеш, зарур
әһле салиб – тәре йөртүчеләр
мөхарәбә – сугыш

Умирает ли нация?

С самого начала прогрессивного движения тюрко-татар России вопрос об исчезновении нации волновал образованную молодежь. С выходом в свет произведения Гаяза эфенди Исхаки «Исчезновение через двести лет» сомнения по поводу дальнейшей жизни нации вновь усилились. Любая негативная черта в развитии нашей нации вселяла боязнь: «исчезаем!». Но каждый шаг вперед отбрасывает эти сомнения, снова перед нами восходит солнце надежды, его лучи ощутимо согревают и радуют наши сердца. Однако вопрос остается и ответ на него требует глубокого анализа.

Действительно, исчезают ли нации?

Чтобы ответить на вопрос, надо обстоятельно разобраться в нем. Во-первых, разделим вопрос на две части и ответим на каждую из них в отдельности.

1. Если со временем люди перестанут делиться на нации, народ, объединенный в образование под названием «нация», исчезнет, люди будут разниться между собой как-то иначе или нет?

2. Может ли погибнуть отдельно взятая нация?

Сначала ответим на первый вопрос.

Уже более шести-семи тысяч лет цивилизации история человечества развивается в рамках различных, но определенных культур. Если посмотреть на историю развития за прошедшие века, то увидим начало образования той или иной нации, ее дальнейшее формирование, наибольший подъем, затем постепенный спад, превращение в угнетенную нацию, наконец полный уход со страниц истории и вновь рождение под прежним или новым названием. Вообще, как свидетельствует история человечества, нации рождаются, растут, борются между собой, рождают свою культуру или же заимствуют, обновляют ее по-своему, прививают другим. Все формы борьбы, общественных отношений, все вращается внутри нации. Нации олицетворяют человеческую историю. Как вода вне сосуда высыхает, исчезает, так и история без жизни крупных человеческих коллективов не существует. Как нет истины вне времени и пространства, по ут-

верждению Канта, так без наций нельзя изучать человеческую историю. Нация нужна для познания общественной и индивидуальной жизни человека. С древних времен вся история жизни отдельных людей – вавилонян, шумеров, финикийцев, древних римлян и греков, немцев, русских, китайцев и тюрко-татар развивалась внутри наций. Если бы не было наций, то не было бы истории, как предмета изучения.

По законам всеобщей истории люди, выйдя из стадного состояния животных, поднимаются до уровня родов, затем племен и далее до стадии наций. Только тогда начинается жизнь общества. До этого времени смысл жизни людей, как и животных, состоит из приема пищи, борьбы между собой, стихийного размножения, воспитания потомства.

Если мы хотим познать какого-либо человека, мы должны изучить его духовную и творческую жизнь, а также знать его нацию. Чтобы глубже познать духовный мир исторически известной личности или знаменитого современника, необходимо знать его принадлежность к той или иной нации, изучить пути развития этой нации, ее устремления, цели, исторические черты.

Мы не могли бы понять философию Аристотеля, не принимая во внимание его принадлежность к древним грекам. Его труд «Политика», написанный с монархическим уклоном, противоречил бы его стремлению поддержать Александра Македонского – представителя той же греческой цивилизации.

Таким образом, если нация является единственным путем познания жизни общества и конкретного человека, если человечество уже по меньшей мере в течение 6-7 тысяч лет развивается по нациям, создающим каждая свою культуру, а всеобщая культура стала культурой многих наций, то ни в коем случае народы не прекратят деления на нации и жизнь «вне наций» невозможна. Когда говорят, что в будущем все человечество будет единым, что с разделением на нации должно быть покончено, что из-за наций возникают войны, из-за наций богатые эксплуатируют бедных, то в большинстве случаев желаемое выдается за действительное.

Хотя все эти пожелания могли бы быть естественными и весьма сознательными, однако уничтожить нации невозможно, они будут жить вечно. Космополитическая идея жизни людей без наций зародилась более трех тысяч лет тому назад. Ее провозглашают, начиная от греческих философов до современных ученых. Конечно, мы многого хотим, но природа сильнее нас! Трагедия в том, что мы много хотели бы, но не можем...

Спрашивается, причем природа в вопросе исчезновения нации? К сожалению, дело именно в природе...

Мудрая природа сотворила различные виды животного и растительного мира, в свою очередь сотворила и бесчисленное число представителей человечества, которое разделилось на большое количество родов. Эти роды разнились между собой по биологическим признакам.

Известно, что между духом человека и его телом существует связь. Всякому строению тела соответствует его дух. Не будем останавливаться на этом, поскольку тому есть объяснение в простых законах психологии. Поэтому распространившиеся по всем уголкам мира многочисленные племена рода человеческого создали свои, только им присущие духовные миры. Однако, разделенные на многочисленные племена люди не смогли жить только внутри своих племен. Видимо потому, что человек является «стадным животным» или, выражаясь литературно, общественным. С другой стороны, существующая постоянная борьба племен друг с другом заставляла их объединяться. Терпя поражения и побеждая, племена объединялись. Объединения повлекли за собой межплеменные браки и рождению от них детей. Дети от таких браков были несколько иными, чем дети исходных племен. Наконец, от смешения двух или нескольких племен получились совершенно новые племена, затем вторые, третьи, четвертые и так без конца. В этих новых племенах рождалась сначала в неразвитой форме культура, с примитивной формы развивался язык, появлялись свои герои, о них стали складывать легенды, песни, сказки и утверждались свои традиции. Новые племена, обживая свои территории, приспособились к природным и экономическим условиям тех мест. Рождалась привязанность друг к другу, а также привязанность к местам проживания. Наконец, отдельные племена создавали свои государства, которые подчиняли себе более слабые формирования или сами подчинялись более сильным. Началось и противостояние: одни стремились занять главенствующее положение, а другие боролись с этим. Так образовались нации и началась борьба между ними.

Из вышесказанного видим, что вначале, естественно, возникли племена, объединившись друг с другом, они образовывали нации. Известно, что в природе каждый борется за существование. Это характерно для каждого вида растений и, вообще, живых организмов. Также и нация, являясь продуктом природы, борется за существование. Эта борьба выражается в двух формах: бессознательно и вполне осознанно. Бессознательная борьба ведется со всеми внешними влияниями. Каждая нация считает свои пес-

ни более красивыми, более близкими. Более привлекательным кажется ей свой типичный облик и характер. Унаследованный от предков язык легче передается наследникам. Если представители какой-либо нации обидят или оскорбят другую нацию, то представители оскорбленной нации воспринимают оскорбление как личную обиду, у них рождается мысль об отмщении. При этом каждый представитель обиженной нации забывает о себе, готов жертвовать собой за свою нацию. Все это бессознательные формы борьбы за сохранение нации.

Природа сохраняет нацию от ее кончины еще одним путем. Почувствовав признаки отмирания своей нации, отдельные ее представители начинают бороться с этим и принимают меры для дальнейшего развития и процветания нации. Поднимаются национальное искусство, литература, театр, музыка, что пробуждает национальный дух. Так природа усиливает противостояние кончине нации. Итак, законы природы, направленные на сохранение наций, не позволяют согласиться с мыслью об отмирании наций и превращения человечества в конечном счете в одну нацию. Это, может быть, и высокая идея, но она фантастична, трудно представить себе, чтобы она могла воплотиться в жизнь. История развития человечества подтверждает не исчезновение института наций, а сохранение его и дальнейшее развитие. Мы явились свидетелями, что одной из причин войн XX века являлась межнациональная борьба. Этот принцип сохранится и впредь, и ничто и никто вопреки истории не изменит такое движение. Природа определила направление движение Волги с запада на восток, и Волга не может изменить свое движение, как бы мы этого хотели. Также и природа, создавшая людей и разделившая их на нации, не может изменить свои законы лишь по нашему желанию!

Умозаключения о том, что наука, знания, культура приведут к единой, объединенной нации, недостаточно верны. Культуру создают нации. До сего времени созданной всеми нациями единой культуры в мире нет, поэтому каждая культура имеет свое лицо – французское, английское, арабское. Мировая культура – сумма национальных культур. Даже единые для всего человечества наука и знания не могут сплотить нации воедино.

Познание природы, науки с древнейших времен у народов происходило, в целом, одинаково, но несмотря на это, исторически не сложилась же единая нация! К тому же и науки можно считать частично национальными. Астрономия вавилонян создавалась на базе национальной культуры древней Вавилонии. Идеализм германцев, позитивизм французов вытекал из их фило-

софского мышления. Поэтому естественная мысль, основанная на природной логике, не дает основания для создания единого человечества.

Короче говоря, из вышесказанного ясно, что разделение людей на нации никогда не кончится, попытка мыслить по-другому противоречит природе, разные предположения и идеи в этом направлении – чистый идеализм, чистая фантазия. Слова о единой, всемирной нации пусты, они обречены, как мыльные пузыри.

Карл Великий со своими приближенными, не считаясь с волей народов, собрав воедино народы разрушенной Римской империи, создали единое христианское государство. У них не было ни римлян, ни французов, ни немцев. Чем же все это кончилось? Еще до конца эпохи Карла его потомки раскололи страны по национальному признаку на три совершенно разные государства. Так мучительно началось образование итальянской, французской, германской наций, сформировавших каждая свое государство со своими землями...

В истории много убедительных примеров подобного. Читателю полезно было открыть страницы всеобщей истории и убедиться в этом.

Далее постараемся ответить на второй вопрос.

Если в мире не конечен институт наций, то могут ли исчезнуть отдельные из них?

Ответ на вопрос прост. Теоретически нация представляет собой нечто подобное виду в природе. По закону природы выживают лишь наиболее сильные виды, способные победить в борьбе. Слабые же, не способные выжить в борьбе, не приспособленные к жизни виды, могут не выжить. Их побеждают другие, они исчезают. Также и нации. Если нация не устоит в борьбе за существование, она исчезает. Не сумевшая приспособиться к жизни нация терпит поражение в борьбе с другими и исчезает. В истории таких примеров множество.

Однако старый мир, несмотря на вечную межнациональную борьбу, исчезновение отдельных наций, развивается своим путем, продолжая делиться на разные нации.

И в этой борьбе выживают более удачливые, способные, развитые нации!

(Журнал «Анг».– 1917.– № 11/12.– С.164-167.
Перевод с татарского С.Г.Губайдуллина).

Инде ни булачак?

Тарих бик карт. Аның сакаллары инде бәшәриятнең үзенеке кеби агарган. Тарихның бер нәрсәгә дә исе китми. Хиффәт адәмнәрнең дөньяда җәннәт ясарга йөрүләре, киләчәктә әллә ниткән хозур, мәсгудь иҗтимагый тормыш көтүчеләргә ул бары көлеп кенә карый. Ул андый нәзариятпәрвәр һәм хыялый тормыш ясарга омтылучыларга үзенең җыерылып беткән карт куллары белә артка төртеп күрсәтә:

– Әнә караңыз! – ди ул. – Бәшәрият нинди юл белән киткән булса, сез дә киләчәктә шул юл белән китәчәксез, – ди.

Карт тарихның алдагыны белә торган метод вә ысуллары бик садә, ул үзенең йөзендә чиккән вә төрле михнәтләрдән ясалган җыерчыкларын гына көзгедән карый да, мәдәни инсаннарга да шул җыерчыкларны ингыйкяс иттергән калын сәхифәләре васитасы белән күрсәтә. Тарих иҗтимагый сахирләрне яратмый. Аның кашында инсаниятнең киләчәктә яисә кеше куллары белән сонгый рәвештә ясалачак сихри-матур сәяси-иҗтимагый тормышны үзенең көзгесе булган мәнбәгъ, таш вә китаплар сәхифәсенә яздырса да, адәмнәрнең «җикеренү», «котырулары-ның» никадәр көлке, никадәр төссез икәнлеген күрсәтү өчен генә яздыра.

Әлләниткән дәүләт төзү әсасында язылган Әфләтун, Африканский Августинның әсәрләрен ул безнең заманга кадәр саклап калдыра, безгә гыйбрәт өчен, безгә шуларның берсенең дә фәгалиятькә чыкмаганлыгын күрсәтү өчен генә саклый... Марксизм, анархизм кеби хәзерге гомуми табигыя вә биология кеби фәлсәфи ноктаи нәзардан социологиянең әсасларына бина бер генә төрле дә әсаслана алмаган «точный» гыйлемнәргә әсасландырган булып, черек фундаментка салынган аксиомаларга терәлеп эшләнгән тарикатьләргә карт тарихның исе китми. Аның архивында мондый тарикатьләр бик күп. Мондый тарикатьләрне тарих мөнбит Нил буе өлкәсе Мисырда да күргән, Юнанстанның матур күге астында хыялланып йөргән философ, софистлардан да ишеткән, Янсукианг буендагы Кытайда Тангуцидан да тыңлаган, әссе Һинд илендәге Буддалардан да мондый фәлсәфәләрне

сөйләткән. Карт бәшәриятнең ак сакаллы тарихы, адәм баласының иҗтимагый хәятен бәхет оҗмахына илтеп чыгарып, андагы рәфаһият бишегендә тирбәтү юлларын күрсәтүчеләргә бары көлеп кенә карап килгән.

«Ни булачак?» дигән сөальне тарихның саргаеп беткән битләренә мөрәҗәгать итеп, һаман да сораганнар һәм сорыйлар...

Тарих исә, адәмнәр кеби ашыкмый, кызмый, кайгырмый, җыламый, сынатмый гына: «Моңарчы ни булган булса, нинди бәлаләр, каза вә рәхәт, бәхетләр башыңыздан үткәргән булсаңыз, шуны күрәчәксез... Шуннан башка, яңа нәрсәне, шуларны китереп чыгарган корыч кеби каты кануннардан башка нәрсә сезгә бирелмәгән!» – дип куя.

– Бәшәрият бервакыт та мәсгудь булачак түгелмени? – дигән сөальне адәм балалары тарихка ашыгып-ашыгып бирә башлыйлар, тарих-философ аларга да садә генә җавап бирә:

– Мин дөньяга ничә миллиард адәм баласы килеп киткәнне күрдем. Һәм хәзер дә, дөньяда әллә никадәр адәм балалары яшиләр; һәммәсенең күңелендә мәсгудиять эзләү, рәхәт өмиде, хозурлык көтү... Ләкин боларның сәгадәт вә бәхеткә карашлары шулкадәр төрле-төрле ки, аларның сәгадәтләре фәгалияткә чыгарылачак булса, дөнья бер «хаос» белән тулачак, вакытыннан элек кыямәт кубачак.

Без гакыл, ихтыярән чикләнгән адәм угъланнары бу сүзләрне «иске сүз» димез дә, яңа сүз, яңа фикер эзләп, шул картка яңадан мөрәҗәгать итәмез; бу мөрәҗәгатемез тагы да садәрәк була:

– Соң нинди ысуле идарә булса, яхшы булыр соң? – дип сорыймыз.

Карт тарих үткәндә бәхет эзләп туйган Арасту авазы белән:

– Без ачык итеп белергә тиешлемез ки, һәрбер кешегә үзенең эшендә иң яхшы тауранырга вә бәхетле яшәргә мөсагадә итә торган хөкүмәт ясалу – иң яхшы ысуле идарәдер!* – ди.

Без бу сүзләрне үземез дә беләмез, үземез дә шуны эзлимез. Ләкин һаман да җавап бирә алмыйбыз, сөалемезгә яңадан сөальләр бирергә башлыймыз; нинаять тарихның тузган, тузанлы сәхифәләрен актара торгач, шундый җавап табамыз:

– Бер-бер халык яисә төрле халыклар, милләтләр төркеме шул мәгълүм бер заманда мәгълүм бер дәрәҗәдәге мәдәниятта вә мәгълүм бер гамилләрнең тәэсире белән нинди нәүгъ, нинди форма идарә төзи ала, шундый идарә ясалачак!

Безнең күңелемез шуның соңында гына бераз юана; шуның соңында гына без җүнләп әйләнеп, мохитымызны тикшерә баш-

* Арастуның «Политика» китабы. – Г.Г.

лыймыз... Менә шуннан соң безнең хыялларымыз чүлләрдә күренгән сагым (мираж) кебек, ераклаша башлый; инде без мәсьәләгә җитдирәк карый башлыймыз.

Тарих бабайның кинематографы безгә кыйсьмән куәт вә золым, кыйсьмән халыкларының үз теләүләре белән ясалган бөек дәүләтләрнең манзараларын ачып күрсәтә. Бу дәүләтләр тарих каршында «Әлфе ләйлә вә ләйлә»дәге Синдибар шәһәре алдында диңгездән табылган бер кечек савыттан башта төтен булып чыгып күтәрелеп, башы һавага тигән гыйфритләр кеби тиз генә зурайганлыкларын күрсәтә; шул ук дәүләтләр икътисади, горфи, милли, мәдәни вә табигый гамилләрнең тәэсирләре астында Әбүгалисинаның кабак эченнән чыккан бөек урдусы әфсен укыгач, шул кабак эченә кереп киткән кеби, шиңеп, бер учка сыярлык бер дәүләт булып киткәнлеген яисә тузан булып очканлыгын күрәмез. Иранда зоһур итеп, борынгы Шәрекънең бөтен мәдәният галәмен кулына керткән ахиминид шаһларының дәүләтләре Искәндәр Македониның кылычы орылгач та, тузан булып очып киткәнлеген; шуннан Искәндәр дәүләте вәҗүдкә килгәнлеген; аның хәдүдләренең Хәбәшстан, Һинд елгасы вә хәзерге Дунай буйларына кадәр килеп җитеп тә, үзеннән соң кырыкка бүленүен күрәмез. Соңра Искәндәрнең варисы – Руманың ул заман мәдәният галәмен кул астына керткәнлеген, соңра төрле сәбәпләр белән 7-8 гасырдан соң югалганлыгын, аның урынына җитмеш вак дәүләт килеп чыгуын, бөтен Яурупа галәме миладтан соң 800 елда бөек Шарльманның дәүләте эченә керүен, Шарльманнан соң ук бу дәүләтнең тагы җимерелеп, итальян, француз, герман милләтләреннән мөрәккәб вак падишаһлыклар чыкканлыгын күрәмез.

Өммәвиләр вә габбасыйлар заманасында хилафәт никадәр зурайган иде, ул да ничә гасырлардан соң таралды. Ниһаять, бөек төрек-татар ханлыгы Британия империясеннән яисә әүвәлге бөек Русиядән 3 мәртәбә зур, егерме сигез миллион мөрәббәгъ километр җир алып, дөньяның яртысына баш булган иде. Ул да бетте, таралды. Шул бөек дәүләтне ясаучы без бөтенләй югалып, «Болак аръягы җөмһүрияте» ясарга да мөстәгыйдь булмаган, милли мохтариятне дә кулда тота алмаслык бер хәлгә килдек.

Менә тарихның үткер балтасы Русия «дәүләте мөгаззимә»сен дә шулай тураклый башлады. Финляндия, Польша, Украина, Кавказ, Кырым кулдан ычкынды, Себер аерылырга тора...

«Соң ни булачак?» сөале тагы башны вата башлый. Янәдән шул сөаль табигый рәвештә бирелә башлый; янә карт тарих кулы белән югарыда зикер кылынган бөек империяләр, җөмһүриятләргә, ниһаять, күз алдымызда гына диярлек корылып, җимерелгән Наполеон империясенә төртеп күрсәтә башлый...

Адәмнең күләгәсе кеби янынннан китмичә торган хыял «Ул заманнар белән бу заман бер-берсенә бер дә ошамый; кыяс мәгаль-фарикъ!» диләр дә, безгә хәзерге бәшәрият галәменең икътисады вә мәгънәви хәле башкалыгын дәгъва итәләр. Ләкин шуны онытырга ярамыйдыр ки, тарих тәкәррердән гыйбарәттер! Бары тик бу тәкәррер, безнең шул сәяси, иҗтимагый дулкыннар арасында йөзгәнлегемездән, күренми генә.

Менә бер-ике гасыр үтәр, яңа дәүләтләр, яңа мохит, яңа гамилләр эш күрә башлар. Русиянең хәзерге әхвален дә шулай ук тарих үзенең зураеп та, беткән дәүләтләре җөмләсенә язды-рып куяр...

Дөрест, бу кызганыч, бер бөек дәүләт егыла, ул дәүләтне төзегәндә безнең төрек-татар каны да бик күп түгелгән, ләкин нишләмәк кирәк?

Тарихның яшен кеби тиз бара торган агымын безнең хыялый фикер вә тарикатьләремез генә туктатачак түгел! Рума империясе җимерелгән вакытларда да христианлык, стоизм, эпикуризм кеби, бәшәриятнең сәгадәте хакындагы фикерләр үзләренең фәлсәфә сатуларында дәвам иттердекләре хәлдә, вандал, hун hәм готларны китергән вә Рума дәүләтен егарга сәбәпче булган икътисадый гамилләр империяне hаман җәhәннәм чокыры янына якынлаштыра баралар иде...

(«Шәрекъ кызы» журналы. – 1918. – № 3. – Б.60-63).

бәшәрият – кешелек
хиффәт – акылы зәгыйфь
мәсгудь – бәхетле
нәзәриятпәрвәр – теоретик
ингыйкяс – чагылдыру, күрсәтү
васита – арадашлык, ярдәм
сахир – сихерче
сонгый – ясалма
мәнбәгъ – чыганак
Африканский Августин – Августин Аврелий (354-430), урта гасырларның күренекле философы, Төньяк Африкада туган.
фәгалиять – гамәл
тарикать – тоткан юл, юнәлеш
мөнбит – уңдырышлы җир
рәфаhият – иркенлек, муллык
тауранырга – канәгатьләнергә, риза булырга
мөсагадә итү – мөмкинлек, рөхсәт бирү
нәүгъ – төр
кыйсьмән – өлешчә
урдусы – урдасы, гаскәре
зоhур итү – туу, барлыкка килү
вөҗүд – барлыкка килү
хөдүд – чик
хилафәт – хәлифәлек
мөрәббәгъ - квадрат
мөстәгыйдь – кулыннан килерлек, булдырырдай
мохтарият – автономия
дәүләте мөгаззимә – бөек дәүләт
кыяс мәгаль-фарикъ – «тиңләштерү аермалы, мөмкин түгел» мәгънәсендә
тәкәррер – кабатлану

Гыйльми материал арасында

I

Русия монархиясе үзенең эчендәге төрле кавемнәрне тикшерүгә әһәмият бирмәде. Шуның аркасында Русиядә булган төрле галимнәр һәм гыйльми оешмалар да күбрәк яисә Русиянең тышында булган халыкларны яисә великорус халкын өйрәнү белән шөгыльләнделәр вә бу юлда зур муаффәкыятьләр таптылар. Мәсәлән, археология оешмалары безнең Идел буе шикелле җиргә күмелеп калган борынгы мәдәниятләрне тикшерү, Идел буендагы искедән калган җирләрне казу вә халыкларның тормышын тикшерү урынына бик ерак җирләргә әһәмият биреп, хәтта Борынгы Бабил, Мисыр хәрәбәләрен казырга акча вә көч сарыф кылгалап тордылар. Шул сәбәпле безнең Татарстан өлкәсе каплап торган урыннарның да тарихы вә этнографиясе һич җүнләп тикшерелмәгән. Моны тикшерүнең вакыты хәзер килеп җитте, шуңарга махсус оешмалар төзелде, мәҗмугалар чыгып тора. Ләкин Русиянең икътисадый хәленең авырлыгы хөкүмәткә бу эшкә әллә ни кадәр акча сарыф кылырга ирек бирми. Бу революция биргән тикшерүгә мөсагадә белән табигый файдаланырга кирәк; ләкин тарих вә этнография бабында иң зур эш – материал җыюдыр. Материал исә Татарстанда хисапсыз күп, бу елгы гомуми Русия күргәзмәсендә нәрсә җыяр өчен ясалган ике кечкенә генә экспедиция моны күрсәтте, тарих вә этнография өчен хәзерге фәнгә мәгълүм булмаган әллә никадәр материал бирде; әгәр чынлап әзләсәк, фән өчен бик мөһим материал табылачагында сүз дә юктыр. Казанда торып бу эшне эшләп булмый. Әмма кантоннарга махсус гыйльми сәфәрләр ясарга яңа әйтелгән икътисадый яктан күп имкян юк. Бу тарихи вә этнографи материаллар көннән-көн югалып баралар. Матди материаллар, биналар, киемсалым, зиннәт әсбабы, корал шикелле нәрсәләр яисә ачлык заманнарда яисә модадан чыкканга сатылалар вә тузалар, пожарларда янып һәлак булалар. Мәгънәви материалдан халык әдәбияты, җырлар, табышмак, мәкаль, имля шикелле сүздән гыйбарәт булган материаллар картларның үлүе белән югалалар, рево-

люция заманында вакыт, тыныч заманга караганда тагы да тизрәк акканга, хакында үзенең дәрәҗәи мәдәниятен тиз-тиз генә алып барып, бер дәрәҗәдән икенчесенә тиз күчкәнгә, бу материаллар әлек модернизмга бирелеп катлауланалар, соңра алмашалар, соңра әүвәлге мәүзугъларын югалтып, алар урынына яңалары туа, яисә бөтенләй югалып, алар урынына фәнни, гыйльми яисә язма әдәби нәрсә вә фикерләр керәләр. Шул сәбәптән тарихи вә этнографик материалларны тиз генә җыеп калырга кирәк.

Европа милләтләре арасында тарихи вә этнографик материалны җыю эше белән халык мәктәпләре (ибтидаи мәктәпләр)нең укытучылары күп шөгыльләнәләр. Мәсәлән, шул укытучылар хезмәте аркасында герман халык әдәбияты вә гомуми фольклоры ифрат дәрәҗәдә яхшы җыелган һәм тикшерелгән вә аның белән хәзерге көндә әллә никадәр социолог вә этнологлар гомуми гыйльми кануннар чыгару өчен файдаланып яталар. Дөрес, безнең хәзерге көндәге күбрәк укытучыларыбыз белән Германия ибтидаи мәктәп укытучылары арасында зур аерма бар. Безнекеләр аз мәгълүматлы вә аз хәзерлекле булсалар, Европадагы сыйныфташларыбызның белемнәре зур вә киң. Ләкин бит гыйлем вә фән безгә күктән төшәр әле дип көтеп, тормыштан зарланып кына ятып булмый. Өйрәнсәк, укысак, һәрвакытта да белергә мөмкин. Шулай ук булдырып булмас дип, үз-үзеңә ышанмыйча да торып булмый, бары тырышырга кирәк.

II

Укытучылар татар тарихы вә этнографиясеннән материал җыйганда шушы нәрсәләргә артык әһәмият бирергә тиешләр:

1. Борынгыдан калма тәңкәләр. Бу тәңкәләр бигрәк тә Спас, Лаеш, Тәтеш кантоннарында вә Арча, Әтнә, Мәңгәр, Әйшә шикелле борынгы зиярәт вә шәһәр калдыклары булган җирләрдә табылалар. Бигрәк тә алар сука сукалаганда, тырма тырмалаганда һәм яз көннәрендә шаулаулар аккан җирләрдә очрыйлар. Бу тәңкәләрнең күбесе Алтын Урда дәверенеке булганлыктан, мәгълүм тәңкәләр булсалар да, шул тәңкәләр арасында фән өчен бик әһәмиятлеләре килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән, шушы көнгә кадәр Казанда сугылган Казан ханлыгыннан калма тәңкәләр табылганы юк, шулай ук Болгарда яисә Болгар иленең Суар, Биләр, Коштан шикелле урыннарында XII нче гасырга кадәр сугылган тәңкәләрнең бары бер-икесе генә табылган.

2. Шулай ук савыт-саба, корал калдыклары мәсьәләсе. Болар да борынгы татар вә болгар тарихын өйрәнү өчен бик кирәкле

материаллар, хәтта чүлмәк кисәкләренә дә зур игътибар итәргә кирәк.

Бу чүлмәк китекләре аркасында тарих гыйлеме бер халыкның мәгълүм дәверләрен дә ачып бирә ала. Табигый җир өстендә табылган һәрбер китеккә әһәмият биреп булмый, аларның күбесе тирес түккәндә чыгарылган булалар. Ләкин җир астыннан чыкканнарына зур дикъкать итәргә кирәк.

3. Әгәр әзләнүче алка, йөзек, беләзек, чулпы, гәрәбә, тапас шикелле зиннәт нәрсәләре тапса, аларны мөһим нәрсәләр тапкан дип әйтергә кирәк була.

4. Бигрәк тә әһәмиятле тикшерелә торган нәрсәләр – кабер ташлары. Боларның әле күбесе «Иске зиярәт», «Газыйлар» яисә «Изгеләр зиярәте» дип йөртелә торган каберлекләрдә булалар. Әле болар ифрат күп, аларның кайсысы рус авыллары тирәсендә дә калдылар. Мәсәлән, Казаннан 30-40 чакрым җирдә Чыпчык авылына кергәндә ике, хәзергә укылмаган, тикшерелмәгән таш утырып тора. Болардан ике юл белән файдаланырга мөмкин: 1) әгәр фотография булса, якыннан язуын төшереп алу; 2) фотография булмаса, карандаш я каләм белән нәкъ үзләре төсле үк итеп күчереп алу. Соңыннан кесә дәфтәренә кайда, нинди урында, никадәр зурлыкта икәнен язып алып, укырга керешү. Танылмый яисә танып булмый яисә яртысы беткән, ватылган дип, ташлап китәргә ярамый. Чөнки укылган вә калган кадәрлесе дә, тиешле урында доклад ясалса, фән аның белән файдаланачак.

5. Кыш көннәрендә вә начар һавалы вакытларда укытучыга тагы да зур вә әһәмиятле эшләр бар. Ул да булса иске язмаларны җыю вә кулга алып булмаса, аларны укып, тарих вә этнографиягә (гореф-гадәт, дарулар, имләү вә башкалар) гаид булганнарын имлясы вә теле белән бер дә үзгәртми күчереп алу. Китап яисә язылган кәгазьне кулга алып та, бу гарәп я фарсы теле белән язылган икән дип ыргытып ташларга ярамый. Андый дин китаплары кырыенда язган язу вә бәгъзе вакытта тарихи яктан мөһим булуы өстенә, тел вә өслүб ягыннан һәм аның каләме җәһәтеннән мөһим булалар. Мондый вакытта язуның кайчан вә кем тарафыннан язылган булуы бик мөһим. Гадәттә мондый иске язулар авылда укымышлырак картларда һәм карт муллаларда булалар. Ләкин аларның иң мөһиме мәчет чормаларында табыла. Мәсәлән, татарларның бер тел тикшерүчесенең мәшһүр «Йосыф-Зөләйха» дастанының яңа вариантын тапканы мәгълүм. Без дә бервакыт Гали Рәхим белән Казан мәчетләренең берсеннән Хисам Мөслиминең «Тәварихе Болгария»сенең бер кисәген тапкан идек. Кулъязманы тапкан чакта, әгәр аны кулга төшереп булмаса, күчереп алганда аның кәгазенең дә рәсме хатының нин-

ди булганын вә нинди зурлыктагы битле кәгазьгә язылганын язып алырга кирәк.

Мәгънәви мәнбәгъләрдән халык әдәбиятын җыюның әһәмияте бу елларда булып килгән курсларда укыган вә әдәбият дәресләрен тыңлаган укытучыларга мәгълүм бер мәсьәлә. Шуның өчен аны җыюның әһәмияте хакында сөйләп тә тормыйм. Бары тик бу хакта бер-ике генә сүз әйтеп китәргә кирәк:

1. Этнография фәне халыкның дәвалау хакында булган гореф вә җолаларын бик дикъкать итеп мәгълүмат җыя. Бу мәсьәлә белән Россиядә һәм Европада бик күп галимнәр шөгыльләнәләр. Төрек вә татар халкының да бу яктан дикъкать итәрдәй бик кызык фикер вә гадәт-җолалары бар. Халык кулында искедән калган күп кенә татарча язылган «Тыйбб китаплары» йөри. Бу хакта борынгы язма китап тышларында гаҗәеп кызык им-том өйрәтелгән фикерләр очрый. Ләкин халык эчендә моның тагын да кызык специалистлары бар. Аларны «имче» дип атыйлар. Менә шушы мәсьәләгә даир мәгълүмат җыю этнография өчен бик әһәмиятле. Укытучылар карт вә карчыклар белән сөйләшеп утырганда нинди җирдә нинди дару вә нинди догалар кылу, чалпу бака догасы, куркылык кою шикелле нәрсәләрне дикъкатьләп сорашып, халыкның үзе сөйләгән төсле үк итеп язып алырга кирәк. Язып алганда кемнән вә кай урында ишеткән вә күргәнен язарга онытмаска кирәк. Мондый «сәнәт»сез булган мәгълүматның этнография гыйлеменә бер төрле дә бәһасе юк.

2. Татар арасында шаманлыктан калма «сихер», «күз буу» аталган нәрсәләр бар. Бу да фән өчен мөһим.

3. Насыйри вә башка галимнәр тарафыннан һәм «Аң» журналында Гыймад Нугайбик тарафыннан язылган вә җыелган татарларның ислахтан элек мәгъбүдләре булып та, хәзер бары «пәри-җен» рәвешендә халыкта бик күп затлар хакында хикәя вә мифлар йөриләр. Бу хакта мәгълүмат җыю бик файдалы, бу мәсьәлә белән без татарның борынгы шаманлыгын гына өйрәнеп калмыйбыз, бәлки гомум инсаниятта анемизм шикелле дини хорафатларны өйрәнү өчен күп мәгълүмат җыйган булабыз. Бу хакта татар әдәбиятында да бер-ике тәшәббес булды инде. Ләкин ул нәрсәләрдәге мәгълүмат әлегә зәгыйфь.

III

Укытучы иптәшләр җыйган мәгълүматны кайда куярбыз вә аны җыеп кайда җибәрербез диярләр. Инде Татарстанда хәзер мондый татар халкына даир мәгълүматны җыючы урын бар – ул да булса «Татарны өйрәнү» оешмасыдыр. Оешма мондый матери-

алны җыярга вә аларны тәртипкә салып, бәгъзе бер изахлар белән бастырырга тиеш. Әгәр иптәшләр җыйган мәгълүматларын «Гыйльми мәркәз»гә күндерсәләр, оешма мәгаль-мәмнүният кабул итәчәк һәм шул җыелган мәгълүмат һәм материалга карап мөтәхәссисләр доклад ясаячаклар. Бу докладта һәм материалны бастырганда җыючы иптәшләрнең исемнәре яд ителәчәк, җыю, эзләү шәрәфе аларга биреләчәктер. Әгәр инде мондый мәгълүмат күп вә яхшы җыелса, укытучы иптәшләр шул оешма аркылы матди яктан да файда күрәчәкләр. Бу хакта җыюның ысулларын, юлларын вә мәгълүмат сорап «Гыйльми мәркәз»гә минем исемемә хат язсалар, мин яисә белмәгән мәсьәлә вә мөтәхәссисләргә мөрәҗәгать итеп, иптәшләргә киңәш вә мәгълүмат бирү өчен хат язачакмын.

Билгеле, татар укытучылары – революция продуктларыдыр. Бу сыйныф аларны китереп чыгарган Февраль вә, бигрәк тә, Октябрь революциясенең тарихын өйрәнү юлында хезмәт итәргә тиешлеләр. Бу хакта урыннардагы материаллар хәзергә тикшерелмәгән, җыярга мәгълүмат күп. Бу материалларны ничек җыярга кирәклеге хакында икенче мәкаләбез киләчәк номерда булачак.

(«Мәгариф» журналы.– 1923.– № 9-10 (19-20).– Б. 59-62).

мөсагадә – мөмкинлек
имкян – мөмкинлек
дәрәҗәи мәдәният – мәдәният дәрәҗәсе
мәүзугъ – әһәмият
ибтидаи – башлангыч
гаид – бәйле
тыйб – медицина
даир – караган
мәнбәгъ – чыганак
тәшәббес – инициатива
изах – аңлатма
мөтәхәссис – тикшерүче
мәгаль-мәмнүният – шатланып

Иҗтимагый гыйлемнәр бабында ниләр эшләнде?

I

Без сөйләячәк фәннәр. Казанның иҗтимагый гыйлемнәр бабында роле. Аның бу бабта реакция дәверендә төшүе. Рус галәмендә. Татар галимнәре. Сугыш дәвере. Февраль революциясе вакыты. Татарстан Советлар Җөмһүрияте игълан кылынгач.

Без бу мәкаләбездә иҗтимагый гыйлемнәрдән тарих, әдәбият тарихы, этнография, икътисад һәм сан алу (статистика) вә үзе табигыятьтән булып та, иҗтимагый гыйлемнәргә бик якын булышчы булган антропология гыйлемнәре бабында кирәк аерым кешеләр вә кирәк коллективлар тарафыннан биш ел эчендә эшләнгән эшләр хакында сөйлибез.

Татарстан Җөмһүриятенең баш шәһәре Казан XIX йөзнең беренче чирегеннән башлап Русиянең гыйльми мәркәзләреннән берсенә әйләнде. Бу иске шәһәрнең кочагында бик күп галимнәр тәрбияләнделәр. Аларның төрле гыйлем бабларында, бигрәк тә, иҗтимагый фәннәрнең бик күбесендә зур хезмәтләр кылулары аркасында Казан шәһәре Русиядә генә түгел, хәтта гарби Европада да мәгълүм бер гыйлем мәркәзенә әйләнде. Без бу затларның исемнәре вә аларның хезмәтләрен санап бетермибез. Ләкин шунысы тәәссефле ки, бу шәһәр 1905 еллардан соң хөкем сөргән реакция заманыннан алып иҗтимагый гыйлемнәр бабында артка чигенде. Бик зур галимнәр бу заманда мәәюс булып, рухларын төшереп, иҗади эштән туктадылар. Профессор Фирсов шикелле зур галимнәрнең кайсысы Казаннан сөрелделәр; Катанов кебек мәшһүр мөстәшрыйклар, тәәмин ителә алмыйча, зур, кадерле көтепханәләрен чит илләргә сатып җибәрделәр дә, үзләре гыйльми эш белән тәәмин ителә алмагач та, монахларны укытыр өчен Рухани академиягә мөдәррис булдылар. Кайсылары попечитель вә губернаторга ошый алмагач, Казанны ташлап киттеләр. Икътидарсыз, «әмре шаһәнә» белән профессор булган күп кенә кешеләр Казан дарелфөнүненең хокук, филология факуль-

тетларын тутырдылар. Боларда, бик күп кафедралар профессорсыз буш калганы хәлдә, чиркәү тарихыннан икешәр кеше дәрес әйтеп килде. Хокукчыларның берсен марксизмда гаепләп, дөньяви гыйлемнән курс укытырга ирек бирмичә, үч иткән төсле, чиркәү хокукы укытырга мәҗбүр иттеләр. XIX йөзнең ахырына кадәр гаять мөһим диссертация вә мәкаләләр басылып килгән, дарелфөнүннең нашире әфкяре булган мәҗмугада 1905 елдан соң берничә әсәрне алып ташласак, иҗтимагый гыйлемнәрдән рәтле нәрсәләр басылмас булды. Казанда бердәнбер иҗтимагый фәннәр бабында эшләүче Археология җәмгыяте тирәсендә берникадәр эш барса да, өлкәне өйрәнүчеләрнең юклыгыннан, максаттан бик ерак булган мәсьәләләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр булдылар. Хокук оешмасы исә, тугач ук үлде. Бу рус галәмендә.

Бу тирәдә соңгы елларда бер генә татар эшләмидер иде. Бердәнбер рус галимнәре арасында йөрүче, кайбер мөһим докладлары белән Археология җәмгыятендә мәгълүм Г.Әхмәрев тә чахоткадан үлде.

Килик татар галәменә.

Олуг сугыш башлану белән, 1905 елдан алып, Насыйридан вә Мәрҗанидән соң башланган фәнни хәят чаткысы яңадан акрынайды. Тарих бабында эшләүчеләрнең кайберләре, шулай ук грамматика һәм әдәби тарих, тәнкыйть бабында эшләүче Галимҗан Ибраһимов та Казан атмосферасыннан югалдылар, педагогика һәм методика бабында эшләүче Мөхетдин абзый Корбангалиев тә фәннән бигрәк практик эшләр белән мәшгуль булды. Хуҗа Бәдигый кебек халык әдәбиятын җыючы кешеләр дә гаскәри хезмәт бәласенә дучар булдылар. Бик күп зыялыны шул ук бәладән котылу өчен тагы «оборона»га тартып илтте һәм гәзитәләргә учетка керергә мәҗбүр итте...

Татар галәме менә шул рәвешчә Февраль революциясенә барып керде. 1917 ел тагын татарның аз-маз гыйлем белән шөгыльләнүчесен фән бабына җибәрде. Татарның Казандагы бөтен зыялысы – һәммәсе дә сәяси дулкынга иярep киттеләр. Әллә ничә организациядә рәис, секретарь, әллә ничә гәзитәнең язучысы, мөхәррире, нашире булып әверелделәр. Шулай ук беренче вә икенче Русия мөселман укытучыларының съездларындагы тел, имля бабындагы мөназаралар да бары сәяси көрәшкә багышланган ашыгыч эшләр генә иделәр. Менә Октябрь революциясенә кадәр Казанда гыйльми тормыш шул дәрәҗәдә иде. Бу каты иҗтимагый көрәш дәверендә чып-чын гыйльми хезмәтне үтәп тә булмыйдыр иде. Шуның өчен без хәзер Татарстан Җөмһүрияте игълан кылынгач, революция үзенең дошманнарын җиңеп чыга башлаган дәвергә күчәбез.

II

Тарихы гомуми, Русия тарихы бабында Татарстанда хезмәтләр. Галимҗан Ибраһимовның татар тарихына марксизм социологиясен истигъмале. Бу хактагы мәкаләсенең маһияте. Бу әсәрнең тарихи әдәбиятка тәэсире. Археология бабында хезмәтләр. Болгар вә Казан ханлыгы дәверенә даир хезмәтләр. Алтын Урда тарихын өйрәнүдә Баллодның хезмәтләре. Өлкәнең яңа дәверен тикшерү. Татарларда революция тарихы мәсьәләсе ничек әшләнде? Татар әдәбияты тарихы бабы. Гыйльми Үзәкнең мәңгелек хезмәте. Халык әдәбияты тарихын өйрәнү бабы. Аерым тарих шәхесләрне өйрәнү.

Килик тарих бабына.

Татарстан Җөмһүрияте игълан кылыну белән, Казандагы бөтен фәнни тере яшь вә карт көчләр үзләренең тикшерүләрен өлкәне өйрәнү юлына бордылар. Ләкин, шулай булса да, гомуми һәм Русия тарихлары бабында тикшеренүләр һаман сүнгәне юк. Моңарга безгә мәгълүм булган берничә мисалны гына алып китәбез. Профессор С.П.Шестаков классик (юнан вә рума) галәмен өйрәнүнең хәзерге көндә модадан чыгуына, Казанда филология факультетының булмавына игътибар итмичә, борынгы шәрекъ, юнан, рума һәм бизанс галәмнәренең тарихларын тикшерүләрен вә бу хакта язулардан тукталганы юк. Аның хәзерге көндә тәмам булган гаять мөһим әсәрләре мәркәзләрдә басылу нәүбәтен көтеп яталар.

Яшь археолог, профессор Ф.Смолинның җәнүби Русиядәге миллият колонияләре хакындагы әсәре дә тәмам булган. Профессор З.З.Фирсовның* Екатерина дәүләтендәге сәүдә вә сәнагать компанияләре XVI-XVII йөзләрнең Русия тарихыннан укылган лекцияләре, аның оста каләме белән төрле вакытларда язылган эскиз вә характеристикалары Татарстан нәшрият комбинаты тарафыннан тагын басылып чыктылар. Бу галимнең 1917 елдагы «Крестьян революциясе һәм Вакытлы хөкүмәт» дигән әсәре Өлкә фирка комитетының истпартбюросының «Революция юллары» дигән гаять мөһим мәҗмугаларының № 1-ендә басылып чыкты.

Бу карт тарихчы, әдипнең талантын Татарстан Җөмһүрияте игълан кылыну тагы да арттырды; Татарстанның сәяси, иҗтимагый шартлары чынлап утырып эшләргә уңайлыклар бирүе ар-

---

* Төп текстта типография хатасы киткән, ягъни инициаллар ялгыш басылган, дөресе – Н.Н.Фирсов. – *(Төзүчеләр искәрмәсе).*

касында аның революция, халык хәрәкәтләре, аерым тарихи шәхесләрнең тормышына даир, Казанда язылган бик күп мәкаләләре белән мәркәз матбугаты бизәлде; шулай итеп Николай жандармнары тарафыннан сөрелгән бу профессор картайган көндә яңадан, шушы көндә эшләп ята торган рабфаклар өчен язуга кадәр барып җитте.

Без монда тарих бабында башка хезмәтләрне куеп торып, өлкә һәм аның халыкларының үтмешен өйрәнү бабына күчәбез.

Татар тарихын социология – гомумиләштерү (обобщение) бабында бер-ике сүз. Тарих теориясе, фәлсәфәсе бабына даир әсәрләрне, әгәр 1906 елда Казанда басылган Йосыф Акчураның «Тарих вә голүм»ен алмасак, татар әдәбияты тудыра алмаган иде. Бу Акчура әсәрләре дә социологиядән позитивизм мәсләген, методологиядән Синиабос фикерләрен гомумиләштерүдән башка бер нәрсә дә түгел иде. Монда татар, төрек халыкларының тарихының процессына даир мисал йөзеннән генә бер-ике сүз әйтелгән иде. Бу бабта, 1910 елларда булса кирәк, Галимҗан Ибраһимов белән минем арамда «Шура»да бер тәнкыйть мөнәсәбәте белән бер мөназара булып узган иде. Ләкин мәсьәлә конкрет рәвештә моннан 2-3 ел эчендә шул ук Ибраһимов белән Җамал Вәлиди арасындагы мөназара булып, Татарстанда башланды. Бу бер хосусый мәсьәлә өстендә башланган мөназараның төбе янә шул тарихның дәверләре (период) һәм төп фәлсәфәсе өстендә барды.

Шушы мөназараның нәтиҗәсе булса кирәк, бу мәсьәләгә даир Галимҗан Ибраһимовның «Безнең юл» журналының 1922 елда 1 нче номерында «Иҗтимагый әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм» исемендә бер мәкаләсе чыкты. Бу мәкаләнең исеме әдәбият мәсьәләсенә гаид кенә булса да, асылында бу, татарның бөтен үткәненә дәверләр ясау, аның тарихының, юлының төп процессын ачып бирү мәсьәләсендә социология турында бер зур әсәрнең конспекты, кыска гына әйткәндә, татар тарихына марксизм социологиясенең кануннарын татбикъ кылуның беренче һәм уңышлы бер тәҗрибәсе иде. Бу әсәрнең бер әһәмиятле ягы татар тарихына марксизм күзлеге аша карау булса, аның икенче җәһәте моңарчы кул, тел тимәгән татар тарихының яңа дәверен дә кертеп бер юл сызып күрсәтү иде. Бу зур түгел, әмма мөндәриҗә җәһәтеннән бай мәкаләнең төп фикерләре бер конспект шикелле булса, соңра мөхәррир башка әсәрләрендә бу мәсьәләләрне детальләү белән мәшгуль булды. Тагын да ачык әйтелсә, Галимҗан Ибраһимов татар тарихының процессын әдәби рәвештә «Безнең көннәр» заманында бирергә башлаган булса, бу

әсәрендә ул аны гакыл, мантыйк, фактлары белән бирергә омтылды. Бу мәкаләнең кыскасы шуннан гыйбарәт:

1) Безнең мәдәният тарихыбыз – җиде кабилә (казан татарлары, мишәр, нугай, алатыр, типтәр, төмән һәм касыйм татарлары) җыелып, бер милләт рәвешендә әдәби бер коллектив буларак яшәгән бер җәмгыять тарихыдыр;

2) Менә шушы кабиләләрнең мәдәният тарихларын тикшереп, хәзерге көнгәчә килеп җитсәк, өч дәвер (эпоха) күрәбез:

а) кадимче Шәрекъ – Русия мөселманлыгы дәвере, яисә идеологиядә феодалчылык дәвере. Хронология җәһәтеннән бу дәвер XVI йөздән, ягъни Казан дәүләтенең егылуыннан башланып, XIX йөзнең уртасы, Насыйриларның килеп чыгуы заманы белән тәмам була.

б) икенче дәвер Шәрекътән кергән бөтен тоткарлыкны җимереп, яңару, европалашу белән башлана; моның чыгуына сәбәпләр: «Европада финансовый капиталның үз чигеннән тулып ташуы, Шәрекънең йотылуы, Русиядә капитализмның көчәюе, аның Урал-Волга буена һөҗүме, шуның нәтиҗәсендә безнең натуральный хуҗалыкның җимерелүе, татар буржуазиясенең чигелмәс өчен яңа юллар эзләве, дошман коралы белән коралланулар; шуннан килеп чыккан буржуазный уяну вә яңа мәдәният туу, нинаять сәяси буржуазный фикер вә агымнарның ясалышы.»

в) Октябрь революциясеннән соң яңа дәвер башлана. Бу дәверне тудырган сәбәпләр: алдагы дәвернең моңарга юл ачуы, җинан сугышы вакытында татарның сәүдә вә сәнагать капиталының үсүе, шуның белән бергә хезмәт әнеле тормышының гаять начарлануы; шуннан килеп чыккан каты сыйнфый аермалыклар.

Ибраһимовның бу мәкаләсенең без бары кыскасын гына алдык. Мәкалә схема кебек язылса да, анда һәр дәвер шактый гына озын язылган. Без бу мәкаләне бәһаләүгә керешмибез, ләкин шулай да әсәрнең гыйльми яктан яңа, әһәмиятле, оригинал бер мәкалә икәнен игътираф итәбез.

Шул ук номер «Безнең юл»да Сәлах Атнагуловның да тарихны дәверләргә бүлү хакында бер тәҗрибәсе чыкты, ләкин бу мәкаләнең төп фикерләре Ибраһимовныкы белән якын булганга, бу хакта тукталмыйбыз. Яңа мәкалә вә әсәрләрендә, туры килгән чакта, Ибраһимов бу фикерен һаман детальләп вә киңәйтеп сөйләп торып, каләм вә гыйлем әнелен бу бабта уйларга юл ачты. Аның «Безнең юл»ның 1922 ел № 2-дә басылган «Татар әдәбияты тарихының мөндәриҗәсен билгеләү мәсьәләсе» Каюм Насыйри мәҗмугасында язган мөкаддимәсе шул юлда детальләрне ачып

бирергә омтылудан гыйбарәт иде. Ләкин 1 һәм 2 нче дәверләрне детальләп тикшерү эшен мин дә бу мәкаләләрдән соң алып китәм. Мәсәлән, «Татар сыйныфлары тарихы» хәзер басылмакта булган русча «Татар буржуазиясе тарихы», «Яңа шәрекъ» исемле рус мәҗмугасында басылган кыскача, янә Мәскәүдә бер мәҗмугада басылып ята торган «Пугач явында татар сыйныфларының катнашуы» исемле озын мәкаләбез шул мәсьәләләр белән шөгыльләнүнең нәтиҗәләре иде. Башкалар 1, 2 дәверләрне тикшерсәләр, мөхәррир үзе һаман да 3 дәвер белән мәшгуль; аның моннан 3 ел элек чыккан «Октябрь революциясе», хәзер генә басылып чыккан «Пролетариат әдәбияты» шушы яңа дәверне тәфсилләүдән гыйбарәттер.

Хәзер без Татарстанда 5 ел эчендә өлкә тарихын өйрәнү мәсьәләсенә күчәбез.

Бу бабта язылган бөтен нәрсәләрне санап тормыйбыз. Мондый нәрсәләрнең матбугат дөньясына чыгарга торган, хәзерләнеп ята торганнары бик күп. Билгеле Гыйльми Үзәк һәм шушы көннәрдә туган Өлкәне өйрәнү бюросы боларның мәгъкуль булганнарын бастыру чараларын карар, өмет бар ки, аларның күбесе басылачактыр.

Сүзне өлкәнең тарихтан элекке хәлен өйрәнүдән башлыйк.

Археология бабында биш ел эчендә ике галим эшләп килделәр: М.Г.Худяков һәм профессор В.Ф.Смолин. Боларның Казанда эшләгән хезмәтләре Казан матбугатында басылып килделәр. Әле хәзер дә өлкәнең таш, бронза йөзләренә гаид язган әсәрләре – кулъязмалары бар.

М.Г.Худяковның өлкәне өйрәнү турындагы әсәре – Татарстанның археология харитасыдыр. Бу әсәрнең өлкәбездә булган бөтен мөһим борынгы калдыклары, хәрабәләре – һәммәсе дә күрсәтелгән. Әсәр Гыйльми Үзәк вә Татарстанны өйрәнү җәмгыятьләре тарафыннан вөҗүдкә килде.

Профессор Смолин күбрәк өлкәнең болгар дәверен тикшерү белән мәшгуль булып, бу бабта «Идел-Кама Болгариясенә мәдхәл » исемендә шәрекъ-гареб мәнбәгъләрен тикшерүче бер әсәр язып тәмам итте.

Быел Смолинның «Болгарга юлбашчы»сы белән Гыйльми Мәркәз тапшырган бер кулланмасы язылып, тәмам булып типографиягә бирелде. Шул ук яшь галим «Реальный словарь древностей Волжско-Камского края» дигән әсәрен тәмам итеп ята. Бу зат археология гыйлемендә классик юнан, рума галәмен өйрәнүдә кулланылып киленгән ысулларны татбикъ иткәнгә, ул әсәрләре методология ягыннан шөбһәсез, дөрес чыгалар. Казан ханлыгын тикшерү бабында Худяковның «Казан ханлыгы» дигән бер

әсәре чыкты. Бу әсәр хакында бер сүз әйтмәс борын, аңарга яңалык бирүче бер мөһим мәнбәгъ хакында сөйләп китми хәл юк. Ул исә шушы көннәрдә «Безнең юл»да һәм русча «Татарны өйрәнү җәмгыяте»нең хәбәрләренең № 12 басылып чыккан Сәед Вахидов тарафыннан табылып, 1925 нче ел февраль аенда Гыйльми Үзәк аркылы Татарстан Мәркәз музеена бүләк иткән Сәхибгәрәй хан ярлыгыдыр. Бу әсәр Казан ханлыгы дәвереннән калма, аның иҗтимагый-икътисади тарихын өйрәнү өчен бик бөек мәнбәгъләрнең берседер.

Менә Худяков шушы мәнбәгънең Вахидов тәрҗемәсе белән файдаланып, башка мәнбәгъләрне да алып, мәҗмуга – алда сөйләнгән әсәрен – язды. Монда җитешсезлекләр бар. Мәсәлән, әсәр марксизм әсасында язылмаган. Кайбер җирендә Казан ханлыгының мәдәниятен идеализация бар; ләкин бу эш бары яшь мөәррихнең борынгы миссионер тарихчыларга каршы булган реакциясе генәдер.

Татарстан Җөмһүриятенең зур булышлыгы белән профессор Баллодның Алтын Урда мәдәниятен тикшерүен алырга кирәк. Баллод һәм аның иптәшләреннән Зайковский вә башкалар борынгы Алтын Урда мәркәзе булган шәһәрләр урыннарында казынып, бик күп нәрсәләр, акчалар таптылар; шуның нәтиҗәсендә Сарай Җәдид шәһәренең урынын табарга муаффәкъ булдылар, шуның белән бергә Баллод, бер татар тарихы өчен генә түгел, бәлки бөтен дөнья тарихы өчен мөһим материаллар бирде вә күчмә халыкларның мәдәнияткә күчүләре Алтын Урданың да мәдәнияте, аның оригиналь архитектурасы вә орнамент һәм бизәкләре, техникасы – анда төрле сыйныфларның булуына даир матди дәлилләр, байлар вә хезмәт әһеленең өй тормышы, татарларның Урта Азия, Иран, Бизанс һәм Италия белән мөнәсәбәтләренә даир күп нәрсәләр бирде. Бу экспедицияләр хакында Казан, Татарстан мәгариф комиссариатына доклад язып, эшләгән эшләреннән бер хисап биргән соңында, «Мәгариф»тә бу хакта мәкаләләр язды. Шул ук вакытта, хәзерге көнгә кадәр, аның Алтын Урда хакындагы мөһим мәкаләләрен Мәркәз мәҗмугаларында бастырып торды. Татарстан хөкүмәтенең булышлыгы белән эшләнгән бу эшләрнең нәтиҗәсен ике китап итеп бастырды. Аның берсе Мәскәүдә басылган «Идел буе Помпеяләре» булса, [икенчесе –] Татарстан нәшрият комбинаты тарафыннан бастырылган « Яңа һәм иске Сарай»дыр. Әлхасыйл, Баллод һәм юлдашларының бу хезмәтләре XIX гасырда Саблуков вә компаниясе тарафыннан төзелгән Алтын Урда хакындагы ялгыш карашларны төзәтергә сәбәп булды.


ع. عزیز، علی رحیم.

تاتار ئەدەبییاتی تاریخی

برنچی جیلد.

بۇرنغی دەور.

ئیکنچی بولك.

تاتار تلی وەئەدەبییاتنك تاریخی یازمشی.
ئیدل بویندا تیك بۇرنغی تل یادکارلەری.
ئیدل بویندا جغتای ئەسرلەری.
ئیدل بویندا عۇسمانلی ئەسرلەری.

تاتارستان جۇمهوریەتنك دەولت نەشریاتی.

Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим. «Татар әдәбияты тарихы. 1 нче җилд: Борынгы дәвер. 2 нче бүлек» (Казан, 1922) китабының титул бите.

Өлкәнең яңа дәверен тикшерү бабында сан алу бүлеге тарафыннан чыгарылмакта булган «Татарстан цифрларда» мәҗмугасенең № 12-ендә дә Арцыбашевның «1814 елда Казан губернасының сәнагате» дигән мәкаләсеннән башка бик аз нәрсәләр мәйданга чыкты. Ләкин, шулай булса да, бу бабта мөһим әсәрләр эшләнеп яталар. Шул җөмләдән Й.Чирибашевның XIX йөздәге өлкәбезнең крестьян хуҗалыгы бабындагы мөһим хезмәте эшләнеп килә.

Яңа дәвердә өлкәнең тарихын өйрәнүдә зәгыйфьрәк җиребез – татарның революция тарихына даир әсәрләрнең аз булуыдыр. Галимҗан Ибраһимовның тәшәббесе белән Мулланур Вахитовка багышланып чыгарган мәҗмуганы да, шул ук галимнең «Татар студентлары хәрәкәте» дигән мемуарларны һәм Исхак Рәхмәтуллинның «Революция юллары»нда бастырган «Мулланур Вахитов» дигән мәкаләсен, Измайловның «Казан өчен көрәш» мәҗмугасына керткән кечкенә генә «Чехлар вакытында татарларның настроениесе» дигән мәкаләләре дә «Татарстан» газетасы битләрендәге төрле мөнәсәбәт белән Фатыйх Сәйфи, И.Рәхмәтуллин вә башкаларның татар революция хәрәкәтенә даир биргән материаллары, һәрхәлдә, бу бабта мөһим генә эшләрдәндер.

Әдәбият тарихы мәсьәләсенә килсәк, бу бабта түбәндәгеләр эшләнде. Бу бабта беренче итеп профессор Катанов тарафыннан язылып тапшырылган «Татар әдәбияты тарихы»н алырга кирәк. Бу әсәрнең мөһим бер ягы булса, ул да мөхәррирләре мәгълүм булмаган вә язылган еллары да караңгы булган, татарлар арасында укылып йөрелгән борынгы әсәрләр хакында мәгълүматыдыр. Шулай ук Г.Рәхим белән минем тарафымнан язылып басы-

лынган «Татар әдәбияты тарихы»ның борынгы дәверен алырга кирәк. Бу әсәрнең хәзер төзәтелгәне марксизм юлына бик якын китерелеп «Феодализм дәверендә татар әдәбияты» исеме белән басылып чыкты. Бу хакта матбугатта чыккан ике мәкаләне оныты-п калдырырга ярамый. Аның берсе беренче басманың 3 җилденә язылган «Безнең юл»да басылган Г.Сәгъдинең тәнкыйде, икенчесе Ж.Вәлидинең «Бүз егет» поэмасы хакындагы мөһим гыйлавәседер.

Татар әдәбиятының үткәнен өйрәнү өчен зур булышлыкны 1925 нче елда Гыйльми Үзәк эшләде. Быел яздагы карары белән «Татар әдәбияты көтепханәсе» нәшер итәргә карар кылды. Бу нәшрият татар әдәбиятының мөһим классик әсәрләрен бастырырга ясалган бер мөһим тәшәббестер. Бу серия хронология тәртибе белән бик борынгы нәрсәләрдән алып, 3 нче дәверне дә эченә алып чыгарга тиештер. Әсәрләрнең чыгу тәртибе һәм планы Галимҗан Ибраһимов тарафыннан ясалып, газеталарда игълан кылынды. Хәзер инде бу сериянең күп кенә китаплары чыкты. Моның белән Гыйльми Мәркәз зыялылар массасына татар әдәбиятын әсәрләре буенча өйрәнүне ансатлатты. Һәрхәлдә, безнең каршыбызда бу бер бөек гыйльми эштер.

Татар халкы әдәбиятын өйрәнү бабында да күп кенә эшләр эшләнә.

1925 елда М.А.Васильевның русча «Татар әкиятләре» дигән мәҗмугасы басылып чыкты. Бу әсәрдәге хикәяләрнең татарча тексты булмавы кимчелектән хисап ителә, һәрбер әкиятнең артына гыйлавә кылынган башка халык хикәяләре белән чагыштыру өчен күргәзмәсе Васильевның бу бабта гаять күп тикшерүенең нәтиҗәсен күрсәтәдер. Моннан соң татар зыялыларына да татар әкиятләрен башка халыкларныкы белән чагыштырып өйрәнү өчен юл ачылган дип хисап ителергә тиештер.

Биш ел эчендә татарның гыйльми матбугаты аерым тарихи, мәдәни, әдәби көчләрне, аларның тарихи формаларын вә мохитләрен өйрәнү мәсьәләсенә дә шактый әһәмият биреп килде. Без Мулланур Вахитовка багышланган мәҗмуга хакында сөйләп уздык. Шулай ук революция вакытында вафат булган зур һөҗүви талантлы шагыйрь Бабичны тикшерүне дә әйтеп узарга кирәк. Җөмһүриятнең беренче көннәрендә булса кирәк, вакытсыз һәлак булган шагыйрьнең әсәрләре вә аның әдәби, иҗади эшләре хакында Галимҗан Ибраһимовның озын мәкаләсе белән бер мәҗмуга чыкты. Ләкин аерым тарихи-мәдәни хезмәтләрне өйрәнү бабында Г.Ибраһимов редакциясендә 1922 елда чыгарылган «Насыйри мәҗмугасы»н алырга кирәк. Насыйри мөнәсәбәте белән чыгарылган мәҗмуга аркасында Насыйри һәм аның заманы ха-

кында төрле мәгълүмат алынды, яңару дәверенең башы шикелле бер тарихның караңгы почмагы ачылды. Быел февральдә, димәк, туганына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән, Татарстан Җөмһүрияте Насыйри кебек яңартучы, педагог, этнограф, тарихчы, телчене яңадан хәтерләп, бер бәйрәм ясады. Аның кулъязма, мөһим әсәрләрен басарга карар кылды, бу әсәрләрнең фәнни әһәмиятләре хакында бер әсәр язылды; Казан археология җәмгыятендә Насыйри хакында тантаналы бер мәҗлес ясалды. Тарих материалын җыюда яхшы бер хезмәт итеп Кави Нәҗми төзегән «Кызыл Армия сафында татарлар, башкортлар» дигән зур мәҗмуганы алырга кирәк. Монда безнең кызыл фронтта катнашуыбыз мәсьәләсен өйрәнергә күп материал бирелгән.

III

Ф.Сәйфинең «Татар дине». Татарның статистика- этнографиясен өйрәнү. Этнографиягә телне корал итү тәҗрибәсе. ВПИның Шәрекъ бүлегенең этнография дәвере. Этнография бабында басылган, эшләнеп ята торган хезмәтләр. Бу бабта күргәзмәләрдә хезмәт.

Килик этнография бабына.

Гомумән, революциягә кадәрле бу фән бабында бик аз нәрсәләр эшләнде. Җөмһүрият игълан кылыну белән бу этнография бабында эшләр кызып киттеләр.

Бу бабта аерым китап булып чыккан нәрсәләрдән Фатыйх Сәйфинең «Татар дине»дер. Сәйфи бу әсәрендә төп мәсьәлә итеп татарларда хәзер дә калган шаманизмны алган. Элек ул борынгы ислам кабул иткәнче булган татарлардагы шаманизмны сөйләгәннең соңында, татарларның гореф-гадәт, халык әдәбияты буенча үзләренә махсус шаманизмнарын ачып бирергә тырышкан. Шиксез, бу әсәр – мөһим мәүзугъка язылган бер әсәрдер.

Моннан башка татар, башкорт статистик-этнографиясе белән Г.Шәрәф шөгыльләнеп килде. Аның «Кызыл шәрекъ» журналына бастырган «Русиядәге төрек халыкларының статистика вә этнографиясе» дигән мәкаләсе, «Татар-башкортлар» исемле брошюрасы. 1924 нче елның «Хуҗалык һәм хезмәт» журналының 1924 нче ел номерындагы «Союзный экономия әсасында районнарга бүлү һәм милли-этнографик момент» дигән мәкаләсе мөһим хезмәтләрдәндер.

Ләкин этнография бабында мөһим хезмәтләр ВПИның Шәрекъ бүлегендә бара. Монда өч ел буенча төрек-татар, угро-фин этнографиясеннән ике дәрес укылып килә. Бу дәресләрдә бер мө-

галлимнәр генә түгел, студентлар да материал җыю ягыннан катнашканга, бу яңа коллектив хезмәтләрдән хисапланырга тиештер. Бу фән бабында иң мөһим хезмәт – күргәзмә, выставка, музейлар өчен эшләнгән хезмәт булды. Җөмһүрият игълан кылыну белән фән бүлегенең тәшәббесе профессор Адлерның фикере вә бик күп татар һәм урыс этнографларының булышуы белән Казанда «Шәрекъ халыклары мәдәнияте күргәзмәсе» ясалды. Бу мөнәсәбәт белән бик күп материал җыелды. Күргәзмә өчен татар, рус телләрендә мөһим, гыйльми каталог бастырылды; бу каталогка мөтәхәсисләрнең татар, башкорт тормышы, мәдәнияте хакында мәкаләләре кертелде, фотография снимкалары бастырылды. Бу эш этнография бабында зур гына бер хәрәкәт ясады.

1922 ел Бөтенрусия авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә Татарстан этнографиясе почмагы ясау өчен бер секция ясалып, эшкә кереште. Татар халкының тормышын өйрәнү өчен берничә сәяхәт ясалды, күп кенә материал җыелды.

Быел, выставкадан кайтарылган нәрсәләр вә башка бик күп материал җыелып, Казандагы Мәркәз музейның «Татар этнографиясе бүлеге» ачылды. Бөтен Русиядә Казан музее татар коллекцияләре бабында байлыгы вә тормышның яңалыгы аркасында беренчелекне алды. Хәзерге көндә моның ике телдә гыйльми каталогы басылып чыкты.

Быел Парижда ачыла торган сәнгате нәфисә күргәзмәсенә дә Татарстан халык иҗади сәнгать әсәрләре, татар халкының матди мәдәниятен күрсәтүче әсәрләре белән катнашты. Шулай итеп совет хөкүмәте аркасында татар халкы бер мәдәни милләт буларак Европа сәхнәсенә беренче мәртәбә чыкты. Табигый, бу эш – Татарстан Җөмһүриятенең зур бер казанышларыннандыр.

IV

Татар теле бабында профессор Богородицкийның мөһим хезмәте. Татарның телен өйрәнүнең борынгы мәсьәлә булуы, хәзер шул эшнең өч мәүзугъ өстендә кызуы. Имля мәсьәләсе. Әдәби тел мәсьәләсе, истилях.

Тел мәсьәләсенә килик.

Бу мәсьәләгә килсәк, тел мәсьәләсе практик әһәмият алып килгән бер мәсьәләгә әверелгәненә күрә, бу мәсьәлә өстендә тагын да күп хезмәтне күрәбез. Бу эшкә дә бер татар эшчеләренең генә түгел, рус галимнәренең дә катнашын күрәбез.

Бөтен мәдәният галәменә мәгълүм, үзе Казанда торса да, телне тәҗрибә рәвешендә өйрәнүнең бөтендөнья масштабында зур

мөтәхәссисләреннән берсе профессор Богоридицкий Җөмһүрият игълан кылыну белән аның күпчелегенә яхшы бүләк бирде. Ул төрек-татар телләренең әсаслары белән әүвәлге шөгыльләрен тагын да кызулата төшеп, бу бабта (фонетика) мөһим бер әсәр вөҗүдкә китерде. Шулай ук икенче бер галим – Ашмарин да татар телендә төрткеләр кую мәсьәләсендә бер мөһим нәрсә язып, Мәгариф комиссариатына тапшырды. Беренче әсәр рус телендә, икенчесе ике телдә басылып таралдылар.

Татар фәнни әдәбиятының үз эчендә тел мәсьәләсе 5 ел эчендә тормыш белән нык бәйләнгән түбәндәге өч мәсьәлә өстендә күбрәк әйләнде, эшләнде:

1) Имля мәсьәләсе вә шуның белән нык багланган сарыф вә нәхү баблары;

2) тар мәгънәдә әдәби тел, аның киләчәге мәсьәләсе;

3) шуның белән багланган фәнни истиляхлар мәсьәләсе.

Беренче мәсьәләгә даир язылган гыйльми мәкаләләр, әсәр вә фәнни диспутлар бик күп; затән бу мәсьәлә үзе-үзен тарихлы, Насыйри тарафыннан нык кузгатылган бер кирәкле бабтыр. Моның тарихын белү өчен материалны бу бабта күп эшләгән, практик татар нәхү вә сарыфын беренче эшләүчеләрдән Галимҗан Ибраһимовның әле генә басылып чыккан «Имля, тел вә әдәбият мәсьәләләре» дигән мәҗмугасына кергән «Имля, хәреф мәсьәләсе » исемендә 1924 елда Мәскәүдә Бөтенрусия татар-башкорт мәгариф эшчеләренең икенче съездында укыган докладында табарга мөмкин. Ибраһимовның бу докладыннан күренә ки, имля мәсьәләсе татарның яңа мәдәнияте тарихы белән яшьтәш бер мәсьәләдер. Бу бабта татар фонетиклары: Г.Ибраһимов, Мөхетдин Корбангалиев, Җ.Вәлиди, Г.Шәрәф, Г.Алпаров, Габдрахман Сәгъди, Нугайбәк вә бик күп башкалар арасында, башлыча татар телендәге тавышлы авазлар хакында, моназаралар барды. Шулардан бер гөруһ 10-чылар, икенчеләре 6-чылар бер-берсе белән көрәштеләр. Ниһаять, соңгылары җиңү белән тәмам булды.

Имля мәсьәләсе өстендә көтелгән хәрәкәт сарыф вә нәхү мәсьәләләрен ныклап тикшерергә юл ачты дигән идек. Мәсәлән, «Безнең юл»ның 76 нчы номерында Нигъмәт Хәкимнең «падеж мәсьәләсе» дигән мәкаләсе шул мөнәсәбәт белән чыкты. Ул бу мәкаләсендә татар телендә падеж бармы, дигән бер сөальгә фәнни җавап бирергә маташа. Шул ук мөхәррир «Грамматика әсаслары» дигән мәкаләсе белән чыгып «Татар теленең эшләнүе», «Тел һәм тел фәннәре»нә даир сүзләрнең ике җәһәтеннән таснифләренә даир төпле генә мәгълүмат биреп узды. Корбангалиев вә Хуҗа Бәдигыйләр дә татар теленең практик грамматикаларын эшләгәндә шактый гына яңалыклар керттеләр.

Татар телчеләре имля, сарыф, нәхү белән генә калмадылар.

Алар тел мәсьәләсенә дә килеп җиттеләр. Төрле фикер-агымда булган кешеләр 5 ел эчендә бер фикер тирәсендә җыела алдылар. Нәзари кычкырышлар, мөназаралар, тел мәсьәләсе Татарстан Җөмһүрияте игълан кылыну белән нык хәятка багланып киткәч, татар теле – сөйләшә торган тел тирәсенә җыелдылар. Әдәби тел мәсьәләсендә электән бер юл тотып килүче Ибраһимов 5 ел эчендә тагы нык шөгыльләнеп килде. Аның «Пантюркизмның әдәби йөзе» дигән мәкаләсе гомуми тел мәсьәләсен бик каты тәнкыйттән гыйбарәт иде. («Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» китабында).

Ләкин тел мәсьәләсе хәл кылынып, татар зыялылары бер фикергә килсәләр дә, ул истилях мәсьәләсендә яңадан икенче төрле итеп кузгалып торды. Бу мәсьәлә үзе бер гыйльми әсас, практик бер мәсьәлә булганлыктан, бу хакта бераз тукталырга кирәк була.

Безнең матбугат, каләм дөньясы бу мәсьәләгә күптәннән бирле гаять зур әһәмият биреп барды, чөнки теләсә ничек вә теләсә нинди истилях куллану кебек бер мөдһиш анархия бетәргә тиеш иде.

Үткән еллар аеруча кызган бу мәсьәлә быел инде нигез буенча нык чишелде. Быел Казанда журналистлар клубында бөтен Казанның әдәбиятчылары җыелган киңәштә (сентябрь 16) бу хакта мәгълүм тезислар кабул кылынды. Хәзер бөтенләй урыслашу ягындагы Г.Вәлиди агымы, шулай ук иске гарәплекне сакларга азапланган уң агым да җиңелделәр. Мәсьәлә урта юлга төште (бу хактагы тезислар Мәскәүдә дә кабул кылындылар).

V

Татарстанның икътисадый хәлен өйрәнү. Статистика бабында хезмәтләр. Музейда матурлыкны өйрәнү. Антропология бабында хезмәтләр. Коллективларның мөһим хезмәтләре. Өлкәне өйрәнү. Нәтиҗә.

5 ел эчендә Татарстанның икътисадый хәлен өйрәнү мәсьәләсе бабында да шактый күп хезмәтләр ителде. Русча «Хезмәт һәм хуҗалык», «Безнең юл», журналлары бу бабта күп кенә эшләделәр. Татарстанның икътисадый җәгърафиясен эшләү бабында мөһим әсәрләр хәзерләп ятучылар бар.

Статистика бабында янә Ермолаев иптәш идарәсендә «Сан алу бүлеге» күп кенә эшләп, нәшриятын да алга җибәрергә муаффәкъ булды. «Татарстан цифрларда» журналы һәм бу идарәнең

бик күп башка нәшрияты – Татарстанны өйрәнү бабында зур хезмәтләрдер.

Музей, матурлыкны өйрәнү бабына чыгып баручы «Музей хәбәрләре» хакында мин озын сөйләп тә тормыйм. Б.М.Дульскийның бу бабтагы хезмәте чит илләр матбугатының күзенә алындылар. Бу мәҗмугаларда Русиянең зур галимнәренең мәкаләләре булуы Татарстанга мактанырга юл бирәдер.

Сәнаигы нәфисә бабында эшләүче, Казанда тәрбияләнгән профессор Борис Денекеның Татарстан нәшрият комбинаты тарафыннан Дульский карамагында гаять матур вә нәфис басылган «Шәрекъ сәнагате» исемендәге әсәрен шәрекъ сәнагатенең миниатюрасы бабында Русиядә моңарчы чыккан беренче әсәрләрдән хисаплана. Бу әсәр дә Татарстан Мәгариф комиссариатының тәкъдиме белән эшләнгән иде.

Үзе табигыятьтән булып та, иҗтимагый гыйлемнәргә бик якын булган антропологияләр фәне дә Татарстан Җөмһүрияте игълан кылыну белән доктор Сахаров, доктор М.Н.Никольский эшләми башлагач булган торгынлыгыннан чыкты. Бу бабта Б.Ф.Вишневский Казаннан киткәнче күп кенә эшләде. Бу бабтагы мөһим мәкаләсен «Татарстанның җәгърафи мәҗмугасы»на бастырды. Үзе тәәсис иткән «Тип-антропология җәмгыяте» дә үзе Казанда чакта күп кенә бу гыйлемгә хезмәт итте.

Без хәзер гыйльми коллективларга күчәбез.

Болар хакында ахырдан сөйләвебез, гыйлем бабында коллектив хезмәткә әһәмият бирмәүдән түгел, бәлки һәммә аерым шәхесләрнең дә коллективлар тибында эшләүләрендәдер. Шуның өчен без бу коллективлар хакында аз гына сөйләп узабыз. Болар хакындагы тәфсилле мәгълүмат аерым мәкаләләрдә булса кирәк.

Башлап РКП(б)ның Өлкә комитеты хозурындагы партия тарихын өйрәнү бюросын алыйк. Бу һәйәтнең төп эше безнең өлкәдәге революция хәрәкәтен өйрәнүдән тора. Шуның өчен дә өлкәбезнең яңа дәвер тарихын өйрәнү бабында бу бюроның әһәмияте бик зурдыр. Бу бюроның иң зур муаффәкыяте тирәсенә бөтен революция көчләрен һәм Фирсов шикелле сул галимнәрне җыя алуындадыр. Бу бюро үзенең нәшрият эшен дә тәрәкъкый иттерә алды. Аның «Революция юллары» исемендәге мәҗмугалары гаять мөһим мемуар һәм эшләнгән тарихи мәкаләләр белән тулыдыр. Идел буеның мәркәзе шикелле бер мөһим өлкәнең революция тарихын язучы бу мәҗмуга бөтен Русия тарихы өчен дә гаять кадерле бер мәҗмугадыр. Шул ук истпарт бюро тарафыннан быел яңа бер тәшәббес тә башланды. Ул исә өлкәнең чехлар вә учредилкачылар заманын тикшерүдер. Бу бабта ул инде, «Казан өчен көрәш» исеме белән бер мәҗмуга да чыгарды. Без бу мөһим

нәрсәгә аерым бер әһәмият бирәбез. Ләкин бу бюроның басылган әсәрләре әчендә татардагы революция тарихына даир әсәрләрнең бик аз булуы җитешсезлектән хисапланырга тиеш. Ләкин, ишетүебезгә күрә, бу бабта да хәзер адымнар атланган. Хәзерге көндә истпарт кулында күп кенә басылу нәүбәте көтеп тора торган хәзер әсәрләр дә бар. Шул җөмләдән өлкәбездәге революция тарихыннан язылган Семенов, Грачев әсәрләрен алырга кирәк, ләкин хәзер басылырга бирелергә торган «В.И.Ленин һәм татар җөмһүрияте» дигән Ходоровский вә башкаларның хатирәләреннән гыйбарәт бер мәҗмугага аерым әһәмият бирәбез. Әгәр бу мәҗмуга чыкса, җөмһүрият тарихының төп мәнбәгы булачактыр. Бюроның хезмәтләренең әһәмиятлесе – аның революциягә материал бирүче архивларны тәртипләве вә өйрәнүедер. Бу мәдәни роль табигый фән бабында бер дә онытылмаячактыр.

Татарстанда 1921-1922 елларда тагын бер мөһим коллектив эшләп килде. Ул да булса, Мәркәз архивының гыйльми җыелышларыдыр. Бу җәмгыятьләрдә дә өлкәнең тарихына даир күп докладлар укылды. Шуның өчен дә выставканың «Татарстан халыкларының физический типлары» Семеновның «Авыл халкының җиһан сугышына мөнәсәбәте» дигән докладлары мөһим генәдер.

Өлкәне өйрәнү бабында 1923 елда тәэсис ителгән «Татарны өйрәнү» җәмгыяте шактый гына эшләп килде. Аның өлкәне өйрәнү өчен җибәрелгән экспедицияләре, аның һәр атна булып торган гомуми җыелышларындагы тарих, статистика, этнографиядән докладларын хәтергә алырга кирәк. Шушы арада аның мөһим фәнни мәкаләләре белән «Вестник» исемендәге журналы чыкты; тагын шушы арада аның «Труды» исемендәге калын мәҗмугасы чыга башлаячак.

Шулай ук Казанда 40 еллык тарихлы Археология җәмгыяте дә эшләп килә. Моның хезмәтләре дә күп кенә. Бу ике җәмгыять бергәләшеп, контактта эшли башладылар. Бу мөһим карт җәмгыятьнең дә журналы бер-ике елдан бирле чыгарылмый торганнан соң Җөмһүриятнең 5 еллык бәйрәме вакытында чыга башлаячактыр. Хәзерге көндә бу җәмгыять үзенең эшен өлкәдәге революция хәрәкәтләрен өйрәнергә борды, ләкин шуның белән бергә археология вә этнографияне дә ташламый алып бара.

Бу ике җәмгыять тә – хәзер өлкәне өйрәнү бабында төрле милләт галимнәренең кардәшләрчә берләшеп эшли торган бер җыеннарыдыр.

Татарстанны өйрәнү эше моңарчы бераз кустарьларчарак иде. Хәзер моңардан чыгып, оешкан бер хезмәт рәвешен алды; 1925 нче елның маенда Татарстан Халык Мәгариф комиссариатының Гыйльми Үзәге янында «Өлкәне өйрәнү бюросы» төзелде. Хәзер

җөмһүриятне, күршеләрне тикшерү, өйрәнү, материал җыю, җыелганны тәртипкә салу, төрле гыйльми җәмгыятьләрнең эшләрен берләштерү һәммәсе менә шул бюро кулында булачак. Бу бюро инде үзенең зур бер эшен эшләде дә, Совнаркомның тапшыруы буенча, җөмһүриятнең 5 еллык бәйрәменә карап «Татарстанны өйрәнүдә материаллар» исеме белән зур, кыйммәтле (20 табаклар чамасы) мәҗмуга төзелде. Монда Казанның рустан, татардан, чуаш-чирмештән булган галимнәре, профессорлары – һәммәсе катнаштылар. Өлкәне өйрәнүдә бу зур ярдәм булачак.

***

Санасаң, күпкә китә. Бик кыскача әйткәндә, Җөмһүрияттә биш ел эчендә менә шулар эшләнде. Ләкин әле бу хезмәтләр басылып бетмәгән, гражданлык сугышлары, дәһшәтле ачлыклардан соң килгән аз форсатта эшләнде. Соңгы ел ярым аеруча күтәрде. Хәзер шундый бер гыйльми, әдәби үсү заманына кердек ки, берничә ел эчендә бездә гыйльми хезмәтләрнең бик нык көчәеп, тирәнәеп китүләрендә шөбһә юк.

Моңарчы күбрәк таркау материал җыелды. Хәзер инде шул таркауларны оештыру, системага салу башланачактыр. Барыш шуны күрсәтә.

(Биш ел эчендә. - Казан, 1925. - Б.141-152).

баб – өлкә
гарби – көнбатыш
тәәссеф – үкенеч
мәәюс – өметсез
икътидар – сәләт
әмре шаһанә – югарыдан килгән фәрман
дарелфөнүн – университет
нашире әфкяр – матбугат органы
мәҗмуга – җыентык
истигъмаль – куллану
маһият – асыл
җәнүб – көньяк
даир – караган
мөназара – бәхәс
гаид – бәйле
татбикъ – яраклаштыру
мөндәриҗә – эчтәлек
игътираф – тану
мөкаддимә – кереш
вөҗүд – барлык
мәдхәл – кереш
мәнбәгъ – чыганак
әсас – нигез
мөәррих – тарихчы
муәффәкъ – ирешү
әлхасыйл – нәтиҗәдә, кыскасы
тәшәббес – инициатива
гыйлавә – өстәмә
һөҗүви – сатирик
мәүзугъ – тема, мәсьәлә
мөтәхәссис – тикшеренүче
истилях – термин
затән – нигездә
тасниф – әсәр, хезмәт
нәзари – теоретик
мөдһиш – куркыныч
сәнаигы нәфисә – нәфис сәнгатьләр
тәәсис итү – оештыру, нигезләү

Развитие исторической литературы у тюрко-татарских народов

Этот вопрос в общем масштабе был блестяще выяснен предшествующим докладчиком, академиком Бартольдом, и на мою долю остается лишь изложить ход развития истории тюрко-татарских племен, выполненный трудами самих тюрко-татарских ученых. Так как предоставленное мне время довольно ограничено, я смогу только набросать некоторую схему.

Прежде чем приступить к докладу, я считаю необходимым предупредить, что я буду касаться лишь тех произведений по истории тюрко-татар, которые написаны тюрками Советского Союза, и тех, которые написаны под некоторым влиянием западноевропейской исторической науки. Последнюю оговорку я считаю нужным сделать потому, что даже в XIX столетии среди тюркских племен России существовали историки, которые писали свои исторические произведения или мемуары, подражая старым восточным традициям, не пользуясь западными историческими пособиями и источниками. К таким, например, может относиться «История Шекинского ханства» Латиф Эфенди, «История болгар и Казани» Хусаина Амирхани и многие узбекские произведения. Однако, о тех историках, которые написали свои труды под большим влиянием старых арабско-персидских традиций, но использовали для своей работы русские и европейские источники и исторические труды, я, конечно, говорить буду (Таковы Бакиханов, Марджани, Мурад Мекки).

Появление у российских тюрков исторических произведений (под влиянием европейской или русской историографии) связано с их возрождением, под влиянием европейской цивилизации, в первую очередь, это возрождение началось у тех тюркских племен, у которых раньше всех начал развиваться капитализм и господствующим классом сделалась национальная буржуазия. Таким народом среди российских тюрков являются приволжские татары, которым способствовали их нахождение на старинном торговом волжском пути и очень раннее соприкосновение с европейской культурой через русских. Вот почему еще в начале XIX

столетия там появился первый историк-татарин Ибрагим Хальфин, напечатавший в 1822 году сборник исторических анонимных рассказов «Жизнь Джингиз-Хана и Аксак-Тимура», к которому он приложил весьма интересное предисловие, призывающее татарское население к собиранию погибающих исторических рукописей и народной словесности исторического характера. Этим же деятелем при руководстве известного ориенталиста, профессора Френа было напечатано, руководствуясь научными методами, «Родословное древо тюрков» Абульгазы Багадур хана, в 1824 году. Однако, в татарском мире мы находим некоторый застой в области развития исторической мысли, приблизительно до 60-х годов. Но зато в сороковые годы среди российских тюрков жил и писал другой знаменитый человек – азербайджанский историк Бакиханов, написавший на персидском и русском языках монографию по истории Закавказья, под заглавием «Гюлистан Ирям». До сих пор в азербайджанской исторической литературе ничего не написано по поводу этого поистине интересного произведения и его автора, хотя некоторые из русских и тюркских историков Азербайджана и любили пользоваться этим трудом при составлении своих очерков. Бакиханов владел не только восточными, но и русским языком. Ему были известны такие русские историки, как Карамзин, и некоторые античные авторы, которые так или иначе касались в своих трудах прошлого этой страны. Автор «Гюлистан Ирям», по сравнению с другими тюркскими историками, как например, с татарским Марджани, является вполне европейцем, и образ мысли у него также напоминает нам европейских и русских историков.

Эпоха Николая первого не была благоприятна для развития тюрко-татарской литературы вообще, и исторической, в частности. Список книг, изданных на различных восточных языках, и в том числе на тюрко-татарских в Казани, составленный ориенталистом Дорном, ясно указывает на такое явление: в то время, как в огромном количестве выпускались Коран, шаблонные религиозные книги, различные молитвенники и талисманы, мы видим в списке весьма ограниченное количество более или менее научных и оригинальных книг. Но когда, после смерти этого императора, реакция ослабла и читающая Россия стала чувствовать себя немного легче, то это оживление отразилось и на российских тюрках Поволжья. Кроме того, наступательная политика российского правительства на Среднюю Азию также действовала и на татарский господствующий класс, а именно на буржуазию, которая имела торговые дела с этой Средней Азией и была посредницей русской торговли. Вот почему, когда русский капитал

начал действовать без посредства татар, то в 60-х годах XIX столетия началось среди приволжских татар пробуждение и религиозно-реформационное движение. История Западной Европы нам указывает, что у всех народов в такие моменты возрождения появляется интерес к родной старине. Такое же явление мы замечаем и у приволжских татар, у которых скоро появился замечательный человек - Марджани (1818-89). Марджани известен в мусульманском мире как реформатор и богослов, но он немало трудился в области теории истории, истории ислама, Средней Азии и, в особенности, в области истории восточно-европейских тюрко-татар. Его перу принадлежит многотомная историческая работа «Вафиятуль аслаф», «Пролегомена» (Мукаддима), которая была издана отдельно, а остальные тома до сих пор не могли увидеть свет. Эта «Пролегомена», подобно «Мукаддима» Ибн Хальдуна, посвящена вопросам классификации науки и выяснению места истории среди других «наук традиций» (улуму наклийа). Марджани, подобно Ибн Халдуну, в этом труде останавливается на выяснении факторов истории, придавая огромное значение географическому фактору, однако, мельком касается и роли экономики и жизни человеческих обществ. «Пролегомена», без сомнения, написана под большим влиянием Ибн Халдуна. Как я старался показать в одной из своих статей, некоторые места целиком списаны с него; однако, Марджани как восточный ученый XIX столетия, во многом пошел вперед, он весьма критически относится к средневековым наукам, к алхимии, науке о таинственном значении букв (улуму асирульхуруф) талисманам (ильмуссихр) и др., выдвигая на их место ряд новых естественных наук. Марджани был первым тюрко-татарским историком России, вступившим на европейскую арену.

На VI Археологическом Съезде 1874 года в г. Казани он выступил с докладом на тюрко-татарском языке по истории булгар и татар, в котором он старался выяснить до того неизвестные имена булгарских ханов. Этот доклад Марджани, который вошел впоследствии в «Труды Съезда», является первым опытом систематического изложения истории приволжских тюрков.

Одним из ранних исторических сочинений этого автора является, посвященное истории Средней Азии «Урфатуль-хавакин ли Арфат аль-хавакин». Однако, самым важным и систематически изложенным трудом является двухтомная «Мустафад аль-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар». Первый том этого поистине замечательного труда посвящается истории хазар, булгар, тюркских кочевников Восточной Европы, Золотой Орды, среднеазиатских тюркских ханств, Казанского, Касимовского Астраханского и

Крымского ханств. Второй же том является опытом истории приволжского татарского и башкирского духовенства и мечети, и этот последний том до сих пор является единственным источником по истории татарской культуры после завоевания края Москвой; он написан на основании источников, собранных самим автором (предания, частные письма, летописные рассказы, написанные различными лицами, и.т.д.).

Второй же том написан на основании данных арабских, персидских и чагатайских источников, большинство из которых автор прочитал в бытность его в Бухаре и Самарканде. Однако, ему не были чужды и русские летописи, и другие русские памятники. Этими источниками, не владея языком, он мог пользоваться по переводам русских ориенталистов и особого переводчика из татар. Но Марджани не были чужды труды некоторых русских ориенталистов. Например, я в одной статье старался доказать, что ему было известно «Исследование о Касимовских царях и царевичах» - профессора Вельяминова-Зернова, откуда Марджани взял большую часть сведений о Касимовском ханстве. Это двухтомное произведение Марджани важно еще и в том отношении, что оно написано на тюрко-татарском языке. Я не буду входить в детали произведений Марджани и в научную оценку их, такой разбор уже дан в тюркской литературе, особенно в изданном при моем, Хасан – Ата Абаши и Заки Валиди ближайшем участии юбилейном сборнике «Марджани».

Хотя самое важное и большое сочинение Марджани «Вафийат аль-аслаф» и не было издано, однако, русский ученый мир достаточно оценил этого историка; хотя русские ученые и не дали полного его разбора, но все же считали его серьезным ученым, дающим много нового. По этому вопросу имеется весьма ценная статья З.Валиди «Марджани в русской литературе», а потому, отсылая интересующихся к статье, я хочу завершить о Марджани, роль которого в области татарской исторической мысли была одной из замечательнейших.

С одной стороны, в то время между татарскими учеными и русскими ориенталистами установилась тесная связь, которая в последствии, после смерти Марджани, надолго была прервана. А с другой стороны, в это самое время мы видим небывалый подъем интереса со стороны татарских ученых к исторической науке вообще, к истории тюркских племен в частности. Начиная от шестидесятых годов до смерти Марджани, существовал ряд татарских ученых и любителей, занимавшихся историей. Ученик Марджани, Хусаин Фаисханов, отправился в Петербург и, сделавшись лектором Восточного факультета, всю свою жизнь рабо-

тал вместе с Вельяминовым-Зерновым, помогая ему в трудах по собиранию и чтению документов по истории Касимовского ханства и Крыма.

Даже в архиве Марджани, который погиб в 1922 году во время пожара, я видел составленный им и Фаисхановым проект открытия татарского университета по западному образцу. В то же время друг Марджани, Хусаин Амирхан, занимался собиранием татарских преданий и впоследствии выпустил книгу по истории булгар и Казани. Наконец, друг Марджани, купец Мухаммеджан Аитов, помогал Марджани в чтении русских книг по истории родного ему народа и, наконец, сам написал сборник исторических очерков, рукопись которой погибла в начале революции. Кроме того, когда жил и писал свои замечательные произведения Марджани, совершенно независимо от него работал татарский просветитель и светский человек, энциклопедист и педагог Каюм Насыри (1824-1904).

Насыри не был историком-специалистом, он скорее был лингвистом и этнографом, но попутно, как энциклопедист иногда писал и на исторические темы. Главная заслуга Насыри в области истории приволжских татар не в систематическом изложении истории своего народа, не в отдельных монографических произведениях, а в собирании фактов и исторических документов. Во-первых, такие материалы он помещал в периодически ежегодно издаваемых им настольных календарях на татарском языке. Насыри помещал там исторические песни татарского народа, предания по истории быта (например, одежды, утвари, обычаев и нравов), некоторые критические статьи, направленные против Марджани, которого он не очень долюбливал. Кроме того, Насыри собрал довольно большое количество материала по истории татарской литературы конца XVIII и начала XIX столетий и поместил их к концу своего «Фаваких аль-джаласа».

Но к середине XIX века число татарских начальных школ росло: в 1860 году на 442349 душ татар мусульман было 408 мектебов, в то же время во всей России в местах, подведомственных Оренбургскому Духовному Собранию, существовало 1859 мектебов. Грамотность у татар также была довольно высока, особенно среди господствовавшего тогда буржуазного и мелкобуржуазного городского населения. Поэтому путешествовавший в 1843 году немец-барон Гакстаузен мог сказать про татар, что «татары обладают большими умственными способностями, но ислам допускает их развитие лишь до известной степени, у них

много школ, они почти все умеют читать и писать, и считать на русских счетах, у них даже есть некоторая литература, которую они изучают ревностно, и я убежден, что если бы этот богато одаренный народ принял христианство, то он не только стал бы одним из первых цивилизованных народов, но распространил бы христианство и цивилизацию по всей Азии» («Приволжские города в Казанской губернии издание Казанского статистического комитета. 1892 г. Стр. 169).

Этим мы заканчиваем свою статью. То, что описано здесь, подготовило татарское общество к дальнейшему развитию. Рост капитализма в России, реформы 1860-х годов – все это подготовило почву для перемен в татарской буржуазии в области идеологии. Вот почему с середины XIX столетия у татар появляется реформационное движение. Совместно с этим движением возникло параллельно и другое движение, известное под названием «новометодизма», которое боролось за преобразование школы, способы преподавания в них и за чистку ее от пережитков феодальной идеологии, или схоластики.

В 1890 годах это движение, можно сказать, одержало полную победу.

В то же время, с середины XIX столетия, благодаря росту капитализма классовая дифференциация у татар стала еще сильнее. Классовые противоречия, которые начались задолго до этого времени, также росли. С одной стороны, начала организоваться буржуазия, с другой, промежуточные радикальные элементы. Но татарский зародившийся пролетариат стал работать совместно с русскими братьями по классу и постепенно вступил в ряды социалистических организаций. Таким образом, после этих кратких замечаний становится понятным активное участие всех классов татарского общества со специфическими своими организациями и программами (татарские с.д. большевики во главе с Х. Ямашевым, «Мусульман иттифаки», как партия крупной татарской буржуазии и помещиков, с.р. мелкобуржуазное движение с Туктаровым во главе), с которыми они выступили в революции 1905 года.

(Материалы по изучению Татарстана: Сборник статей. Выпуск II. – Казань, 1925 – С.71-111).

Насыйри чын гыйлем-фән бабында

XIX гасырның урталары – татарларда схоластиканың иң куәт алган бер замандыр. Бөтен инсаният галәменә уртак булган схоластиканың «фәннәр – голүме диниянең колыдыр» шигаре бездә иң көчле рәвештә хөкем сөргән чаклары – шушы дәвердә. Александрлар заманында көчләнеп киткән, XVIII гасырның дәвамы, миссионерлыкның азу ярган чаклары – шушы замандадыр. Шуның нәтиҗәсе булган татарлардагы дини тәгассебнең көчләнгән чаклары да – шушы XIX гасырның урталарындадыр.

«Мән тәмәнтака тәзәндак» лозунгасына кадәр килеп җитеп, хәтта мантыйкка һөҗүм башланган заман да – шушы дәвердер. Менә шушы идеалларның оясы булган шул кадимә мәдрәсәләрендә җитешкән Насыйридан чын гыйлем-фәнгә Яурупадагы мәгънәсе белән хезмәтне көтү дә гаҗәп бер эш булыр иде; аннан бу эшне таләп кылу да бер кәрамәт сорау белән мөсави булыр иде... Ләкин, шулай була торып та, без Насыйрида чын гыйлем вә фәнгә, хезмәткә омтылуны күрәмез. Бу эше белән Насыйри үз заманасының әһеленнән берничә адымнар өсткә күтәрелә, дәһилык дәрәҗәсенә барып җитәргә якынлаша...

Әгәр Ибраһим Хәлфин татар галәмендә беренче мәртәбә тар пәрдәне җыртып чыгып, үзенең хан ярлыгларына даир мөляхәзә вә тәрҗемәсен Венадагы ... * мәҗмугасенә бастырса, әгәр аннан бер гасыр соң Мәрҗани 1874 елда Казанда җыелган археология съездында рус вә Яурупа мөстәшрикъләре алдында үзенең доклады «Галәләтез-заман»ын укыса, әгәр аның шәкерте Хөсәен Фәезханов Мәркәз Академия мәҗмугаләрендә Болгар ташлары хакында үзенең яңа кәшеф иткән фикерләрен сөйләсә, безнең Насыйри да Яурупа вә рус галәменә татарның фольклоры – халык әдәбиятын җыю, аны классификация ясау, русчага яхшы тәрҗемәсен бирү, ниһаять, татарның мифологиясен бер системага салып, мөкәммәл русча бер мәкалә бирү кеби хезмәтләрне эшләде.

Әгәр Мәрҗанинең гарәп галәменә хосус итеп язган «Галәләтез-заман»ы үзенең әсаси тарзы фикриясе ягыннан мөселман шәркынең IX-XII гасырлар әсәрләрендә аермасы булмаса, без инде, үзе әйткәнчә, Насыйрида «когда я стал к делу относиться научно» дигән аңлы, соз-

---

* Текстның оригинал нөсхәсендә шул рәвешчә буш урын калдырылып, җыентыкның исеме күрсәтелмәгән.– *Төз. иск.*

нательный принцибыны очратабыз. Вакыйган, Насыйри татарны татар булуы ягыннан тикшерә алды һәм «я буду говорить о татарине, как о татарине» диде. Татарның хәятын каплап алган, Гарәбстаннан килгән пәрдәне ул күтәреп карады да, аның астыннан үзенең табигый шаман дине, табигый хәяты белән татарның игътикадын, хәятка карашын, дәрәҗәи мәдәниятен үткен күзле кешеләргә күрсәтә алды. Бу бөек русча әсәрләрен Насыйри бер газета мәкаләсе яисә бер әкият язган кеби тиз язмады. Аның өчен ул 30-40 ел, балалык чагыннан алып, «эшкә гыйльми яктан карый башлаганына кадәр» эшләде. Бик күп халык җырлары, йөз иллегә якын мәкаль, табышмак җыйды. Шушы озак еллар эшләүнең нәтиҗәсе буларак Бәдигый һәм Гаффаров мәкаләләрендә сөйләнгән* аның өч русча мәкаләсе вөҗудкә килде.

Насыйриның бу халык әдәбиятын җыю һәм аларга классификация ясау һәм татарның этнографиясенә хезмәте – чын гыйльми хезмәт иде. Аңарчыга кадәр татар халык җырлары, табышмак, мәкальләре җыелмаган, бер мажар галиме тарафыннан бу бабта тәҗрибә булса да, искергән иде. Бу әсәрләрне җыюы белән Насыйри татарның фольклорын, этнографиясен өйрәтүгә материал бирмәде, бәлки гомум халыкларның иҗаты хакындагы һәм гомуми этнография фәннәренең тулмаган урыннарын тутырды. Ләкин Насыйриның бу халык әдәбиятын җыю эшендә бер ноксаны булса да, ул да аларның кайдан, кем тарафыннан, кайчан әйтелгәннәре һәм аларның татар арасындагы вариантлары хакында мәгълүмат бирмәведер.

Насыйри татар тарихы бабында бер систематический әсәр бирмәсә дә, материал бирүе җәһәтеннән шактый зур хезмәт итте. Аның бу хезмәте безнең тарихи ганганә вә җырларымызны җыюда һәм XVIII-XIX гасырның башлары кеби караңгы, мәнбәгасез калган дәверемезнең тарихына даир материал бирүендәдер. Аның бу ике хезмәте календарьларында булды. Насыйриның заманында альманах яисә гыйльми журнал урынын тоткан календарьларының һәркайсы елларга гаид булганнарында Насыйри кызык-кызык кына материаллар бирде. 1883 елдагысындагы «Алып адәмнәр» дигән мәкаләсен (бу ганганәне ул «Фәвакиһел-҃өләяса»сында да сөйли), кайсы календарьларындагы тарихи җырлар вә хикәяләр** һәм XVIII-XIX гасырлардагы мәшһүр муллалар, галимнәр, түрәләр, татар арасында «кыйтат җилән», «каеган читек» кеби нәрсәләрне ихтирагъ кылучылар, бәгъзе борынгы шагыйрьләрнең тәржемәи хәлләрен язуын алсак җитәр.

Насыйриның дәреслек яисә уку китабы итеп язган өч җилдлек «҃Җәгърафияи кәбир»е дә шактый мөһим гыйльми мәкаләләрне эченә алган, мәсәлән, шул ук әсәрнең икенче җилдендә «Мисыр хакында әһле ислам мөәррихләренең сүзе» дигән бер озын гына мәкаләсе бар.

---

* Бу мәкаләдә Насыйриның гыйльми хезмәтләре хакында кыска язарга уйладык.

Бу мәкаләсендә Насыйри ислам тарихчыларында Шәйхе мелла Җәлял әс-Сиюти, Ибне Зәүлак, Ибне Мөтәввеж, Әл-Кинди кеби затларның Мисырга даир әсәрләреннән истихраж итеп, бу урта гасыр ислам сәйрендәге борынгы Мисыр асаре гатикасы хакында сөйли. Бу әсәре белән Насыйри Шәрекънең дә борынгы Мисырга әһәмият биргәнлекләрен белдерә. Дөрест, Насыйри бу бабта эре специалист түгел, ләкин, һәрхәлдә Русия тупрагында, гарәп мәнбәгъләреннән алып, борынгы Мисырның асаре гатикасыннан хәбәр бирү эше беренче мәртәбә Насыйри тарафыннан эшләнде.

Әлхасыйль, чын гыйлемгә, гомум инсаният мәдәниятенә хезмәт эшендә дә Насыйри хезмәт итте. Ул бу хезмәте белән соңра киләчәк татар галимнәренең алдан килүчесе (предшественник) ролен ала алды.

Насыйриның чын гыйлемгә хезмәте фольклор, этнографиядә, тарих бабында гына түгел, аның иң зур гыйльми хезмәте – татар филологиясе бабындадыр. Ләкин бу мәсьәләләргә даир мәҗмугамездә әрбабы тарафыннан мәкаләләр булачактыр.

(Каюм Насыйри мәҗмугасе. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. –Казан: ТССҖ нәшрияты, 1922. –Б.146-149.)

бабында – өлкәсендә
инсаният – кешелек
голүме диния – дини гыйлемнәр
шигарь – лозунг
тәгассеб – фанатизм
«мән тәмәнтака тәзәндак» – мантыйк белән мавыгучы – зиндыйк
кадимә – иске
кәрамәт – әүлиялык, гадәттән тыш гамәл
мөсави – тигез
даир – багышланган
мөляхазә – тикшерү
мөстәшрикъ – Шәрекъне өйрәнүче галим
кәшеф – ачыш
мөкәммәл – камил
әсаси тарзы фикрия – нигезле фикерләү ысулы
вакыйган – чынлыкта
хәят – тормыш
игътикад – инану, иман
дәрәҗәи мәдәният – мәдәният дәрәҗәсе
уларак – буларак
вөҗүдкә – барлыкка
маҗар – венгр
ноксан – җитешсезлек
ганганә – риваять
мәнбәга – чыганак
ихтирагъ – уйлап чыгару
җилд – том
мөәррих – тарихчы
истихраж – файдалану
сәйрендә – карамагында
асаре гатика – тарихи истәлек
әлхасыйль – кыскасы
әрбаб – белгечләр

**1881 ел календаренда Насыйри «Шыгали ханның Казаннан чыгып киткәне», «Әмә тавы, Кабан күле» хакындагы шигырь һәм мисалларны сөйли.

Газиз Гобәйдуллинның хикәяләре

Вәсвәсә

Сабир ул симез генә кеше иде. Ул зур бер фирмада доверенный булып хезмәт итә, күп кенә жалованье ала иде. Ул диндар кеше, мәдрәсәдән дә «Гакаид» укып чыккан кеше. Ул үзен бик матур дип тә йөри; аның сары мыегы, сары сакалы белән кушылып, щетка төсле, һәр йоны аерылып тора иде. Ул чирбик кими, кисә дә, мөселман читекчеләре эшләгәнен, йомшак табанлысын кия иде. Аның тәрәкъкыйпәрвәрлеге шуңарга мәсах җаизлеккә ышануга кадәр бара иде. Ул үзе шәкерт вакытта урысча да укыган, шуңарга күрә үзен «зөлҗенахәен» кеше иттереп фараз кыла, әмма татар гәзитләре укырга тәнәззел итми иде. Ул кичләрдә, озын төннәрдә китап моталәга кыла, «Мохтасар»ны «Китабел-һибә»гә кадәр елына өч-дүрт мәртәбә укып чыга иде. Ул намазның мотахассисе иде: тәһарәт алганда, ә һәрбер әгъзасын юганда аерым догаларын да калдырмый, тәкбире тәкримәдә бармакларын үрдәк аягы күк ера иде, әттәхиятта аягын бик үрә иттереп, кыстырып утыра белә иде. Ләкин ул күптәннән бирле бер бәлагә мөбтәла булган иде ахрысы. Докторлар никадәр син таза дисәләр дә, үзенә ютәл зәхмәте булганына иман иткән, шуңарга күрә, артык күп ашарга яратмаса да, көн саен дүрт чи йомырка әчми калмый иде.

Аның башындагы бу авыру быел яз тагын да куәтләнде, какрыгы яшелләнә, төннәрдә тын алуы уңайсызлана күк тоела башлады. Дүрт елдан бирле әчеп килә торган гваякульны быел тагын да арттырып каба башлады. Менә бу авыру аны быел берәр айга кымызга барырга да мәҗбүр итте.

Матур су буендагы башкорт авылы аңарга бик ошады, ләкин мондагы авыруларның күплеге аңар яңадан шөбһә салды: бит ул ютәл авыруы яман нәрсә; бик йога бит ул, ашарга каян алырга?

Гаҗәп бит ул җитешмәгән баш: ул пешмәгән карбыз күк нәрсә... Ул баш бервакытта да үзе генә уйлый алмый, аңа һәрвакытта, авыр йөккә перәшкә ат җигәргә кирәк булган күк, чит баш васитасы белән уйларга кирәк була; шуңарга күрә дә ул шул авылдагы докторга барып, аны йөдәтеп вәсвәсәсен сөйләде. Шуннан соң ул ашау-әчу турысында да шикләнеп ашый башлады.

Ләкин әле бу авылда тагын бер читенлек бар: монда бит карак ифрат күп булырга кирәк. Акчаны кая куеп тотарга? Яшереп калдырсаң да уңайсыз: акчасы бар дип кереп үтерсәләр? әгәр акчаны кирәк кадәр алмасаң, авырып китеп, шәһәргә кайта алмасаң, акча каян алырсың?..

Кое суы, кое суы! Монда Сабир әфәнде тәһарәт ала алуын да, әмма аның бит арулыгы шикле?! Ихтимал анда бер-бер зур хайван төшеп үлгәндер?

Әле анысы алай, әмма ул кичә кич белән гаҗәп бер нәрсә сизде: ул һәрвакытта намазда кыйраәтне ялгыш укый икән! Ихтимал, ул үз гомеренә «вәләззалин»не өч әлиф микъдары сузмагандыр... Менә бәла тагы! Фарыз үтәп бурыч төшергәндә, имеш, важипне калдырып гөнаһлы бул! Әгәр тәрки-важип гөнаһи кәбаирдан булып, гөнаһи кәбаирда дәвам көфер булса... Каян килә тагын аңарга мондый вәсвәсәләр... Чынлап та, әллә аның игътикады таза түгел микән? Әгәр ул ялгыш игътикад белән зиндикъ булган булса?..

Менә кыйбла ягыннан җил исеп, авылны тәмле каен исе белән тутырды. Кояш капланды, көн саргайды... Кыйбла ягыннан чыккан кара болыт бөтен күк йөзен тутырып, җирне дерелдәтеп, яшен яшьнәтеп, авыл өстенә һөҗүм итте. Кырдан көтүләр юк тузанны кузгатып, кайтып җиттеләр, тавык-чебеш лапаска кереп бөреште, этләр дә әллә нинди кызганыч рәвештә кеше янына сырыша башладылар,

Сарбайның Сабир янына сырышуыннан бер хикмәт чыгарга мөмкин иде: ихтимал, ул Сабирны яшенгә суктырыр өчен сырыша торгандыр! Яшен ул хайванны бик сугучан бит...

– Пушул, пушул! Кит моннан! – диде ул.

Менә яңгыр теттереп ява башлады. Авыл өенең такта түбәсен барабан каккан күк иттереп дөбердәтә башлады... Урамда сулар агарга тотынды... Яшен һаман да ялтырый, күк һаман да күкри, яңгыр һаман да куәтләнә генә!

– Ә, Оры авылы аккан күк, бу авыл да ага башласа?

Бит әнә теге елгага агып төшәсең, бара торгач бер нәрсәгә бәрелеп, өй ватыла, Сабирга бүрәнәгә тотынып барырга туры килә, әмма ул су бит Агыйделгә коя...

Моннан да котылуы читен!

Сабир бу моңын йорт хуҗасы Гыйльметдин агайга сөйләде, хуҗа исә:

– Һәй, юк сүз, каян табасың? – диде.

Сабирның йөрәгенә җылы керде. Яңгыр да кимегән күк булды. Яңгыр үтте, матур җәй кояшы чыгып, кыздыра башлады. Кинәт хәтфә күк яшел үлән каплаган авыл урамыннан чыр-чу

килеп, марҗалар үтеп баралар иде. Сабир үзенең гадәтенчә карады. Ул аларга гади генә итеп карамады, читлектән кеше өстенә караган маймыл күк, күзләрен җелт-җелт иттереп карады. Хатын-кызлар бу карауны күреп, гаҗәпләнеп булса кирәк, көлештеләр.

Сабир тик торганда кызарды. Гыйльметдин агай да:

– Һа, бай, болар сиңа карыйлар, ахрысы! – диде. Тик торганда Сабирның йөрәге жу иттереп китте. Аңар Гыйльметдин агай моны марҗалар белән йөри икән дип шөбһәләнгән күк тоелды. Бу шөбһә Сабирның ватык, хәссас вөҗданында әллә нинди бер яра ясады. Йөрәге чеби чыккан малайлар аягы күк әчетә башлады.. Менә аны бөтен дөнья хур итә күк, «зина кыла икән бу» дигән күк була башлады.

– Юк, юк, Гыйльметдин агай, алар миңа карамыйлар... Алар башкадан көләләр... – диде. Агай да, «бай»ның кәефе килсен дип:

– Юк, алар сиңа карыйлар... Сиңа кызыгалар... әнә теге кызыл күлмәклесе...– дип, әллә нәрсәләр әйтмәкче иде, Сабир:

– Юк, без андый кеше түгел, без семьялы кеше... Без бик авыру: кымызга аның өчен килмәдек без; менә без бары авыру өчен... Без бер дә чит хатыннар илтифат итүне яратмыйбыз... – ди башлады.

Гыйльметдин агай, юри әйткән күк:

– Әнә тегесе сиңа карап аермачык көлә... Кызыга, ахрысы... – дип, Сабирның йөзенә карады. Сабир тик торганда дерелдәргә тотынды.

– Әй, юк, миңа андый сүз әйтмә, минем кәефемә ярамый, алай булса, мин синең өеңнән чыгам, әнә Миңнегалиләргә керәм... – ди башлагач, өй хуҗасы куркуга төшә калды.

– Әй, болай гына әйтәм лә, бер әйттем – ун кайттым, әйтеп кенә бактым... – диде ул.

Шулай иттереп, Сабир бу зур «бәла»дән котылды. Ләкин, идән астыннан килеп чыккан күк, икенче бер каза чыкты. Бәлки укучы: авылны җир йоткандыр да, шунда җәһәннәм чокыры күк базга Сабир да төшеп киткәндер ди торгандыр; бәлки укучы, Сабирның кымызда тора торган йортына ут капкандыр да, шуннан чыга алмый икән дип уйлый торгандыр. Ләкин эш алай түгел; Сабир өчен тагын да зуррак каза бар: ихтимал бит Сабирның хатыны да, үзе киткәч шулай ук, шул урамнан үткән хатыннар шикелле үк, аулак өйдә рәхәтләнеп ирләр белән йөри торгандыр. Беркөн дә бит Шәмсеҗиһан (Сабирның хатыны) яз башында фермага барганда кырга чыккан егетләргә бик карап киткән иде. Юкка ул, тәрәкъкыйпәрвәрләнеп, хатынын ирләрдән качырмады. Юкка шәригатьнең бит өртергә кушмавы белән аны файдаландырды. Нишләрсең? Әллә хәзер үк кайтып китәргә микән? Бит бөтен базар шаулый торгандыр: «Сабир китте дә, ме-

нә хатыны...» ди торганнардыр... Алла сакласын... нинди хурлык булыр, нинди хурлык! Нишләргә кирәк? Ихтимал, аны алдау өчен тагын тимер сандыктагы Сабирның пичәтле кәгазьләрен алыр өчен сөйгән булып йөрсәләр... Чынлап та, ул тимер сандыкның ачкычы язу өстәле тартмасында калды. Әгәр язу өстәле тартмасын бер ачкыч табып ачсалар... әле, ихтимал, ул өстәл тартмасы ачык та калгандыр. Менә бәла!.. Сабир кесәсен кармалый башлады. Тиз-тиз генә ике кулы белән түшләреннән ачкыч эзли башлады... Аны ул кесәсендә тапса да, һаман да аның эчендәге шик-шөбһә уты сүнмәде. Чынлап та: ихтимал бит ул ачкычның өйдә калуы да, аның, урынына Сабир кесәсенә башка шкаф ачкычы салуы... Менә Сабирның күз алдына урланган кәгазьләре килделәр, менә аның йөрәге тагын да куәтлерәк тибә башлады. «Мине тәмам таладылар инде, кеше алдында рисвай булдым»... – дип уйлады.

Менә матур кич җитте. Бакчадагы яфракларның әкрен генә дерелдәве, ераклта-ераклта яр башында егетләрнең уйнаган гармун авазы Сабирга әллә нинди бер курку бирде. Чынлап та, ул егетләр тик утырмый торганнардыр, алар, бер-бер әшәке эш уйлап, Сабирны таларга киңәшеп утыра торганнардыр әле. Сабир, чемоданын ачып, корулы зур револьверын алып баш астына тыгып куйды. әле генә бикләгән ишеген яңадан барып карады. Тагын шикләнеп, ут та кабызып карады. Утын сүндерде. Сүнмәгәндер дип, тагын лампасын бер кат карады, Лампадан ис чыккан күк булды; башына ис тигән шикелле тоелды. Торып тәрәзәне ачты. Азрак торды да тагын япты. Биге зәгыйфь дип, яңадан барып тоткасыннан сөлге белән әләктереп, сәке аягына бәйләде. Теге тәрәзә янындагы агач һаман селкенә, кыштыр-кыштыр тәрәзәгә бәрелә иде. Сабир ятты; ләкин аның хәтеренә теге корулы револьвер төште. Менә ул аннан шикләнә башлады. Ихтимал, йокы арасында атылып китүе... Ул аның морҗасын стенага таба каратып куйды...

Менә авыл тәмам тынды. Күрше Миңневәли агайлардагы яңа килгән авыру урыс та утын сүндерде. Ләкин Сабирга тынычлык һаман да насыйп булмады; идән астында әллә нәрсә кыштыр-кыштыр итә иде... Диварларда әллә ниткән җанварлар бик әкрен гене йөриләр иде. Йокы һич керми. Сабирның күңелен бер җиңел генә кайгы күк күңелсез тойгы каплады. Өен сагына, каравыллы, куркынычсыз өендә йоклыйсы килә башлады... Ничек тә ул бу төнне йокламый үткәреп, иртә белән үк моннан китәргә карар биреп куйды...

(Г. Газиз. Хикәяләр.– Казан: Татар. китап. нәшр., 1958.– Б. 17-21).

шуңарга мәсах җаизлеккә – шундый түбәнчелекнең дә ярагана-ныны
зөлҗенахәен – ике канатлы
тәнәззел итмәү – үз-үзен түбәнсетмәү
моталәга кылу – уку
«Китабел-hибә» – «Мохтасар»ның бер бүлеге
мотәхассис – оста, белгеч
тәкбире-тәкримә – намазга керешкәндәге «колак кагу» тәкбире
васитасы белән – ярдәмендә
вәләззалин – намаз укыганда шул сүз белән башланган кисәк
важип гөнаhи кәбаирдан – важипне кую – олы гөнаhлардан (важип – hичшиксез үтәлергә тиешле нәрсә).
игътикад – ышану, иман
зиндикъ – иманы дөрес булмаган, бозык кеше

Хатыным җәдит булды!

– Менә әле, Әхмәтҗан абзый, син сәүдә яхшымы дип сорыйсың. әле әш анда түгел; минем өйдә бер дә рәт юк әле: хатын әллә нишләгән.

– Нишләгән соң, Батырша? Әллә авырыймы? Чирлиме? Әле минем хатынга да былтыр менә җински булис булган иде дә, теге Симунски дигән бабкы карап, сихәтләнде.

– Юк, Әхмәтҗан абзый, сихәте бар барын да... Менә, әйтсәң дә оят инде...

– Я, Батырша, әйт... аның ояты юк, Миннән чыкмый ул сүз...

– Менә, Әхмәтҗан абзый, ничек дип әйтим инде... Мине бик йөдәтә башлады, сөям, ди, гыйшык тотам, ди... Мин әйтәм: соң, гыйшык булсаң, син минем хатыным ич, тагы ни кирәк, дим... Муеныма сарыла, ашарга-эчәргә ирек бирми; әллә нинди робагыйләр укый: синнән башка, ди, тора алмыйм, ди... Тормасаң, мин әйтәм, дөмек инде, hаман да, дим, бергә торабыз ич, дим...

– Вәсвәсә булмады микән, Батырша? Хиффәтләнмәде микән? Хатыннар корсакка узгач шулай була торган...

– Юк... Мин, ди, башта, ди, сине белмәгәнмен, ди.– Менә ай яктысы булыр хәл юк, валлаhи, йөрергә чыгыйк, ди, hич чыдар хәл юк, әллә ниләр сөйли; мин сине, ди, ничә елдан бирле сөям, ди... Бер, ди, ут яктысы шикелле нәрсә, ди, әчемдә hаман да: «Батырша, Батырша!» дип кычкыра, ди...

– Я әле, ни сәбәптән ул болай икән; сөйлә әле...

– Белмим... Бары шул: бер асламчы карчык былтыр әллә нинди китаплар сатып йөрде дә, минем җәмәгатькә дә саткан; шуларны укыгач кына булды инде ул... Берсе «Мескен Газизә» атлы китап. Шуннан ул миңа да укып йөдәтә; бер кыз бер кешегә гыйшык булган: теге кеше аны алмаган да, аерылган... Син, ди, шуның күк, ди, мине сөймисең менә, ди... Валлаһи менә, ялап бетерә, кеше нәфәсе авыр бит ул. Менә, ул инде яз җитсә, Арча кырына барыйк, ди... Шунда, сандугач сайрый башлагач та, миңа ябыша: сөям, ди... Аны нишләтәсең? Кешедән ояласың бит...

– Ә, Батырша, ул инде алай булса җәдит булган, җәдит... Алар бит шул гыйшык китаплары язалар бит. Робагыйның шәбе аларда инде... Мин аны бер дә хатынга бирмим: укыма, димен, соң, кеше бит ул аза аннан соң.... Әле безнең бай улы да: мин, дип әйтә, ди, шагыйрь Пушкин дип әйтә, ди бит; мин язам, дип әйтә, ди... Гыйльме горуз дигән бер гыйлем бар, ди; шуны укыйм да, дип әйтә ди, робагый яза башлыйм, дип әйтә ди... Шуның бер язуын безнең Шәйхетдин укыган. Шул язган, ди, «сөйгәнемә» дип куйган да, ди, синең тырнагың – Каф тавы гәүһәре, кашларың сандугачныкыдай кәкре, дип язган ди.

– Табалар бит сүз, Әхмәтҗан абзый, ә? Минем җәмәгатем дә мачтыр инде ул сүз табарга... Соң беркөн, минем гомеремнең апак алмасы син, фәлән-төгән дип, кибеткә хат язып төшергән дә, шунда, кайчан кавышырбыз инде, дип язган... Соң бит инде кич белән кайтам, ләбаса!

– Шулай инде ул, Батырша, хатыннар азса, харап эш ул... Ул дәрт бит ирләрдә бер өлеш булса, хатыннарда җиде өлеш була, ди... Әмма инде хозур андый хатын, ә?

– Юк, Әхмәтҗан абзый, пүчтәк эш ул... Туйдыра бит ул... Соң ул менә харап инде... Мине, ди, син Гөлгазар дип йөр, ди... Шул исемдә бер китап укыган ул, күрәсең! Ни эшлим икән Әхмәтҗан абзый, ә?

– Соң син аны теге бабкыга күрсәтеп кара... Алар бит тәҗрибәле булалар...

– Әйттем... Әле быел бала төшерде ул... Шунда әйттем... Мин әйтәм, мая жана миңа лубуф диржет, дим... Бик яхшы, ди. Яхшы менә монда һаман да ялап торгач: кеше сулуы авыр бит ул...

– Дөрес, дөрес, Батырша.

– Менә әле, Әхмәтҗан абзый, беркөн, бәйрәм алдыннан, кәндитергә барабыз да, шунда, гөнаһ шомлыгына каршы, күрше Котбетдиннең кызы белән хатыны кергәннәр... Шуңа карыйсың ди бит, менә, шабаш!.. Соң, мин әйтәм, сабый ла-

баса ул, дим... Аңар карамый, гыйшык хәле ул, ди, яшькә карамый, ди.

– Күрәсең, тәшвишләнә инде ул...

(Г. Газиз. Хикәяләр.– Казан: Татар. китап. нәшр., 1958.– Б. 46-48).

жински булис – женская болезнь (хатын-кыз авыруы)
сихәтләнде – терелде
робагый – гарәпләр дүрт юллы шигырьне шулай атыйлар; электә татарда, гомумән, көйле нәрсәләрне робагый дип йөрткәннәр
хиффәтләнү – акылга жиңеләю, тилесыманлану
нәфәс – сулыш, сулу, тын
гыйльме горуз – шигырь үлчәве турындагы гыйлем
мая жана миңа лубуф диржет – хатыным миңа мәхәббәт саклый

Чалбар

Вәлиулла хәзрәт әченең әллә кай жиреннән чалбарга аеруча дошманлык сизә иде; дәһрилек, остазга илтифатсызлык, наданлык – һәммәсе дә, һәммәсе дә шул бәдбәхет чалбардан килә төсле иде... Хәер, ул дошман нәрсә бу Вәлиулла хәзрәт заманында үзе дә аз иде әле; хәзер генә бит ул бөтен дөньяны каплады... Кемне генә күрмә, һәммәсендә чалбар! Дөрес, Вәлиулла хәзрәт тә рамазанда бәдәл өчен килә торган гарәпләрдәге, «сәет»ләрдәге чалбарга тимидер иде, чөнки алар, чалбар булудан бигрәк, бер галәм, бөтен бер дөнья иделәр: алардагы чалбарның төбенең, балагының киңлеген әлегә кадәр бер кеше дә үлчәп бетергәне юк.

Менә Вәлиулла хәзрәт шул бер истисна белән, гомумән, чалбарга дошман иде... Аның мәдрәсәсендәге ике йөз шәкерттән берсендә дә чалбар юк иде... Аның мәхәлләсендәге алты-жиде йөз ир кешедән һичберсендә чалбар юк иде...

Үзегезгә мәгълүм, бездә салкын көннәр була, гомумән, Болгар иле шундый суык инде ул! Менә шул салкын көннәрдә Әрбет, Минзәләгә ярминкәгә барганда да мәхәллә халкы хәзрәтнең фатихасында чалбар кимиләр иде; һәр госергә бер йәсер бар ди бит, шуның кебек, чалбар урынына да сырган-бөргән күк ыштан киюне мәхәллә әһалисе гадәт иткән иде...

Көннәрдә беркөн Вәлиулла хәзрәт Иске бистәгә әллә кем байга никах мәжлесенә барырга чыккан иде. Бу язның жылы коя-

шы яңа гына карый башлап, карларны эреткән бер көне иде... Гөнаһ шомлыгына каршы, теге Әрәмәле авылы мулласының улы Сәетгәрәй шәкерт хәзрәткә очрады, Сәетгәрәй Вәлиулла хәзрәт мәдрәсәсендә укый торган «тәүзих-хан» иде инде... Хәзрәтнен күзе егеткә төште. Кыйбладан искән җил белән егетнең җиләне җилфер-җилфер килә иде... Җилән астыннан кара нәрсә күренде... Вәлиулла хәзрәт, үз-үзен белмичә, пычракка бата-бата, трантасыннан төшеп, Сәетгәрәйне туктатты да, бик кызып:

– Һай, син, мулла кем Сәетгәрәй, чалбар кигәнсеңдер ахры? – диде.

Сәетгәрәй бу эшнең ахыры яхшы булмасын белә иде:

– Тәкъсир, шундый кара ыштан гына ул! – диде.

Хәзрәт кулы белән кармалап карады:

– Һай, шәйтан, оятсыз! Чалбар булмый, нәрсә булсын бу? Шул инде, дошман, чалбар инде! Әһле исламның рисвайлыгына сәбәп нәрсә шул инде!.. – диде.

– Тәкъсир, болай гына, суыктан гына! – дип, Сәетгәрәй котылырга уйлаган иде дә, булмады.

– Юк, сал, сал!.. – диде хәзрәтем.

– Яхшы, тәкъсир! – дип, шәкерт юлына китмәкче булды, ләкин хәзрәт ирек бирмәде:

– Юк, хәзер сал... Миннән, валлаһи, фатиха юк, аслан фатиха юк!.. – диде ул.

– Тәкъсир, зинһар, рөхсәт итсәнә, кайткач та салырмын, валлаһи, рисвай булам, әчендә башка нәрсәм юк иде.

– Юк, хәзер күз алдымда сал дошманны! Монда күп уйлый торган эш юк: салмасаң, минем мәдрәсәмнән чык, сиңа фатиха да, ни дә юк, валлаһи, бәддога сиңа... Атаңа язармын...

– Зинһар, миһләт бирсәнә, хәзрәт!

Бу вакытта инде алар янына бер пыялачы рус, бер сәдакачы хатын килеп, тагы үткән-барган туктап, халык күбәя башлады...

– Рисвай булдым, хәзрәт! – ди иде Сәетгәрәй...

– Юк, аслан разый түгел, синең мондый әкъбәхел-кабәих нәрсәне киеп, бер адым атлавың бөтен әһле исламга рисвайлык, бөтен мөселманның йөз суын китәрү! – дип, хәзрәт үз таләбендә сабит торды.

Нишләмәк кирәк? Мәдрәсәдән чыгаргамы? Кая барасың? Салмый хәл юк. Ул вакытта әле халык хәзерге шикелле динсез түгел, фатиханың да кадерен белә иде...

Сәетгәрәй сала башлады. Пыялачы урыс, хәзрәтнең каршына килеп:

– Молодец, мулла, а то урлаган нәрсәне шулай тотмасаң... Мин үзем свидетель булам, – дип, хәзрәткә куәт бирә башлады. Ул бичара бу вакыйгага караклык катышкан дип уйлый иде.

– Һай, бәдбәхет, шәкерт кеше үзе, чалбар урлаган бит! – дип, карчык та пыялачы урыс фикеренә кушылды.

Сәетгәрәй сала башлады: җилән эченнән бер пута чишеп ташлады... Җиргә бер зур нәрсә килеп төште... Төшкән нәрсә итәк булып чыкты... Сәетгәрәй аның «балакларын» да салды.

Хәзрәтнең чалбар дип курыккан нәрсәсе ни булып чыкты дип уйлыйсыз?

Ул икенче бер жилән иде: Сәетгәрәй, «әре» булсын өчен, икенче җиләннең җиңнәрен чалбар итеп киеп, пута белән биленә бәйләгән дә, шул җәгъли чалбар белән әре генә йөрергә чыккан иде.

Борынгы заманда менә шулай итеп дошманны бетерәләр, әмре мәгъруф вә нәһи гайнел-мөнкәрне иҗра итәләр иде.

(Г. Газиз. Хикәяләр.– Казан: Татар. китап. нәшр., 1958.– Б. 90-92).

дәһри – алласыз
бәдәл – ялланып хаҗга бару
шул бер истисна белән – шуңардан кала
һәр госергә бер йәсер – һәр авырлыкка бер җиңеллек
әһали – халык
тәүзих-хан – «Тәүзих» китабы укучы шәкерт
миһләт – вакыт
әкъбәхел-кабәих – кабахәтнең дә иң кабахәте
әһле исламга рисвайлык – мөселман халкына оят китерү
сабит торды – нык торды мәгънәсендә
җәгъли – ясалма, ялган
әмре мәгъруф вә нәһи гайнел-мөнкәрне иҗра итәләр иде – шәригатьтә тыелган эшләрдән кешене тыю кебек изге эшне җиренә җиткерәләр иде

Тимсах куркусы

1

Мулла Сабир мәҗлестә бик кызып, әллә ниткән сәяси мәсьәләләр сөйли иде. Шулкадәр кәефле сөйли, шулкадәр кәефе хушланган иде ки, сөйләгәндә, тәмле нәрсә ашагандагы күк, авызыннан селәгәйләре агып төшә, сүз арасында шуларны ул авыз эченә шыпылдатып, кире суырып ала иде.

– Без Бохарада вакытта әфганыйлардан күп зат белән күрештек. Аларда бер гаҗәп шәҗагать бар. Үзбәкнең алардан коты чыга. Аларның төсендә әллә нинди бер гайрәт күренеп тора, Аларның әсмәр төсе, кара күзләре Халит бине Вәлит хәзрәтләрен искә тешерә, Анда әгелчән дә керә алмый.

Кәрим бай Сабир мулланың сүзен кисте:

– Дамелла, – диде ул, – тимсах дигән нәрсә ни нәрсә була?

– Мулла Кәрим, ул бер дүрт аяклы хайван. Һиндиләр мәмләкәтендә була, «Хәятел-хайван» аның хакында күп нәрсә сөйли: ашасы килсә балалар күк елый, ди; йомыркасы ганка йомыркасы кадәрле була, ди. Һәм дә мәзаһибе әрбәга каршында ләхме хәрам, вәхушдән ул, ерткыч, ифрат хәтәр: кешене йота ала, йота алмаса, ертып ашый...

Кәрим бай Сабир хәзрәтнең янынарак барып утырды.

– Менә син ишеттеңме әле, хәзрәт, – диде ул, – менә шул хайван, Әчтерханда кәмиттән качып, пычрак суы белән канауга төшеп качкан, ди...

Сабир мулла бары:

– Гаҗәп хайван инде ул! – дип кенә куйды.

Гомерен фантазия белән уздырган талчокчы Хәкимнең йөрәгендә әллә нинди вәсвәсәсыман нәрсә пәйда булды. Ул, Кәрим абзыйның янынарак утырып:

– Кәрим абзый, соң ул йөри микән? – диде.

– Дүрт аяклы, ди, ич, йөри торгандыр...

– Хәзрәт, йөриме соң ул?

Хәзрәт:

– «Хәятел-хайван» аны бака шикелле бәрри вә бәхер хайван дигән бугай, йөри күрәсең! – диде.

Хәким:

– Минем күл янында торуым бер дә мәслихәт түгел алайса! – дип куйды.

Хәзрәт тә, Кәрим бай да шаркылдап көлделәр. Ләкин Хәкимнең күңелендә тирән бер әз булып шөбһә калды. Ихтимал бит, ул тимсах дигән җанвар Иделгә китеп, Идел белән Казан шәһәренә йөзеп килер дә су ташуы вакытында болар тора торган күлгә кереп үрчер. Ул бит зәхмәт нәрсә, ди; үрчесә бит, ул яман булыр...

Сабир хәзрәт үзенең ярата торган сәяси мәсьәләләренә яңадан керешеп киткән иде. Хәким аның сүзен бүлдерде:

– Дамелла, бигайбә, бер генә сүз сорыйм әле сездән: тәкъсир, соң ул тимсах чага микән соң?

– Әнә анысын белмим инде, мулла кем, ничек әле, әй Хәким...

2

Күл өсте ак башлы дулкыннар белән тулган иде... Һәр ак дулкынның арасында бер тимсах башын чыгарып, мәче күзе күк күзләрен ялтыратып торалар, күл кырыенда ифрат каты кычкыралар иде...

Хәким күрде: Камали унтерның аягыннан тимсах капкан, каравыл кычкыртып күлгә өстери, Камали унтер кылычын чыгарып суга, ләкин кылыч бөгелә, сына, кулыннан төшә. Менә Камали унтер акыра, менә ул тырмаша. Ул су кырыендагы зур ташка тотынган. Таш урыныннан куба, «Мәдәт, мәдәт!» дип кычкыра. Менә яр кырыенда Сабир мулла зоһур итте. Тимсах та Камали унтерны җибәрде; бөтен ак башлы дулкыннар, тимсахлар югалдылар.

Тирләп-пешеп, Хәким агай йокысыннан уянып китте. Иртәнге намаз вакыты җитеп килә иде. Хатыны уятты да:

– Кая, сиңа әйтәм, бик яман төш күрдем, кичә сөйләгән яман хайваннарны күрдем; зинһар, балаларны су янына җибәрмә... – диде.

– Абау, әстәгъфирулла... Тфү, шакшы хайван!

– Ахмак, шакшы гына түгел, хәтәр әле...

Намаз укып, чәй эчте дә Хәким агай талчокка китәргә хәзерләнде. Үзенең төрле иске нәрсәләр сала торган саквояжын алып чыгып китте. Аңа талчокта Сәмигулла абзый очрады.

– Кая, Хәким, шул каркадил тиресеннән ясаган чумаданыңны миңа сат әле, сораучы бар; син башкасын алырсың; тагын кулда табылыр әле! – диде.

– Нәрсә тиресе дисең?

– Каркадил!..

– Нәрсә соң ул?

– Мөселманча тимсах диләр бугай...

– Кит! – диде Хәким агай. Аның төсләре агарып китте.

– Ал, ал, – диде дә ул чемоданны шунда ук җиргә куйды. Тиз-тиз генә эчендәге әйберләрен алып, юлына китте.

Ул юлда үз-үзенә: «Котылдым бу бәладән, әйдә акчасы эшкә ярар ичмасам, үзе күз алдымнан югалды...» – дип уйлады,

Хәким, өенә кайтышлый, бик якты ут яндырылган бер кибеткә кереп, бер кавын алды да акрын гына өенә таба юнәлде. Юлда аны күршеләрендә тора торган бер сәүдәгәр куып җитте.

– Әссәламегаләйкем! Әмма чабасын да соң син, Хәким әфәнде!

– Кайтырга ашыгам, бүген соңга калдым...

– Бик шәп кавын алгансың икән, күпмегә алдың? Хәким абзый, әллә нинди, кешегә күренергә ярамый торган җире, тәне ачылган төсле булып китте; оялды, тирләде.

– Ә, юк, балалар ашар дип алдым мин аны, мин андый корысары нәрсәне яратмыйм, – диде.

Чынлап та, ничек итеп кавын хәтле кавынны Хәким үзе, олыгайган кеше, аны ашасын! Ият бит ул! Тагын да, имеш, сакалын күтәреп кавын алып кайтсын! Аның мещан рухы оялды... Ит, лапша, торма, хәтта сарымсак, суган (әнә кыярның да тозлаганы зарарсыз) әле сәүдәгәр ашарлык нәрсәләр; имеш, ул чеп-чи кавын ашасын; балалар, хатыннар гына ашый торгап нәрсәне! Аны бары туйда, яки башка берәр мәҗлестә генә ашарга килешә... Җомга көннәрдә бәгъзе олыгайган кешеләр ашавын ашыйлар да, ләкин ул да инде бөтенләй килешеп бетми шул...

Күрше талчокчы:

– Кая соң, Хәким әфәнде, синең теге сумкаң? – диде.

– Мин аны биеттем бит. Ул теге әшәке нәрсә тиресеннән ясалган икән!

– Дуңгыз тиресеннәнме әллә?

– Юк ла, теге тимсах тиресеннән. Кабәхәт, хәтәр җанвар ул... теге урыс каркадил ди ич әле шунда...

– Әле бит укыдыңмы: гәзитләрдә Самардагы звир кәмитеннән берсе чыгып качып, Волгага төшкән имеш, диләр...

– Кит, – диде Хәким абзый: – Тагынмы? Әлә генә берсе Әчтерханнан качкан дигәннәр иде ич!

Хәким абзыйның яңадан кәефе китте. Әчтерхандагысы ата булып, Самардагысы ана булса, алар бөтен Волганы тутырырлар инде. Шулай итеп, алар бөтен күлне дә тутырганнардыр инде! Менә беркөнне үрмәләп ишек алдына менсәләр...

Өенә кайтып кергәч тә, Хәким абзый хатынына кавынны тоттырды да:

– Сиңа әйтәм, каһәр генә төшсен, минем теге сумкам тимсах тиресеннән ясалган булган икән бит! – диде.

– Кит, булмас!.. Теге төшеңә кергән җанвар тиресеннәнме?

– Шуннан шул...

– Мин бүген, атасы, Шәрифҗамалларга ашка барган идем, анда сөйләделәр, гәзиттә бар, ди, Самар каласындагы кәмиттән качкан, ди...

– Мин дә ишеттем... Тәгаен алар безнең бу күлдә бардыр инде!..

– Бардыр, атасы... Кичә Әхмәдиләрнең казы югалган, ди!..

– Юк, бу фатирдан күчәргә кирәк... Әнә теге шүрлектәге чумаданны да чоланга чыгарып куй: кем белә, бәлки ул да теге

ләгънәт тиресеннән ясалгандыр... Күз алдыма килеп, һаман искә төшеп тормасын; болай да ул җанвар ике көннән бирле инде кәефне тәмам кырды!

(Г. Газиз. Хикәяләр.– Казан: Татар. китап. нәшр., 1958.– Б. 105-108).

шәҗагать – батырлык
ганка – мифик зур кош
әсмәр – кара тутлы

Форточкалы кәләпүш

Кәләпүшне калыплый торгач, Сәмигулла абзый дәфгатән туктап китте. Миңлебикә абыстай мич алдында коймак пешерә иде.

– Тукта әле, хатын, – диде ул, – куй әле беразга гына; үзеңә бер сүз әйтим, теге Закир киттеме? Ул булса, сөйләмим; ишетмәсен, я үзе ясар... хитри кеше ул...

– Тукта әле, карт, йөдәтмә, хәзер Маһруй белән кияү килер, әнә сәгать җиде тула...

– Туктасана, куй әле! Шул табаңны пешер дә кил!

– Менә булды... Хәзер киләм! – диде дә Миңлебикә абыстай, кулын алъяпмасына сөртә-сөртә, аның янына килде.

– Я, нәрсә әйтәсең?

Сәмигулла абзый кулына калыплап бетергән кәләпүшне алды да:

– Менә мин нәрсә уйлап чыгардым: менә күрәсеңме? Кәләпүшче Лотфулла кәләпүш өстенә дүрт тишек ясаган булган... Мәселман духтыры да мактаган, ди: хәзер башка һава кереп торыр, хәзер татарның башы авыртмас инде, һава йөреп торыр, дип әйтә ди... Ә мин хәзер япун күк булдым инде, тагын башка төрле әкәмәт чыгармакчы булам...

– Тизрәк булсана! Булырсың менә, әҗәткана, япун! Нишләмәкче буласың тагы? – дип Миңлебикә абыстай ирекнән сорап өлгермәде, Сәмигулла абзый сүзендә дәвам итте:

– Менә нәрсә эшлим: күрәсең әнә тәрәзәдә шылтыр-шылтыр итеп фурточка әйләнеп тора; әнә шул кәләпүш тишегенә дә мин шундый фурточка ясамакчы булам; кечкенә генә, челтер-челтер итеп, сандугач күк сайрап утыра торган фурточка...

– Калфакка да яса син аны, – диде Миңлебикә абыстай, – безгә дә рәхәт булсын.

– Элек кәләпүшкә ясыйм, аннан соң сезнең чыпчык башы күк бидгать калфагыгызга да ясармын... Кая, бир әле кайчы белән әнә беркөн кияүләргә алып кайткан пампаси тартмасын. Хәзер ясап карыйм...

– Аңар мин сабын салып куйдым, юк әшкә...

– Бир, дим, хәзер бир... Кеше фурточкалы кәләпүш ясамакчы, милләтнең башы авыртуын бетермәкче була, ә син шуны да табып бирмисең!..

Миңлебикә абыстай тартманы әзли башлады.

– Фу, коймак пешереп бетерергә дә ирек юк! Сиңа калды, фурточка әшләргә инде... әҗәткана!

– Әзлә, әзлә! Менә гәзитләрдә мактый башласалар, син дә сөенерсең... Менә һәммә кеше миңа заказ бирә башлар; ә минем игълан гәзитләрдә басылып чыгар; «Мин, кәләпүшче Сәмигулла әфәнде Гыйззәтуллин, табиплар кушканча, мәшһүр, файдалы фурточкалы, сайрый торган кәләпүш әшлим... Ихтирам белән Сәмигулла Гыйззәтуллин», дип яздырырмын. Әйдә китсен безнең дан!

Миңлебикә абыстай бер калай тартма табып китерде:

– Аны кеше ничек киеп йөрер соң? Шыгырдап йөдәтер ич соң ул?!

– Алай түгел ул, хатын; элек ул башның яман исе чыкканчы сайрый да соңыннан, баш истән тазаргач, сайрамый ул! Менә безнең фурточка да һаман шыгырдамый бит!

– Әйдә, яса... Мин коймакларымны пешереп бетерим әле!

– Әй, сиңа әйтәм, кияү килгәч тагын син шапылдама, ул үзе ясый башламасын!

– Юк, юк, әстәгъфирулла... Сиңа сөенеч миңа да сөенеч ич!..

Сәмигулла абзый, тартманы кисә башлап, телен чыгарып әшләргә тотынды.

«Тукта әле, мин моны болай гына калдырмыйм... Илтерски куәте белән, әнә теге кинима томанныендагы күк, тиз әйләнә торганнарын ясыйм», дип уйлады ул эченнән...

(Г.Газиз. Хикәяләр.– Казан: Татар. китап нәшр., 1958.– Б.118-119).

дәфгатән - кинәт
хитри- хәйләкәр
илтерски куәте - электр куәте
кинима томанные - кинематограф

Кылыч-мылтык
(Татарның рыцарьлык тарихыннан бер бит)

1

Беркөн әтинең иске нәрсәләрен җыештырганда, иске чапан, таҗ-чалма, мисвәк, тәсбихләр белән бергә салынган зур бер күгәргән кылыч, бер тупыйк башлы, морҗасыннан тутыра торган пистул (пистолет) килеп чыкты. Әни карчык, боларны күрүе белән ап-ак булып китеп, әти картка карап:

– Сиңа әйтәм, атасы, харап булдык, кылыч-мылтык килеп чыкты, яу булыр, һәлак булдык, атылып кына китмәсен... Хәзер урынына куй... Гөнаһ шомлыгына каршы, кайдан юк-бар хәтәр нәстәләрне казып чыгардың, абау! – дип кычкыра башлады.

Әти карт ак мыек асларыннан гына көлә, әни карчыкны «тәскин кылырга» (юатырга) тырыша иде. Мин әнинең ай-ваена карамадым, тиз генә коралларны алып чыгып, бүлмәмнең стенасына асып куеп, кроватема ятып уйларга керештем. Минем башыма әллә кайдан фантазияләр килә башлады. Бүген генә университетта профессор безгә хач сугышларының тарихын сөйләп, Сәлахетдин, Сәет-Баттал шикелле каһарманнарның – «Арслан йөрәк» рыцарьлар, әллә кемнәр, Кара рыцарьлар белән сугышканнарын сөйләп кайтарган иде.

Менә мин әйтәм: безнең агай-әненең дә шундый батыр рыцарь вакытлары булган, күрәсең. Атларга атланып, башларына тимер түбәтәйләр киеп, тузан туздырып, буран уйнатып, дошманнар белән киң степьләрдә көч сынашканнар... Бәлки безнең бабайлар да бу көрәшләргә катнашканнардыр... Башка әллә ниләр килде. Шул вакытта үкчәсез читеге белән кыштыр-кыштыр итеп, минем бүлмәгә атай карт та кереп утырды. Мин хәзер сорашырга тотындым:

– Әйе, шуның өчен кергән идем әле.„ – диде әти, – син инде һәр нәрсәне беләсең килә. Бу кылыч белән пистул синең бабаң Сәйфулла хаҗи дигән кешедән калган. Әти мәрхүм күп юл йөргән, күп ил күргән кеше иде. Эрбеткәме бара, Минзәләгәме китә, һәрвакыт бу ике коралны алып йөри торган иде. Менә төрек сугышыннан алдарак булган бер заманда, минем малай чак, мине дә Минзәлә ярминкәсенә алып барган иде. Юл ашлары, вак бәлешләр, каз итләре, вак күмәчләрне әни мәрхүм «пугрибис»кә салып утырганда, әти зур сандыкны чыжлатып, җырлатып ачып, бу ике коралны тартып чыгарды. Соңыннан бу пистулны бик зур яулыкка төреп, өстенә тунын киеп, данадар бүреген ба-

шына эләктереп чыгып барганда, мин дә эт күк артыннан иярдем. Буран иде. Ишек алдына ямщик та зур күшле чанага пар алаша җигеп килгән иде. Әти урысның янына килеп, утыз тиен акча биреп:

– На, Иван, на даруге пулштуфкы пускай! – диде. Иван, башын салып, бик рәхмәт укып калды, атай, капканы шыгырт итеп ачып, күршегә кереп китте. Мин әйтәм «бу кая бара икән». Күршедәге Миңсабирның ике этажлы агач йортына кереп китте. Анда Сәхип салдат дигән Никалайский салдат торадыр иде. Әлегә кадәр исемдә, сакалы кырма, әмма мыеклары капралныкы шикелле ямьсез озын иде. Кәрчүннектә аның мыегы чәйгә кергәнгә, халык аны «Урыс Сәхип» дип йөриләр, имеш. Кердек. Әти сәлам бирде.

– Һә, исәнме, Сәйфулла хаҗи! Минзәләгә китәсең бугай? Синә инде Сәхип абзаң тагын кирәк булгандыр... – диде ул.

Атай да:

– Әйе, Сәхип абзый, менә тагын синә теге пистулны китердем, корып бирче! Миндә инде дары да юк, синдә аның ише нәрсә була торган иде... – диде.

– А как же! Бар, есть. Разве ваянный кешедә пурых булмас! Без аның исен күп мәртәбәләр иснәгән кеше, под Аршау, под Сиваступуль, без күп сугышкан кеше... А какже, есть, бар... – дип китеп, өстәл тартмасыннан бер кәҗә мөгезе (дары савыты) чыгарды. Атай да, яулыкны сүтеп, пистулны өстәл өстенә куйды. Мин дә керә-кичү шикелле янына барган идем, этеп җибәрде.

– Кайда мылтык морҗасы алдында торасын! Хәтәрдә бәрәкәт юк! – диде.

Сәхип абзый, күзенә махсус күзлеген киеп, элек пистулны карады.

– Ә, иске икән. Яхшы пистолет, яхшы. Настаящий уральский стальдан ясаган, Питроф мачтырның эше, яхшы эш...

Сәхип абзый әллә нәрсәсен менгезеп төшерде. Соңыннан морҗасыннан авызы белән кабып өрә башлады. Атай да, мин дә ике адым артка чиктек.

– Вульный кеше курка инде ул, аха-ха! – дип көлде дә, атайга карап: – Син моны атмагансыңдыр ахры? – дип сорады.

Атай:

– Юк, Сәхип абзый, асла юк, мин аны атмыйм, әмма һәр елны җәй көне җыенга барганда алып барып, андагы мулланың агасы салдатка биреп аттырам...

– Ну тавышы шәп чыга торгандыр? – диде Сәхип абзый.

Атай исә:

– Әллә тагы? Ул аны чишмә янына төшеп ата шунда... – диде.

Тутыртып алып, Сәхип салдатка юл сәдакасы биреп чыгып китә башлаган идек, салдат:

– Хаҗи, ә пистун? – диде.

– Юк, юк, Сәхип абзый, анысын киертмә, миңа гына бир, кирәк-ярак булса, киертермен, – диде әти.

Сәхип салдат бер калай тартманы ачып, кәгазьгә төреп, атайга ике пистон бирде һәм атайның бик курыкканын күреп:

– Юк ла, курыкма, атылмый бит ул, менә киертсәң генә... – дип, пистулны ала башлаган иде, атай:

– Юк, юк, асла киертмә. Кирәге юк! – дип, мылтыкны алып чыгып киттек.

Чанага нәрсәләрне төйи башладык. Пистул белән кылычны да салдык. Киттек.

2

Менә, чалулый-чалулый Казанның урамнарыннан чыгып, Арча кырына барып җитеп, кыңгырауларны чишеп җибәргәч, кар сахрасы эченнән повозкабыз кош шикелле оча башлады. Буран туктаган. Ике якка утыртылган юан каеннар, зур баһадирлар шикелле, яныбызга килеп җитәләр дә, тагын артта калалар... Юлаучылар да, үз җырларын җырлап, йөк төягән чаналар артыннан баралар. Повозкаларга утырган боярлар да тройкалар белән элдертеп узалар... Күп киттек. Мин дә йоклаганмын. Берничә станцаларны да узып киттек бугай. Бервакыт тын булып китте. Безнең атлар да әкренләп каядыр кереп туктадылар. Фонарь тотып ап-ак сакаллы карт чыгып:

– Ә, Сәйфулла хаҗи икән, хуш килдегез! – дип, безне ак өйгә алып керде. Нәрсәләрне ташый башладылар. Ишекне ачып, зур кара күзле малай, кашына-кашына кереп, алдыбызга басты. Чулпысын чылтыратып, кызыл француз яулыгы белән авызын каплап, килен өстәлгә самовар кертеп куйды. Бу Чүриле авылының мөәзине Кәримулланың өе икән ләбаса. Һәммәбез дә өстәлгә утыруга, чыжылдаган самовардан пар чыгарып, безнең чынаякларга чәй койгач, хуҗа карт:

– Я, исәнлекме, саулыкмы, аманчылыкмы, ул-бу юкмы? – дип сорашырга кереште. Әти карт та бик вәкарь белән генә җавап биреп торды. Туйганчы чәй эчтек. Соңыннан ямщик та: «Атлар булды!» – дип керде.

Нәрсәләрне чыгарып бетереп, ахыргы мәртәбә ямщик кергәч, атай, зерә гайрәтләнеп китеп, минем колакка гына:

– Син, улым, курыкма, мин бу мужикларга бераз страх салыйм әле! – дип, әлек сәкедә яткан пистулны, чүпрәгеннән чыгарып, сөртергә тотынды.

– Чү, – диде мөәзин, – чү, мулла Сәйфулла, атылып китмәсен, зинһар акрын тот!

Атай:

– Менә безнең юлдашыбыз... – дип, чүпрәк белән тирләгән пистулны сөртә-сөртә, бер күзен кысып почмакка таба төзәгән күк итеп торды. Ямщик читкәрәк китте. Мөәзин, көлемсерәп:

– Бер дә запассыз йөрмисез үзегез, хаҗи абзый... – дигән иде, атай:

– Ә, әле безнен, тагын бер иптәш бар! – дип, кылычны төргән бигаять озын киндерне чишә-чишә тәмам итеп, кылычны кынысыннан чыгарып, бик гайрәт белән чаж итеп селкеп җибәрде.

Мөәзин, мескен, куркып агарынып китте:

– Чү, сабыр, сабыр, хаҗи әфәнде! – диде. Мин дә атайның гайрәтеннән күземә терәлгән йокыларымны югалттым. Шунда мин бер нәрсә күреп калдым, кылычның очы десертный пычак очы шикелле тупыйк иде; үзе бөтенләй үтмәс иде. Мөәзин дә:

– Хаҗи әфәнде, миңа таба каратып тотма, сузыла бит ул! – диде.

Ямщик чыгып киткәч, атай, мөәзингә сәдакасын биреп:

– Габделкәрим әфәнде, син бер дә хафа булма, бу сиңа күрсәтү түгел: бу ямщиклар – разбойниклар, аларга шулай страх күрсәтмәсәң ярамый, дус бар, дошман бар! – диде.

Күрешеп чыгып киттек, чанага утырдык. Теге коралларны да каядыр исә чананың астына салып калдырган идек.

Юлда мин атайга бер сәаль биреп, ни өчен ул кылыч очсыз да, үтмәс тә, дип сорадым.

– Юлда чәнчелмәсен дип, урын-җирне кынысы кисмәсен дип, мин аны шулай үтмәсләтеп алдым, – диде.

***

Әти бу хикәяне сөйләгәч, минем күз алдымнан баягы рыцарьлык, сугышчанлык картиналары тәмам югалганнар иде.

(Г. Газиз. Хикәяләр.– Казан: Татар. китап. нәшр., 1958.– Б. 163-167).

на, Иван, на даруге пулштуфкы
пускай – мә, Иван, юлда ярты
штоф аракы әчәрсең

страх салу – куркытып алу
сәаль – сорау

Әкиятләрдән берсе

Шәрекъның үткен кояшы күптән сүрелгән, чүлне чолгап алган яшеллеккә күптән хәл алырга ирек биргән иде... Чишмәнең көмеш сулары акрын гына чырлап агалар, вак ташларны тәгәрәтәләр иде...

Ялгыз коббә, ялгыз коббә... Мондагы шәехнең черемәс тәннәре инде өч йөз елдан бирле ял итәләр; аның рухы да инде күптәннән гайре мадди бер галәмдә йөзә... Чүлнең тынлыгы, тәннең бәгъзан кече атналарда зиярәткә килә торган җаны кебек рәхәт... йөрәкләргә истирахәт, күңелләрдән мәңгелек исәпне алып ташлыйлар... Җилсез кичтә ял итә торган, җәелеп ята торган бер-ике пальма, озын хөрмә агачлары иркенләп утыралар.

Мөҗавир Габдулла коббәнең тонык, рәшәткәле тәрәзәсеннән еракта үтеп бара торган кәрванны күзе белән озатты; кояшның тегендә, еракта-еракта, офыкта югалганын карап торды да, озын итеп таза кыңгырау кеби сак тавыш белән ахшам азанын әйтте; озаклап чын дәрт, чын Алласын сөю белән намазын үтәде... Чүлнең рухына килә торган мәгънәле Коръәннән кычкырып берничә аять укыды; кулын күккә таба күтәреп, мәңгелек сөя торган мәгъбуденнән рәхмәт яңгыры сорады, кичерүен теләде...

Менә җир караңгыланды, күк үзенең тишекләреннән иләк артыннан якты караган кеби, вак-вак яктылар белән тулды... Ярты ай да хөрмә агачының куе, зур яфраклары арасыннан ялтырап күренде...

Мескен ач шакалларның җылавы, әллә кайда, чишмә янында карт ябалакның кычкыруы бер моңлык салды...

Коббәнең челтәрле тәрәзәсеннән җылтыр-җылтыр итеп ут та күренде... Мөҗавир Габдулла мәкъбәрәгә кереп, бу көн ахыргы мәртәбә, мәңгелек йокыдагы изге шәехтән мәдәд, ярдәм таләп кылганнан соң кереп, калага алып барып, сатып тамагын туйдырырлык нәрсә алыр өчен, фәкыйрьләргә шәехнең рухына садака бирер өчен, янә үзенең бөтен тирә-яктагы мәшhүр матур язуы, әсәрле каләме белән китап күчерергә кереште...

Изге сүзләрне матурлау өчен Габдулла бәгъзе хәрефләрне төрле буяулар белән бизи, матурлый иде... Бәгъзе фасылларның башына агачлар, гөлләр ясап җибәрә иде... Ләкин әллә нишләп бу агачлар, бу гөлләр, бу матур, хакыйкатән нәфис хәрефләр Габдулла мөҗавирнең теләген җиренә китермиләр иде, бу матурлыкларның әллә нишләп бер җебе юк кеби тоела иде. Кая ул җеп, мөҗавир белмидер иде... Яза торгач, пальмага килеп кунып, бәгъзе вакыт мөҗавирне рәхәтләндерә торган яшел кошны

ясамакчы да була, берсе әллә шайтан котыртуы аркасындамы, бер фасылны матурлый торган үрнәкнең чәчәгенә менеп тә баскан иде... Ләкин ул моны күрүе белән тәүбә-истигъфарга башлап, ул нәрсәне ясаткан иблисне куган иде... Ул аны сизгәч, "Аятел-көрси" белән бөтен бүлмәне өшкереп тә чыкты... Тагын яза башлады: тагын язу никадәр матур булса да, аны тынычлатмый иде...

Төннең ярты лары күптән үткән иде... Ястүдән соң да мөҗәвир төрле вирдләр белән, Алла белән сүзгә керешкән иде... Үзенең аңар гыйшкын, аны яратуын; аннан курыкмаганлыгын, әмма бары ярат канлыгын, бөтен тәне белән аны үзенең җан биргән, үзенә гыйбадәт итү өчен җибәргәненә мең шөкерләр кыла иде... Менә ул тынычлап намазлык өстендә йокыга китте...

Беренче таң белән төн сорыланган иде. Ул күзен ачты, яңадан йомды... Чөнки аның күз алдында ак юка бөркәнчеген ярты лаш күтәргән бер кыз тәрәзәдән карап тора иде...

Ул шикләнде: ул монда ни өчен Габдулланы шикләндерергә килгән? Кайдан килгән? Ник килгән? Ләкин аның күңелендә бая матур нәрсәләр язып, ясап та таба алмаган бер чын эчке хозурлыгы табылган иде... Бөтен матурлык шул сурәтнең эченә кергән дә баткан, бөтен изгелек шуның эчендә камырга сеңгән су кеби сеңгән шикелле иде... Кыз селкенә: үзенең матур күзләрендә бер изгелек көлүе зоһур иткән иде.

Габдулла торды... Кыз югалды, ләкин коббәнең диварына үрмәләп үскән ал роза акрын гына чүлдән искән җил белән селкенә, мөлаем бер караш белән карый кеби иде... Габдулланың куркуы бетте, шайтан аңар кыла торган вәсвәсәсен кискән кеби булды...

Менә ул иртәге ризыклык өчен, әнә шул ераста бер нәзек манара өстендәге алтын айлы, яңа кояшта ялтырый торган шәһәргә барырга, яза торган китабын бетерергә исәпләп, яңадан диварга терәлеп, иске палас өстенә утырды, буяуларын алды... Ләкин теге баягы кызның сурәте, хәзер теге яза торган китапның битендә пәйда булды. Габдулла бер изге елмаю белән карап көлә башлады...

Габдулла кулына тоткан каләмен китапның битеннән алып:

– Әйт, кардәшем, син кем, сине кем җибәрде? Син Алла тарафыннанмы, әллә шайтан тарафыннанмы? Әгәр соңгысы булса, ялгышасың, мин синең матурлыгыңа гына гашыйкмын, нәкъ әнә, бәгъзан җилнең матур сызгыруы, дөяләрнең муеннарына таккан шөлдерләренең ачык һавалы чүлдә төннәрдә чылтыраган тавышы кеби генә яратам! – диде.

Кыз тагын да бер изге төс алды, авызында, күзендә тагын да бер мөкаддәс көлү зоһур итте:

– Яз, яса! – диде ул...

– Ни ясыйм? – диде Габдулла мөҗавир. Каләме карасына, үзе теләсә-теләмәсә дә, манылды.

Калын тиренең үзәрендә каләм селкенә башлады, кызның матур күзләре өстеннән каләм йөри, каләм ясый башлады: матур кызның сөйкемле тәбәссемле йөзе тирегә чын шикелле төште...

Менә шулай итеп беренче сурәт ясалды...

Каты давыл чыкты.

– Син илаһимы, шайтаныймы? – диде Габдулла...

– Син илаһимы, шайтаныймы? – сөале яңадан тәкрәр итте...

Ләкин җавап юк иде... Төрбә өстенә ясалган авыр таш астыннан акрын гына тын тавыш, берничә сөальдән соң:

– Мөҗавирем, бу илаһи да, шайтаный да түгел, хәятый; бу матурлыкның синең күңелдәге хакыйкый һәйкәле...– диде...

Күк күкрәде, яшен яшьнәде... Җир дерелдәде...

Менә хәзер бу урында коббә дә юк, тәкия дә юк... Кая киткәне дә мәгълүм түгел...

Алай да бәгъзе вакытта, төннәрдә кунарга бу чишмә янына килгән кәрвандагы кешеләр:

– Син илаһимы, шайтаныймы? – дигән сөальнең тәкрәр ителгәнен ишетәләр, ди.

(«Аң» журналы.– 1914.– №21 (20 ноябрь).– Б.375-377).

коббә – төрбә
гайре мадди – мадди булмаган
бәгъзан – кайвакыт
истирахәт – ял
мөҗавир – дәрвиш, каберлек сакчысы
мәгъбуд – Алла
мәкъбәрә – каберлек
мәдәд – ярдәм
бәгъзе – кайбер
вирд – билгеле вакытта укыла торган догалар
зоһур итү – чыгу
үзәрендә – өстендә
тәбәссем – елмаю
хәятый – тормыштан

Рассказы
Газиза
Губайдуллина

Тюбетейка с вентилятором

Тюбетейщик Самигулла-абзы, занятый подсаживанием тюбетеек на колодки*, вдруг приостановил свою работу. Жена его Миннебикэ-абстай стояла перед горящей печью и пекла оладьи. На окне, скрипя и дребезжа, вертелся вентилятор.

– Погоди-ка, жена,– сказал он,– оставь на минутку: я кое-что хочу сказать тебе... Тот, Закир, ушел? При нем не скажу, пусть не узнает. А то сам еще начнет делать. Хитрый он человек.

– Подожди, старик, не надоедай! Сейчас приедут дочка Магруй с зятем, вон уж скоро семь часов...

– Подожди ты, оставь! Кончай эту сковородку и иди сюда!

–Вот готово! Сейчас иду!–сказала Миннебикэ и, обтирая руки о фартук, подошла к мужу.

– Ну, что скажешь?

Самигулла-абзы взял в руки посаженную в колодку тюбетейку и начал:

– Вот я выдумал новое изобретение. Вот видишь? Тюбетейщик Лутфулла пустил в ход новую выдумку: он сделал наверху тюбетейки четыре дырочки. Говорят, доктор-мусульманин похвалил его за это: теперь, говорит, для головы будет вентиляция; у татар, мол, больше голова не будет болеть, так как свежий воздух все время будет проникать вовнутрь чаплашки. А я то уж совсем на японца стал похож: выдумал совершенно новую махинацию.

– Ну, ну, говори скорее! Станешь японцем, хвастунишка ты эдакий... Чего еще там выдумал?

– Вот что я сделаю,– продолжал Самигулла,– видишь на окне вертится вентилятор: дрр, дрр, дрр... Вот такую же вертящуюся штуку я хочу приделать к отверстиям на тюбетейке. Понимаешь? Малюсенький такой вентилятор... И будет вертеться: дзинь, дзинь, дзинь! Совсем как соловей будет петь.

– Ты приделай его и к нашим колпачкам,– сказала равнодушно Миннебикэ,– пускай и нам будет прохладно.

---

* В прежнее время тюбетейки в Казани изготовлялись кустарями одиночками или же кустарями на дому по мануфактурной системе.– А.Р.

– Я сначала сделаю к тюбетейке, а там дойдет очередь и до ваших новомодных колпачков не больше воробьиной головки* . Ну-ка, дай мне ножницы и жестянку из-под монпансье, которую я намедни принес с базара. Сейчас начну делать.

– Ну, тебя! Зачем зря портить коробку? Я в нее мыло положила.

– Дай, говорю тебе! Отдай сейчас же. Тут человек хочет сделать тюбетейку с вентилятором, уничтожить, так сказать, головную боль у всей нации, а ты: «мыло положила».

Миннебикэ покорно стала искать коробку.

– Фу, ты! Не даешь даже оладьи допечь. Тут печка у меня догорает, а ты со своими выдумками. Хвастунишка!

– Ищи, ищи... Вот как станут меня в газетах расхваливать, сама, небось, будешь довольна. Все будут у меня заказывать тюбетейки. А я еще там объявление такое в газету пущу: «Я, мол, тюбетейщик Самигулла-эфенди Гиззатуллин, изготовляю по предписанию врачей знаменитые целебные, поющие тюбетейки... С почтением Самигулла Гиззатуллин». Во! Пускай гремит наша слава!

Миннебикэ-абстай все же разыскала какую-то старую жестянку.

– Как же люди будут ее носить? – полюбопытствовала она.–Ведь она надоест всем своим дребезжанием...

– Нет, это не так, жена. Он будет вертеться только до тех пор, пока из головы не выйдут вон все дурные запахи; а потом он успокоится, не будет больше дребезжать. Вон ведь наша форточка тоже не все время вертится.

Миннебикэ ушла к своей печке.

– Ну, делай, делай,– сказала она,– а я допеку свои оладьи.

– Эй, тебе говорю, зятю-то ты ни гу-гу; не то он сам начнет делать.

– Нет, нет, боже упаси! Ведь твоя радость – моя радость! Самигулла-абзы, высунув кончик языка, стал старательно разрезать ножницами жесть.

«Погоди,– думал он про себя,– я это еще так не оставлю... Я сделаю к ним такой вентилятор, который будет вертеться электрической силой, как тот, что в кинема поставлен... »

(Сборник татарской литературы (дореволюционной)/ Под ред. П.Когана; Перевод Али Рахима.– М.–Л.: Гос. изд-во. худож. лит., 1931.– С. 151–152.).

---

* Еще недавно татарки носили на голове национальный убор — бархатные колпачки, которые по тогдашней моде имели тенденцию к уменьшению в размерах, дойдя наконец до смешного малых размеров.– А.Р.

Брюки

Старый мулла Валиулла чувствовал к брюкам острую, глубокую ненависть*. Безбожье и непочтительность к старым учителям-муллам нашли в последнее время широкое распространение среди молодежи; во всем этом, казалось ему, были виноваты эти самые проклятые русские брюки... В добрые старые времена еще не носили это «вражье одеяние», а сейчас оно буквально наводнило весь мусульманский мир. На кого только ни посмотришь, все понадевали брюки!

Правда, Валиулла-хазрет не склонен был придираться к шароварам сеидов-арабов, которые приезжали сюда в месяце Рамазане, во время поста. Ибо эти шаровары, шириною в целый мир, отнюдь нельзя было назвать брюками. До сих пор еще никто не измерил ни глубины их днища, ни ширины штанин. Это не то, что противные шариату узкие брюки урусов.

Вот за этим единственным исключением Валиулла-хазрет был врагом всех брюк в мире. И в его медресе никто из двухсот шакирдов не смел носить брюк, из 600-700 мужчин его прихода ни один не носил этой части костюма.

Однако вам хорошо известно, у нас в году бывают довольно холодные времена. Вообще ведь наша «Болгарская страна» отличается холодным климатом! И вот, благодаря молитвам хазрета, купцы из его прихода, ежегодно ездившие с обозом на ярмарки в Ирбит и в Мензелинск, прекрасно обходились без брюк даже в самые лютые морозы. Говорят, нужда научит и из каждой беды есть выход; и прихожане одевали в таких случаях вместо брюк стеганые на вате синие штаны с борами.

***

Однажды Валиулла-хазрет проезжал в тарантасе по улицам Старо-татарской слободы**. Он был приглашен на свадьбу в дом одного богатого купца. То было в теплый весенний день, когда солнце, растопив снега, превратило улицы города в сплошное море грязи. Как на грех, навстречу ему попался шакирд из его медресе, сын деревенско-

---

* Лет 50-60 тому назад старозаветные татары и особенно муллы-обскуранты не терпели европейских брюк, так как, по их мнению, ношение брюк, как костюма кяфиров (неверных), было противно исламу.– А.Р.

** Часть г. Казани, преимущественно населенная татарской буржуазией.– А.Р.

го муллы по имени Сеид-Гирей. Хазрет, как строгий блюститель нравственности, сразу обратил внимание на необычайный костюм своего воспитанника. Весенний ветер трепал фалды долгополого зиляна* шакирда, который с важным видом прогуливался по тротуару, а под зиляном виднелось что-то черное. Увидя это, старый мулла тотчас остановил лошадь и, взбешенный, соскочил с тарантаса прямо на грязь.

– Эй, как тебя там, мулла Сеид-Гирей, никак ты надел брюки? – вскричал он. Сеид-Гирей чуял, что эта встреча добром не кончится.

–Таксыр,** – сказал он смущенно,–это такие черные штаны...

Хазрет пощупал брюки рукой:

– Ах, шайтан, бесстыдник! Что же это такое, как не брюки? Они и есть вражья одежда! Это и есть причина позора всего мусульманства!

– Таксыр, это только так, от холода я...–начал было шакирд, оправдываясь, но это его не спасло.

– Нет, сними, сними!–приказал строго мулла.

– Хорошо, таксыр!–промолвил шакирд и хотел было уйти восвояси, но не тут-то было. Хазрет остановил его.

– Ты куда? Нет, снимай сейчас же! – закричал он.– Нет тебе иначе моего благословения, решительно не дам...

– Таксыр,–взмолился молодой человек,–пожалуйста, разреши дойти обратно до медресе; там уж я сниму. Ведь, ей-богу, опозорюсь я: ничего у меня под ними нету.

– Нет, сними сию же минуту, тут перед моими глазами! Сними врага! Нечего тут долго раздумывать. Иначе сейчас же оставь за непослушание мое медресе. Не будет тебе никакого благословения! Клянусь богом, прокляну... И отцу твоему напишу...

– Умоляю, дай отсрочку, хазрет?

В это время около них остановились русский стекольщик и одна старуха нищенка. Постепенно около этой группы стала собираться праздная уличная толпа.

– Не позорь меня перед народом, хазрет!–продолжал плакаться бедный Сеид-Гирей.

– Нет,– настаивал мулла,– нет на это моего согласия. Эта гадость из всех гадостей – позор всему мусульманству; каждый твой шаг оскорбляет весь мусульманский мир... Снимай!

Что же делать шакирду? Неужели оставить школу? Куда пойдешь? Пожалуй, придется снять.

---

* Татарский верхний костюм в виде халата с отложным воротником.– А.Р.

** Почтительное обращение к муллам.– А.Р.

Да, в те времена люди еще не были так безбожны, как теперь, тогда еще умели ценить учительское благословение... И Сеид-Гирей согласился снять. В разговор вмешался стекольщик, русский:

– Молодец, мулла! – сказал он. – Так и надо разделываться с ворами. Хочешь, я сам пойду в суд за свидетеля?

Так подбадривал он хазрета. По незнанию языка бедняга думал, что тут дело касается кражи брюк. Он ввел в заблужденье и нищую татарку:

– У, подлец! – сказала она. – Сам еще учащийся-шакирд, а брюки украл...

Она была вполне солидарна со стекольщиком.

Наконец Сеид-Гирей принялся снимать брюки. Когда он под зиляном развязал полотенце, обернутое вокруг талии вместо кушака, что-то громоздкое и широкое упало на землю. Это был подол какого-то другого платья. Затем он снял и самые штанины.

Как вы думаете, чем оказались брюки, так напугавшие нашего хазрета?

То было не что иное, как другой зилян, только надетый в обратном направлении. Чтобы «пофорсить», Сеид-Гирей занял у товарища зилян, надел его рукава себе на ноги, а полы обвязал вокруг талии под платьем. В таких самодельных брюках пошел было он щеголять по улицам города, да к несчастью, навстречу попался сам хазрет...

Да, друзья мои, в былые времена умели строго блюсти все веления и запреты шариата.

(Сборник татарской литературы (дореволюционной)/ Под редакцией П.Когана; Перевод Али Рахима.– М.–Л.: Гос.изд-во. худож. лит., 1931.– С.148–150.).

Из легенд Востока
(миниатюра)

Солнце несколько убавило свой палящий зной. Горсточка зелени, затерявшаяся среди жарких песков пустыни, будто облегченно вздохнула. Среди вечерней тишины неподвижно млея отдыхали финиковые пальмы. Широкими веерами распустились их перистые листья. Тихо журчал ручеек между камнями... Ти-

шина пустыни наполняла душу покоем; сердце отдыхало от сует мирских.

Одинокая гробница под круглым куполом... Это усыпальница великого святого шейха. Триста лет уже, как прах его покоится под тяжелой плитой. И муджавир* Абдулла, так же как и многие его предшественники, охранял древнее тюрьбе**, кем-то построенное над могилой святого старца.

Благочестивый Абдулла проводил глазами проходящий по пустыне караван; долго, долго смотрел он через решетчатое окно своей кельи на солнце, медленно закатывающееся на мглистом горизонте. Звучным, как колокол, голосом пропел он призыв к молитве, и долго, истово сотворил намаз***. После молитвы громко пропел он несколько стихов из Корана, такие же знойные, как сама пустыня; воздев руки к небу тихо прочитал молитву.

Земля погрузилась в темноту. Сквозь тысячи сверкающих отверстий смотрело небо.

Полумесяц засверкал среди густых листьев пальм. Плач несчастных голодных шакалов и крик старой совы, где-то там у ручья, тихой грустью наполняли тишину ночи...

Вот в решетчатом окне одинокой кельи показался свет. Это муджавир Абдулла зажег светильник, и сел за свой ежедневный благочестивый труд. Изо дня в день переписывал он своим прекрасным почерком священные книги. И сегодня он заканчивал одну из таких рукописей. Завтра он понесет свою работу в ближайший город и вырученные деньги пожертвует бедным за упокой души своего шейха.

Абдулла украшал свое письмо цветными заголовками, и, чтобы украсить святые слова, снабжал их порой цветными узорами. Начальные страницы и отдельные главы он любил украшать заставками в виде причудливых растений и цветов... Однако это поистине прекрасное письмо, даже эти чудесные, но мертвые узоры все же не совсем удовлетворяли Абдуллу. Казалось ему, что тут чего-то не хватало. В чем была суть – он сам не мог уяснить себе...

За окном росли ползучие розы. Иногда красивая маленькая птичка садилась на ветки розы и своим пеньем услаждала слух муджавира. И не раз тянуло его зарисовать образ этой милой птички. Однажды случилось так, что он не удержался и, помимо его сознания, появилась птица среди цве-

---

* служитель при гробницах
** мавзолей

тов, украшавших начало одной главы. Должно быть сам лукавый шайтан двигал тогда его рукой. Тотчас же с покаянной молитвой отогнал он от себя лукавого и снова с молитвой принялся строчить святые слова...

Но, странно, красивые арабески письма не успокаивали больше его, не удовлетворяли его чувство красоты...

Полночь уже давно миновала...

После ночного намаза Абдулла по своему обычаю отдался задушевной беседе со своим божеством...

В бесконечных славословиях изливал он ему свою пылкую любовь. Он не боялся своего бога, нет, он любил его нежной любовью, так как влюбленный юноша любит свою прекрасную подругу. Утомленный, тихо уснул он, наконец, на своем молитвенном ковре...

Еще неясно серел голубой рассвет, когда он в полудремоте раскрыл свои глаза. Открыл и снова смущенно закрыл их. Ибо ему показалось, что приникнув к окну глядела на него, полуподняв свое прозрачное покрывало, прекрасная девушка. Сомнение закралось в душу муджавира... Зачем она пришла сюда смущать его покой? Откуда появилась эта прекрасная дева? Что ей нужно здесь? Но, странно: великое удовлетворение и покой разливались в его душе при виде этой девушки... Вдруг он обрел в своем сердце то удовлетворение прекрасным, которого он напрасно искал среди прекрасных изгибов письма, среди расцвеченных роз, перевитых фантастическим растительным узором... Ибо это была истинная, живая красота. Ему чудилось, что вся красота мира, вся благость и святость сосредоточились в этом дивном образе... Святая улыбка озаряла прекрасные очи девушки, и она тихо кивала ему через узорную решетку окна...

Дервиш вскочил на ноги... Виденье исчезло как дым... Лишь розовый куст, ползущий по каменной решетке, весь усыпанный розовыми цветами, тихо качался под дуновением утреннего ветерка; и, казалось, улыбаясь любовно смотрели на него эти розы... Исчезло наважденье дьявола, и вновь успокоился Абдулла...

Следовало докончить незаконченную с вечера работу. Он сел на свой старенький коврик и взял в руки книгу. Прямо перед ним за окном, вдали, в лучах невидимого восходящего

*** установленная молитва

солнца сверкали сквозь туман золоченые купола далекого города. Расставив около себя краски, он в каком-то экстазе взялся за перо. И, о чудо, перед его взором на пустой странице, лежащей на его коленях вдруг ясно выступил образ той девушки. Улыбаясь глядела она на него. И улыбка ее была та же, святая, благостная...

– Скажи, о сестра,– взмолился Абдулла,– кто же послал тебя ко мне? От бога ли ты или от дьявола? Если ты посланница дьявола, то ошибаешься, думая совратить меня, я влюблен лишь в твою красоту. Я люблю тебя точно так же, как люблю заунывный свист ветра и мелодичный звон верблюжьих бубенчиков ясной ночью в чуткой тишине пустыни...

И говорил он точно скандировал стихи.

Выражение благости еще яснее выступило на лике девушки. Блаженная улыбка озарила ее глаза и губы. Странное чувство было в душе у дервиша. Казалось, его столь любимое божество само воплотилось в этом образе. И, странно, эта мысль вовсе не испугала его...

– Рисуй! – будто сказала девушка еле слышно, шевеля прекрасными губами.

– Что же мне рисовать?– спросил Абдулла.

Перо его невольно окунулось в чернила и стало водить его руку по толстому лощеному пергаменту. На лощеном пергаменте выступал чудный образ. И в каком-то порыве вдохновенно водил он по каждой черте его. И миловидное, улыбающееся лицо девушки, прекраснейшей из прекрасных, точно живое появилось на странице священной книги...

И так появился из-под пера муджавира первый живой образ. Поднялась буря, страшная буря...

– От бога ты или от дьявола?– вопрошал в страхе Абдулла.

Ответа не было.

– От бога или от дьявола? – повторял он в исступлении.

Никто не отвечал.

И вот, наконец, из-под тяжелой нагробной плиты будто раздался заглушенный голос старого шейха:

– Это не от бога и не от дьявола, о муджавир мой, это только от жизни... Это лишь отражение великой красоты в душе твоей...

Загремели громы, засверкали молнии... Затряслась, заколебалась земля...

И вот ныне на этом месте нет ни гробницы, ни кельи при ней. Неизвестно, куда они исчезли...

Рассказывают лишь, что когда караваны останавливаются на ночь у здешнего источника, будто путники иногда слышат неизвестно откуда доносящийся, вечно повторяемый вопрос:

– От бога ты или от дьявола?

1914 г.

(Перевод Али Рахима. Рукопись хранится в Восточном секторе Отдела рукописных и редких книг научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского Казанского государственного университета).

Газиз Гобәйдуллинга багышланган мәкаләләр һәм аның турында истәлекләр

Статьи, посвященные Газизу Губайдуллину и воспоминания о нем

Газиз әфәнде Гобәйдуллин

Былтыр Казан дарелфөнүненең тарих вә әлсинә шөгъбәсен тәмам иткән Газиз әфәнде Гобәйдуллин бу көннәрдә үзенең государственный имтиханнарын биреп, беренче дәрәҗә диплом белән тәмам итте.

Газиз әфәнде бу буын зыялыларымыз арасында тарих вә әлсинә шөгъбәсен тәмам иткән бердәнбер зыялымыздыр.

«Кояш» газетасы.– 1916.– 14 июнь (№981)

дарелфөнүн – университет
әлсинә шөгъбәсе – филология факультеты

ДИПЛОМЪ.

Предъявитель сего, **Абдулъ-Газизъ Салиховичъ Губайдуллинъ**, сынъ купца, исповѣданія магометанскаго, по выдержаніи въ ИМПЕРАТОРСКОМЪ Казанскомъ университетѣ полукурсового испытанія и по качествѣ опредѣленныхъ уставомъ числа предметовъ изъ историко-филологическихъ факультетъ сего университета, выдержалъ испытаніе въ историко-филологической испытательной комиссіи при томъ-же университетѣ въ сессіи 1916 года, по отдѣлу историческому, при чемъ оказалъ успѣхи:

НА ПОЛУКУРСОВОМЪ ИСПЫТАНІИ ВЪ ФАКУЛЬТЕТѢ:

введеніе въ философію весьма удовлетворительные, по логикѣ удовлетворительные, по психологіи весьма удовлетворительные, по латинскому языку весьма удовлетворительные, по греческому языку весьма удовлетворительные, по введенію въ языкознаніе весьма удовлетворительные, по исторіи русской словесности весьма удовлетворительные, по исторіи западно-европейскихъ литературъ весьма удовлетворительные, по методологіи и философіи исторіи весьма удовлетворительные, по исторіи Греціи удовлетворительные, по исторіи Рима весьма удовлетворительные и по исторіи искусствъ весьма удовлетворительные.

НА ОКОНЧАТЕЛЬНОМЪ ИСПЫТАНІИ ВЪ КОМИССІИ:

древней исторіи весьма удовлетворительные, по средневѣковой исторіи удовлетворительные, по новой исторіи весьма удовлетворительные, по исторіи славянъ весьма удовлетворительные, по исторіи новой философіи удовлетворительные, по русской исторіи весьма удовлетворительные и за сочиненіе весьма удовлетворительные.

Посему, на основаніи ст. 81 Общаго Устава ИМПЕРАТОРСКИХЪ Россійскихъ университетовъ 23 августа 1884 года, г. **Губайдуллинъ** постановленіемъ историко-филологической испытательной комиссіи 28 мая 1916 года удостоенъ диплома **первой степени** со всѣми правами и преимуществами, поименованными въ ст. 92 Устава и въ Высочайше утвержденномъ въ 15 день августа 1884 года мнѣніи Государственнаго Совѣта. Въ удостовѣреніе сего и дабъ сей дипломъ г. **Губайдуллину** за надлежащимъ подписаніемъ и съ приложеніемъ печати Управленія Казанскаго учебнаго округа. Казань 20 дня 1917 года.

Попечитель Казанскаго Учебнаго Округа

Предсѣдатель Историко-Филологической Испытательной Комиссіи

Правитель Канцеляріи

Җамал Вәлиди

Гыйлем юлында зур бер казаныш

Бездә гыйлем, фикернең гасырлар буенча дин монополиясендә яшәп килгәнлеге мәгълүм. Ләкин әле яңару дәвере башланганнан соң да байтак вакытлар бездә бу мәйданда шактый озак вакытлар дини караш хөкем сөрде. Бездәге җәдит дәверендәге чын галим исеме бирерлек кешеләрнең, һәммәсе дип әйтерлек, дин галимнәре булып, аларның тарихи, иҗтимагый хезмәтләре дә дин рухы белән сугарылган. Аларда хәзерге заманның зур-зур мәсьәләләрен дини күзлектән карап чишелергә тырышылган була иде. Бу турыда Риза хәзрәтне генә алырга, аның зур гыйльми хезмәтләренә генә күз салырга кирәк.

Гомумән, бездә 1910 нчы елларга кадәр дөньяви мәгънә белән генә галим булган бер кешене тотып күрсәтергә мөмкин түгел иде. Дөньяви зыялыларыбыз әле безнең публицистлык яки әдәбилек мәйданында гына эш күрәләр иде.

Чама белән 1910-15 нче еллар арасында, ягъни олы революциянең алдында, бездә дә дөньяви галимнәр баш күтәрә башлады. Бу безнең гыйльми, фикри тарихыбызда яңа буын җитешү дигән сүз генә түгел. Бу безнең фикри тарихыбызда зур бер инкыйлаб туу дигән сүз иде.

Бу инкыйлабның бездә гомуми кузгалыш тудырган 1905 нче елларда ук баш күтәрмичә, аннан 5-10 еллар соңга калуының бик табигый сәбәбе бар: яңа нигездә гыйльми хәзерлек алу, гыйлем, фән белән нык кораллану өчен кимендә шул кадәр еллар вакыт кирәк. 1905 тә фикере ачылган шәкертләр шул вакытта ук шигырьләр, хикәяләр, гәзитләргә мәкаләләр язарга булдыра алсалар да, аларның бу мәйданда, заманына күрә, яхшы ук алга чыкканнары булса да, боларның күбесе дини тәэсирдән азат дип әйтмим, бөтенләй дини дип әйтерлек дәрәҗәдән узган булсалар да (бисмилласыз язылсалар да) гыйлем, фән мәйданында бисмилласыз китаплар тудырырлык көчләр юк иде. Моның өчен тәрәкъкыйның кирәклеген белү һәм «башка халыклар тәрәкъкый итсәләр дә, безнең милләтнең тәдәннидә» икәнен сизү, хәтта моннан үтеп китеп, кәсер саннарда да дүрт гамәлен эшләү, шул

заманча әйтсәк, глаголлар белән управлять итә белү, Пушкиннар, Белинскийлар белән танышу, нинаять, бу мәйданда хрестоматияләр даирәсеннән чыгып, урыс әдәбиятының чынлап эченә керә башлаулар гына, әлбәттә, җитми. Ә шәкерткә шул баскычларны үтмичә, гыйлем бусагасын атлап керергә мөмкин түгел иде.

Мин 1915 нче елда «Аң» журналында басылган «Шәрекътән Гаребкә» дигән мәкаләләрдә шушы мәсьәләгә туктап, анда гыйлем мәйданында дини фикернең монополиясе бетә башлаганлыгын, бездә дә дөньяви гыйлемнең баш калкытканлыгын, бу турыда эш күрүче каләмнәрнең әле яшь шәкертләр генә булганлыгын, шулай булса да, аларның арасында үзләренә зур өметләр баглатканнары булганлыгын язган идем һәм шушындый өметле каләмнәрдән итеп өч кешене исеме белән атап күрсәткән идем.

Бу өч кешенең берсе бу мәкаләчекне язарга сәбәп булган Г.Газиз иптәш иде.

Әйе, Г.Газиз бездә гыйлемне дөньяви мәйданга өстерәп чыгаручылардан, икенче төрле әйтсәк, аны күктән җиргә төшерүчеләрдән берсе, шушы зур эшнең пионеры булды.

Шуның өчен без Газизгә бәя биргәндә аның язган нәрсәләренең гыйльми кыйммәтен тикшерүдән башламаска, бәлки аның тарихи, мәдәни әһәмиятен алга куярга тиешбез.

Минем күз алдымда шул заманның гыйльми, тарихи, шуның белән бергә ярымдини «Шура» журналы. Мондагы һәрбер җитди мәкалә дип әйтерлек дини рухта язылган, монда ислам фәлсәфәсенең иң соңгы ирешүләре нык шәүләләндерелгән. Менә берва-кыт шушы журналда һичбер аять, хәдисләр язылмаган, дини оеткы салынмаган, аның урынына әллә нинди урысча, французча китаплардан цитаталар белән булган гыйльми, иҗтимагый, тарихи мәкаләләр күренә башлый. Асларына «Г.Газиз» яки «Газиз Гобәйдуллин» имзасы куелган бу мәкаләләр, әлбәттә «Шура» укучыларына башта ятрак тоелгандыр, ләкин алар торган саен күбәйде; бераздан Казанда «Аң» журналы чыга башлап, ул гыйльми ягы бөтенләй шушы типтагы дөньяви журнал булды. «Аң»-да Газиз иң күп язучыларның берсе. Ул анда гыйльми мәкаләләре белән генә түгел, үзенең әдәби әсәрләре белән дә катышты. Бу журналның Газизсез номеры аз чыккандыр.

5-6 телдә китап мотәлага итә торган, бик күп укыган, үзенең гыйлемендә йөзә торган бу кеше һәрвакыт шаярып йөрүче һәм үзе шикелле үк шаян хикәяләр язучы бер мәзәкче дә. Шәфигый бугай әйткән, дин фәкъкыйһ (юрист) булмасам, шагыйрь булыр идем, дигән. Газиз дә әгәр галим булмаса, әдиплек белән генә дә

яхшы танылган булыр, бу хәлдә аның әдәби каләме бәлки күбрәк тә җимеш биргән булыр иде.

Бик кыска булуы шарт ителгән бу мәкаләчек Газизгә профессорлык дәрәҗәсе бирү уңае белән языла. Монда иң элек профессорлыкны алучының кем булуыннан башка бездә профессорлыкны алучының булуы, шушы факт үзе бер гыйбрәтле хәл. 15 еллар элек кенә бездә студент булу, хәзерге профессор булудан бер дә ким түгел иде. Әле студентка барасы түгел, шул вакытларда бер журналда «Гимназия бетергән татар кызы» дип берәүнең рәсемен басып чыгарганнары хәтеремдә.

Газизне татардан икенче профессор дип яздылар. Әйе, ул татарлардан югары дәрәҗәдә гыйльми квалификация алучыларның икенчесе бугай. Ләкин Газиз татарның үз тормышы эченнән, татар тарихындагы соңгы дәверләрнең дулкыннары эченнән кайнап чыккан беренче профессор, ул егерме яшьләренә кадәр мәдрәсәдә яткан. 25 яшьләрендә генә университет бусагасына барып егыла алган һәм без дә аңа кадәрге күбрәк гали мәктәпкә керүчеләр кебек врачлык, юристлык кебек юлларга китмичә, яңа бер юлга, татарның үз тарихын, әдәбиятын өйрәнү юлына кергән, шул турыда профессорлык дәрәҗәсенә кадәр ирешә алган беренче кеше.

Газизнең гыйльми хезмәтләре хакында язарга, бу кечкенә мәкаләчектә аз һәм ул турыда язарга әле вакыт бар (профессорлык алу әле гыйльми мәйданына ныклап аяк басу дигән сүз генә).

Мин монда мәсьәләнең ул ягына кагылмыйча, бигрәк бу хәлнең безнең өчен зур тарихи әһәмиятен һәм Газизнең, бая әйткәнчә, татарда гыйлем, фән пионеры булуы ягыннан әһәмияте зурлыгын басып әйтергә телим.

Яшь гомерен мәдрәсәдә урта гасырлар схоластикасы белән үткәргән татар шәкертенең университетка барып керүе бик зур каһарманлык, һәм бик зур бәхет иде. Моңа бик аз кешеләр генә муаффәкъ булды. Инде моннан үтеп китеп югары мәктәпнең кафедрасына менеп аяк басу янә кечкенә эш түгел, гыйлем эшендә бу кадәр тигәнәкле юлларны үткән, бу кадәр киртәләрне җимергән бу иптәшкә сокланып карамаска, аны нык алкышламаска мөмкин түгел.

Шуның белән бергә әле кырык яшендә генә булган Газиздән без киләчәктә янә бик күп җимешле хезмәтләр көтәргә хаклыбыз.

(«Безнең юл» журналы.– 1927.– №11.–Б.38-39.)

тәдәнни – мәдәниләшү
кәсер сан – вакланма
муәффәкъ булу – ирешү

Н.Н.Фирсов

Профессор Газис Салихович Губайдуллин

Получено известие о возведении Г.С.Губайдуллина в звание профессора Бакинского университета по кафедре истории турецких народов. Это едва ли не первый случай профессуры по специальным наукам представителя татар. Татарская Автономная Республика и, в частности Казань, могут поставить данный факт на свой счет, ибо Г.С.Губайдуллин – казанский уроженец и в нашем городе получил свое научное образование.

Родился Г.С.Губайдуллин в 1887 году. Получив среднее образование он подготовился к поступлению в Казанский университет, в котором он окончил курс с большим успехом по историко-филологическому факультету в 1918 году.

В 1919 году мне удалось не только представить, но и привести Г.С.Губайдуллина к оставлению при университете для приготовления к профессорскому званию по кафедре истории России со специализацией по истории татарских народов на территории Восточной Европы. В практике Казанского университета это был первый почин по отношению к студенту-татарину, многим он казался диким и потому кандидатура Г.С.Губайдуллина прошла не без трений. Сделавшись преподавателем истории высших учебных заведений Казани, сначала Восточной академии, потом после ее ликвидации Восточного педагогического института, Г.С.Губайдуллин написал и напечатал целый ряд исторических трудов, как то: 1) Историю татар; 2) К истории классов; 3) Историю татарской литературы древнего периода. Последний труд был исполнен в сотрудничестве с другим талантливым татарским ученым Али Рахимом.

Г.С.Губайдуллин по некоторым причинам не остался в Казани. Он перешел в Бакинский университет и там его по заслугам возвели в профессорское звание и утвердили деканом Восточного факультета

(Еженедельник газеты «Красная Татария».– 1927.– 27 ноября (№13))

Гали Рәхим

Г.Газиз әсәрләре

(Төзүчедән)*

Г.Газиз – татарның матур әдәбиятында үз-үзенә бер төрле урын тота торган язучы.

Ул – юморист-һөҗүче. Аның чын стихиясе – вак-вак кына көлкеле хикәяләр. Г.Газизгә кадәрле безнең яңа үсеп килә торган әдәбиятта һөҗүчелек һәм юмор чаткылары күренеп-күренеп китсә дә, бу жанрны үзенең әдәби иҗаты өчен төп юл [итеп] алган язучы юк иде.

Татардагы шәһәр обывателе, мещан, вак буржуа тормышын мәүзугъ итеп алып, шуны бөтен ваклыклары, түбәнлекләре белән кечкенә көлкеле хикәяләр рәвешендә безнең күз алдыбызга салучы беренче әдип Г.Газиз булды. Бу яктан аны урыс әдәбиятындагы мәшһүр Чехов белән тиңләштерергә була.

Г.Газизнең әдиплек гомере 20 елдан артыграк бер дәверне эченә ала. Аның хикәя рәвешендә язылган беренче әдәби әсәрләре 1906–07 нче елларда «Казан мөхбире» газетының битләрендә башлана. Шунда аның «Марс, уян!» исеме белән бер хикәясе басылып чыкты. Символизм юлы белән язылган бу хикәядә ул шул вакыттагы Гаага конференциясеннән, аның икейөзле Европа империалист дәүләтләренең төче телләнеп «мәңгелек солых» корырга тырышуларыннан ачы сатира рәвешендә көлгән иде. Аның бу хикәя-сатирасы, шактый муаффәкыятьле язылганлыктан, шул вакыттагы Казан урыс газетларының берсендә урыс теленә тәрҗемә кылынып та басылып чыккан иде.

«Марс, уян!» хикәясе яшь Газизнең матбугат мәйданында беренче чыгышы иде. Шул рәвешчә ул үзенең язучылык хәятын бер әдип – бер матур әдәбиятчы булып башлады. Ләкин бу башлангыч дәвердә матбугат мәйданына аның бик аз әйберләре чыкты. Берничә фельетон характерындагы әйберләре «Казан мөхби-

---

* Гали Рәхимнең бу мәкаләсе 1930 елда дөнья күргән «Г. Газиз хикәяләре» китабына кереш сүз буларак язылган, әмма анда басылмаган. Мәкалә автор кулъязмасыннан алынды.– *Төз. иск.*

ре»ндә басылсалар да (мәсәлән, 1907-08 нче елларда басылган « Бөек корбан» дигән фельетоны). Бу дәвердә – язучылыгының башлангыч дәверендә – әле ул «Г.Газиз» дип түгел, бәлки «Г.Г.» дип кенә имза куя иде.

Г.Газиз бу вакытта ук хикәяләр яза иде. Ләкин анда бер төрле үз-үзенә ышанмый караучылык бар иде. Ул язган хикәяләрен иптәшләре мәҗлесендә генә уку белән канәгатьләнә иде. Оригиналь әдәби өслүбенә, тормышны күзәтүдәге осталык һәм нечкәлегенә өстәмә буларак, анда тагын үз әсәрләрен артистларча оста һәм килештереп укый белү таланты да булганга, аның әсәрләре иптәшләре, дуслары тарафыннан бик зур интерес белән тыңлана, алкышлана һәм тәкъдир ителәләр иде. Шулай да ул, үзенең күп әйберләренә артык әһәмият бирми, бер каләм шаярту шикеллерәк итеп кенә караганлыктан, бастырырга артык омтылмый, аларны укыганнан соң өстәл тартмасына ташлый бирә иде*.

1913 нче елга кадәр шул хәл дәвам итте. Бу дәвергә кадәр Г.Газизнең басылып чыккан әйберләре күбесенчә әдәби тәнкыйтьләрдән гыйбарәт булды. 1913 нче елда «Аң» журналы чыга башлады. Иптәшләренең кыставы белән ул үзенең басылуны көтеп яткан эреле-ваклы, тәмам булган һәм булмаган хисапсыз хикәяләре, әдәби этюдлары арасыннан сайлап-сайлап «Аң» битләрендә бастыра башлады. Яңадан яңа язылганнары да арага керә барды. «Аң» укучылары, әдәбият сөючеләр бу оригиналь әдипне бик тиз тәкъдир иттеләр.

Шул «Аң»ның сөелеп укыла торган, әсәрләре көтелеп алына торган язучылардан булып китте. Г.Газиз хикәяләре «Аң»да басыла торган әдәби материалны җанландыручы, анда тулып яткан күбесенчә сентименталь һәм романтик әдәбият арасына шат сангвиник рух кертүче ролен уйнадылар; «Аң» тирәсендә эшләүче башка әдипләргә дә үрнәк булып, аларны да юморга, көлкеле мәүзугъларга язарга сәвекъ иттеләр (Фатих Әмирхан, Тинчурин h.б.). Ләкин Г.Газиз һичбер вакыт үзенең оригинальлеген җуймады. Үзе язышында һичбер кемгә иярмәгәне шикелле, чын мәгънәсе белән үзенә тәкъдидчеләр дә тудырмады. Чөнки ул артык үзенчә, артык индивидуаль бер талант иде. Үзенең хәзергә кадәр сузылып килгән әдәби гомерендә ул үзенең бер алган юлыннан аерылмады, башта сайлаган төп әдәби сызыгыннан язмады. Әдәби иҗат юлында тик үз-үзенә садыйк калды һәм шуның белән яхшы да итте.

---

* Дөресен әйткәндә, бер вакытта татар матбугатында гомумән вак хикәяләрне бастыруга мәйдан да юк иде әле. Әдәби журналлар әле тумаган иде.– Г.Р.

Г.Газизнең чыгышы татар әдәбиятында өр-яңа бер хәдисә булды; чөнки ул үзенә мәйдан итеп, мәүзугъ итеп үзенә кадәр татар әдәбиятында сөрелмәгән бер яңа җирне сөрә башлаган, кеше кагылмаган бер онытылган почмакның пәрдәсен күтәргән иде. Аңар кадәр яңа баш күтәреп килә торган татар әдәбиятында татар тормышының байтак яклары яктыртылды: урта һәм эре буржуа-байлар тормышына да күп урын бирелде, тәнкыйть ителде, авыл крестьян тормышына да кирәгеннән аз булса да, кагылган өлешенең төп массасын тәшкил иткән вак буржуа-мещан стихиясе, ни өчендер әдипләрнең дикъкатеннән читтә калып, аларның каләм чыгырларына әле керми калып торадыр иде. Бу нормаль булмаган бер хәл иде. Чөнки татар әдәбияты үзенең «тәрәкъкый» һәм «җәдитлек» юлындагы каһарманча көрәшендә искечелекнең, тәгассебнең авангардын тәшкил иткән фанатик муллаларга, алдар ишаннарга, кара, тискәре байларга, байгураларга каршы әллә ни кадәр сөнгеләр сындырган булса да, шул авангардның шәһәрләрдә төп арка таянычын, төп базасын тәшкил иткән мещан, ул заманның эре буржуасы тәгъбире белән әйтсәң «вак-төяк халык» галәме әдәбиятта җанландырудан кырыйдарак калып килде.

Менә шул галәм калдыклары, әле дә булса исән булган шул «караңгылык галәме», Г.Газизнең үткен каләме астында җанландырылды; шул галәмнең җанлы типлары үз иҗтимагый катлауларына хас һәм характерлы телләре белән сөйләшеп үзләренең бөтен кызганыч фикер даирәләре, психологияләренең бөтен нечкәлекләре белән безнең алга килеп бастылар. Төп Казан кешесе булуы, кечкенәдән төрле кешеләрен күреп татар арасында үсүе Г.Газизгә ул типларны ифрат реаль буяулар белән тасвир итәргә мөмкинлек бирде. Аның хикәяләрендә Казанның мещан, вак буржуа типлары чып-чын бер «портретлар галереясы» тәшкил итәләр. Кемнәр, кемнәр генә юк анда! Казанның «татар арасы» дип йөртелә торган кисәгенең бөтен характерлы почмакларында торучы, үзләренең тормышларында бөтенләе белән вак, ифрат вак интересларына чумылып калган, бакалар сазда яшәгән төсле үзләренең шул тормыш сазлыкларында чыр-чу килеп гомер итүче «агай-әнеләр», Печән базары типлары, вак сәүдәгәрләр, мастеровой-кустарьлар, картлар, карчыклар – һәркайсы бу галереяда үзләренә урын табалар. Яңа бистә, «Ак ком асты», «Тегәрҗеп урамы», «Забут арты», «Забут урамы» гражданнары – һәммәсе колакларыннан өстерәлеп кояш яктысына чыгарылалар.

Октябрь революциясенә, Совет властена 12 ел узуга карамастан, бу типлар әле һаман да булса дөньяда яшиләр. Казанда та-

тар урамнарында йөргәндә әле һаман да нәкъ Газиз хикәяләреннән яңа гына сикереп төшкән төсле типларны, шул ук «сәүдәгәрләрне», шул ук картларны, карчыкларны һәр адым саен очратырга була. Менә шуның өчен Газизнең моннан 15 ел элек язылган хикәяләренең иҗтимагый әһәмияте әле хәзер дә булса югалмаган; алар әле һаман да коры тарих булып кына калудан ераклар.

Менә сезгә, үзе алдан барып, хатын белән рәттән бару «агай-әне алдында яхшы түгел» дип, бала күтәргән хатынын артыннан ияртеп кенә баручы мещан, базардан кавын күтәреп кайтканына «агай-әне»дән ояла торган «талчукчы Хәким агай», менә, үзенең үлгән хатыны янына «нәмәхрәм ир мәет» күмелгәнгә пошынып, бөтен кәефе кырылган Галим хаҗи; менә Әхмәдулла хаҗының сәламен алмавы өчен вөжданы газаплана торган Әхмәтҗан абзый; менә бөтен рухани интересы, бөтен тормыш идеалы сәгатьне дөрес йөртү белән чикләнгән, «сәгать пәрие кагылган» Шәмсетдин абзый; менә бөтен тапканын эчеп бетерүче, ләкин исереклек хозуры арасында да бүген саткан бишмәтенең кесәсендә киткән ун тиен акча өчен пошынучы исерек кәвешче Дәмин агай; менә «хифзы сыйххәткә муафыйкъ» форточкалы кәләпүш уйлап чыгару белән җенләнгән «тәрәкъкыйпәрвәр»ләшкән кәләпүшче; менә Печән базары гайбәтенең мәркәзе, аның «фокусы» булган чәч алучы Шәрәфи; менә бичара сәдакачы бабайны мыскыл итү, хурлаудан ләззәт таба торган бай; менә гомере буенча бөтен нәрсәдән зарланып торучы, бөтен фидакярлеге «әллә кайда, җәһәннәм астында» тора торган дусты Хәмди абыстайга «мәүлед укыган җиргә» барудан узып торган Хәкимә әби; менә Хан мәчете астына күмелгән, әллә нинди гомердә булмаган изгеләр белән хыялланучы Хәбибә әби... һәм башкалар, һәм башкалар... алар бик күп, санап бетергесез...

Шулар арасына тагын башка төрле типлар да килеп керәләр. Менә эшлексез иркә бай баласы «потомственный почетный гражданин» Шәриф абзый; менә бөтен дөньядагы нәрсәне икегә бүлү белән генә шөгыльләнүче карт «хәзрәт»; менә чалбар урынына аягына җилән җиңе киеп, Проломный урамда йөреп «форсить» итүче иске мәдрәсә шәкерте; менә чалбар кигән шәкертләрен урамда очратып, халык алдында чалбарын салдырып тәхриб итүче икенче бер «хәзрәт»; менә тагын Төркиядән укыр-укымас кайтып, башына фәс киеп, «без госманиез» булып йөрүче бер «әфәндем» тибы; менә бөтен идеаллары урысча язганда «и» хәрефен дөрес язудан узмаган морзалар, шкульниклар...

Менә болар һәммәсе электә тормышта булган, туп-туры тормышның үзеннән алынган, ләкин фотографик рәвештә алынма-

ган, бәлки реаль һәм күпләренчә җыючы характерлы, җанлы хәлендә алынган кешеләр иде.

Бу кызганыч мещан җаннар, үзләренең бөтен вак буржуа психологияләрен, үзләренең искергән, тузган талчукчының капчыгындагы иске-пыскылар төсле, идеологияләрен түкми-чәчми аркаларына төягән хәлдә, Октябрь революциясе дәверенә килеп керделәр. Менә шунда аларның чын рухи фаҗигаләре, траги-комик хәлләре башланды. Бу бичараларның бөек революцияне ничек каршылаулары, ничек уздырулары, ничек аны аңлый алмый, башларына кертә һәм сыйдыра алмый аптыраулары һәм гаҗиз булулары...

Менә болар һәммәсе Г.Газизнең хикәяләрендә чалыш көзгедә күренгән төсле чагылып күренәләр.

Менә сезгә Февраль революциясе чорында тилереп, митингларда «вак сәүдәгәрләр исеменнән» чыгып нотык тотучы, соңга калган «панисламист» Хиффәтҗан; менә «Болак җөмһүрияте» чорында кулына винтовка тотып чыккан, әмма үзе патрульнең янына да барырга курка торган «батыр» агай-әне Ибраһим хаҗи... электә бөтен интересы «көндез сәүдә итү – кич тәфсир уку» дан артыкка китмәгән әллә кем. Байларның башына хәзер мал күмү, мал яшерү дигән зур бер кайгы төшкән; электә бөтен ирешелмәс «идеалы» «управа члены булу»дан гыйбарәт булган Колак Шәрәфиләр хәзер «большевиклар бүген бетәләр, иртәгә бетәләр» дигән коры «көтү» хыялы белән генә яшәргә калганнар; яки аларның теге Кәрим абзый шикелле эмиграция җәннәтенә әләгә алмый «большевик тәмугында» утырып калганнары кайчан да булса бер «тегендә» китү хыялы белән генә сулу алалар; яисә алар үзләренең хәзерге төссез-әшсез тормышларын «иске замандагы» шәп тормышлары белән мактанып бизәкләргә, шуның белән онытылырга телиләр. Хасыйле, болар һәммәсе хәзерге тормышта «артык» булган «садыйк» кешеләр булып калганнар. Аларның бөтен траги-комедияләре шунда...

Шуңар күрә дә Г.Газизнең революция дәверендә язган хикәяләре тагын да кызыклырак, аларның иҗтимагый сатира булу ягыннан әһәмиятләре тагын да зуррак. Хәзерге әдәбиятта әле һичбер яңа язучы бу галәмне шул кадәр ачы көлү аркылы тасвир итә алганы юк. Шуның өчен дә без аның соңгы елларда бераз тынып торганнан соң яңадан хикәяләр язарга керешүен зур канәгать һәм алкыш белән каршыларга тиешбез.

Элекке хикәяләрендә Г.Газиз бер сатирик булырга караганда, бер юморист иде. Чөнки теге типлар – алар заманасының иҗтимагый тормышының бөтен барлыгыннан килеп чыккан, шул заман тормышы өчен бер необходимость булган типлар иде. Шу-

ңарга күрәмедер, безнең әдип аларны язганда никадәр алардан көлсә дә, аларга карата ачы истиһза кулланмый, бәлки тормышта алар ничек булган булсалар, шул килеш арттырмый-киметми ала да яза; алар турында объектив караш белән язылган, реаль тондагы хикәя ул вакытның либераль укучысы өчен үзеннән-үзе көлкеле булып чыга иде. Авторның үз типларына карашында ачу, каш җыеру элементы юк; ул үзенең картларына, карчыкларына балаларга караган шикелле сабырлы бер караш белән карый, җиңелчә генә бер елмаю белән алардан көлә, гүяки эченнән аларны кызгана, «И мескенкәйләрем, бичаракайларым, йөрегез инде шулай үзегезнең кечкенә шатлыкларыгыз белән шатланып, кечкенә кайгыларыгызга кайгырып...» дип аркаларыннан сөеп кенә көлгән төсле була иде. Бигрәк тә борынгы патриархаль бабайлар, әбиләргә нисбәтән шулай иде. Ул аларның «кешелекләрен», рухларының яхшы якларын да яшерми, аларны да күрсәтә, укучыга үзенең каһарманнарын бер яклы гына итеп тәкъдим итми иде. Шуңар күрә дә, без аның элекке хикәяләрендә дә, бигрәк тә картларны тасвир кылганнарында, шактый гына лиризм моментлары да очратабыз. Аларның вак һәм кечкенә тормышларын тасвир кыла торгач, безнең автор кайбер вакытта үзе дә әсәрләнеп китә: аларның рухларында да үзләренчә «лиризм» һәм «шигърият» чаткылары таба иде («Алма агачлары чәчәк аткан-да», «Моң», «Җомга көн», «Өзелгән дога»).

Революциядән соңгы хикәяләрендә исә, без хәзер тыныч юморның ачы сатира белән алмашканын күрәбез һәм шулай булмый хәле дә юк; чөнки теге искергән, тузган типлар, актык көннәрен кичерә торган ул бәндәләр инде хәзер электәге төсле гади паразитлар гына түгел, бәлки Совет төзелешен төбеннән кимерә торган зарарлы паразитларга әверелгәннәр иде.

Г.Газизнең әдәби иҗаты бары тик көлкеле, вак хикәяләр белән генә чикләнеп калмый, җитди тондагы иҗтимагый-психологик хикәяләргә дә аның кулы чит түгел.Ике революция арасында булып кичкән байтак санлы татар провокаторларының, шул кызганыч сатлык җаннарының рухи трагедияләренә багышланган «Олы ләгънәт» дигән хикәясе аның шул типтагы әсәрләренә мисал йөзеннән бу мәҗмугага кертелә. Аның басылган һәм басылмаган шундый тагын берничә хикәяләре бар.

Газизнең иҗаты – күпкырлы иҗат. Аның әсәрләре арасында шигъри яктан ифрат матур эшләнгән, тирән мәгънәле, шәрекъ тормышыннан алынган легенда тибындагы әсәрләрне дә очратабыз. Бу «легенда»ларга азыкны ул туп-туры үзенең хыялыннан таба. Бу типтагы әсәрләреннән электә язылганнарыннан «Легендалардан берсе», яңа һәм басылмаганнарыннан «Кызыл гөлләр ничек яратыла?» дигән

әйберләре монда кертелделәр. Аның диалоглы хикәя рәвешендә язылган «Өч юл»ын да шул катарга төзәргә ярый. Бу символик фәлсәфи әсәр гаять күтәренке рух, көчле тойгы белән язылган булып, нәкъ бер поэма формасын да бирә.

Г.Газизнең «Аң»да басылган хикәяләре 1919 нчы елда «Гасыр » ширкәте тарафыннан 10 табаклык бер мәҗмуга хәлендә басылып чыкканнар иде. Хәзерге мәҗмугага беренче мәҗмугадагы хикәяләреннән байтагы кергәне шикелле, революция дәверендә төрле журнал һәм җыентыкларда басылган әсәрләре һәм соңгы елларда язылып та, моңарчы матбугатта чыкмаган байтак хикәяләре өстәлде. Хикәяләр хронология тәртибе (элеккеләре басылган еллары, соңгы басылганнары язылган еллары) буенча тезелделәр. Шуңар күрә бу мәҗмугада хикәяләрне төркемләүдә мәүзугъ-тема ягы игътибарда тотылмады.

Г.Газиз хикәяләрен язганда ифрат тиз, ашыгыч (чын мәгънәсе белән 5-10 минутта) язып ташлый; һичбер вакыт соңыннан кайтып, бер язганын икенче тапкыр төзәтми һәм төзәтә алмый. Бу аның индивидуаль психологиясеннән килә торган бер момент. Шуңар күрә дә аның электә басылып чыккан хикәяләрендә редакцияләрнең игътибарсызлыгы аркасында төзәтелми калган байтак тел һәм өслүб кытыршылыклары китә иде. Авторның теләве белән бу басмада шундый әһәмиятсез кытыршылыкларның бетерелүенә дикъкать ителде.

Актык сүз итеп шуны әйтеп китәргә кирәк: Г.Газиз татар әдәбиятында кирәк мәүзугълары, кирәк өслүбе белән үзенә башка булып аерылып торган бер әдип булганга, ул һичшиксез безнең әдәбият тарихыбызда үзенә лаек урынны тотарга тиеш. Ни өчендер моңар кадәр киң катлау укучы массасының аны тануына, яратып укуына карамастан, кирәк тәнкыйтьчеләр, кирәк әдәбият тарихы өстендә эшләүчеләр тарафыннан булсын, аның тиешенчә тәкъдир ителгәне, иҗатына бәя бирелгәне юк иде. Моннан соң бу игътибарсызлык бетәргә һәм бу оригиналь талант татар әдәбияты табынында үзенә тамь хокуклы урын алырга тиеш дип беләбез.

1929

(Мәкаләнең кулъязмасы «Казан» милли-мәдәни үзәгендә саклана).

садыйк – турылыклы
хәдисә – вакыйга
тәгассеб – фанатизм
хифзы сыйххәт – гигиена
тәхриб итү – харап итү
истиһза – мыскыл итү
тамь – тулы, бөтен

Рашат Гайнанов

Хикәяче Г.Газиз һәм аның иҗаты

Безнең татар әдәбиятында күп еллар буе укучыга тәкъдим ителмәгән, ләкин милли әдәби мирасыбызга теге яки бу күләмдә үзеннән өлеш кертеп, аның үсеп бүгенге хәлгә килүенә сизелерлек булышлык иткән бер иш язучылар бар. Бөтен яктан камил матур чәчәк бәйләмен бары тик төп төсләрдән генә торган чәчәкләрдән, ягъни арадаш төсләр һәм төсмерләрдән башка гына күз алдына китереп булмаган кебек, әдәбиятыбызны да тарихта үзенә олы юл салып баручы берничә мәһабәт фигура белән генә, ягъни «икенче» һәм «өченче дәрәҗәле» язучылардан башка, бер бөтен итеп күз алдына китерү, табигый, кыен. Г.Тукай һәм М.Гафури белән С.Рәмиев һәм Дәрдмәнд арасында Нәҗип Думави, Сәгыйть Сүнчәләй, Габдулла Харис, Заһидә Гыйффәт тора бит әле. Алардан кала тагын Миргазиз Укмасый, Зариф Бәшири h. б. лар килә. Ф.Әмирхан һәм Г.Ибраһимов белән Г.Коләхмәтәв һәм Г.Камал тирәсендә Гали Рәхим, Солтан Рахманколый, Идрис Богданов, Шәһит Әхмәдиев, Хөсни Кәрим h.б. лар да бар. Ш.Камал, Ә.Такташ, М.Җәлил, К.Нәҗми, М.Галиләр кырыннан Афзал Таһиров, Кәрим Әмири, Заһидә Байчурина h.б. ларның үз сукмаклары сузыла.

Әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә безнең шактый ерактан ук килә торган сукмагыбыз бар. Риза Фәхретдинов, Җәмал Вәлиди, Гали Рәхим, Габдрахман Сәгъди, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали h.б. ларны күрсәтергә мөмкин. Алар барысы бергә бүгенге көндә безнең кулда кыймәтле хәзинә булган тирән эчтәлекле, киң колачлы һәм таза әдәбиятыбызның кирпечләрен салышканнар, аны ике аякка бастыруда күп иҗат хезмәте куйганнар, камилләштерүдә булышканнар. Г.Газиз дә менә шундый язучыларыбызның берсе. Татар прозасының кыска хикәя жанрында ул үзенчәлекле урын били.

***

Г.Газизнең беренче әдәби әсәре – «Марс, уян!» исемле хикәясе 1907 нче елны «Казан мөхбире» газетасында басылып

чыга*. Символик алымда язылган бу хикәясендә яшь язучы эре империалистик дәүләтләрнең, икейөзләләнеп һәм төче телләнеп, 1907 нче елны Нидерландтагы Гаага шәһәрендә үткәрелгән конференциядә сугыш коралларын кыскарту, «мәңгелек тынычлык» урнаштыру турында фәлсәфә сатуларыннан, ә халык артында яңадан-яңа сугыш хәзерләүләреннән сатирик көлә. Хикәя үзенең нәкъ менә сатирик үткенлеге һәм актуальлеге белән укучыга ошый. Күп тә үтми, хикәя тәрҗемә ителеп, Казанда чыга торган рус газеталарының берсендә басыла. Шуннан соң аның көндәлек темаларга багышланган мәкалә һәм фельетоннары, яңа китапларга, спектакльләргә рецензияләре бер-бер артлы чыга тора. Аларның күбесе «Г.Г.», «Габделгазиз», «Г. Сәлман» һәм башка имзалар белән басыла.

Г.Газизнең үзе язган «Тәрҗемәи хәлендә» әйтүенчә, шулай ук тәнкыйтьче Гали Рәхимнең «Г.Газиз әсәрләре» исемле мәкаләсендә (кулъязма) раславынча, яшь язучы 1906-1913 нче еллар арасында күп кенә хикәяләр яза. «Ләкин аңарда бертөрле үз-үзенә ышанмый караучылык бар иде, – дип хәтеренә төшерә Г.Рәхим, – Ул язган хикәяләрен иптәшләр мәҗлесендә уку белән генә канәгатьләнә иде. Оригиналь әдәби өслүбенә, тормышны күзәтүдәге осталык һәм нечкәлегенә өстәмә буларак, тагы үз әсәрләрен артистларча оста һәм килештереп укый белү таланты да булганга, аның әсәрләре иптәшләре, дуслары тарафыннан бик зур интерес белән тыңлана, алкышлана һәм тәкъдир ителәдер иде. Шулай да ул, үзенең ул әйберләренә артык әһәмият бирмичә, бер каләм шаярту шикеллерәк итеп кенә караганлыктан, бастырырга артык омтылмый, аларны укыганнан соң, өстәл тартмасына ташлый бирә иде». Шулай итеп, бердән, Газиз үзенең иҗат җимешенә шулай «җиңелчә» караган булса, икенчедән, ул вакытта әле әдәби журналларның туып өлгермәгәнлеге, ә газеталарның хикәяләргә юк дәрәҗәсендә аз урын бирүе, күбесенчә әсәрләрнең үткен сатирик һәм юмористик планда булуы ошамавы нәтиҗәсендә язучының ул чор хикәяләре дөнья күрми.

1912 нче елның ахырында Казанда Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Рәхим h. б. тарафыннан оештырылган «Аң» журналы чыга башлый. Иптәшләре Г.Газизгә инде шактый җы-

---

* Чынлыкта, Г.Гобәйдуллинның бу хикәясе «Казан мөхбире» газетасының 1907 елгы 6 апрель санында «Чын төш» исеме белән басылган. Анда борынгы Рим мифларына аваздашлык бар һәм латин телендә «Mars, viqilla!» гыйбарәсе кулланылган. Күрәсең, шул гыйбарә Г.Гобәйдуллинның хәтерендә калган һәм ул Гали Рәхимгә язган бер хатында беренче хикәясенең исемен «Марс, уян!» дип күрсәткән. Әлеге ялгышлык Г.Гобәйдуллин иҗатына багышланган хезмәтләрдә дә шулай кабатланып килде.– *Төз. иск.*

елган хикәяләрен журналда бастырырга тәкъдим итәләр. Бу турыда Г.Рәхим болай дип яза: «Иптәшләренең кыставы белән ул үзенең басылуны көтеп яткан әреле-ваклы, тәмам булган һәм булмаган хисапсыз хикәяләре, әдәби этюдлары арасыннан сайлап-сайлап, «Аң» битләрендә бастыра башлады. Яңадан-яңа язылганнары да арага керә барды.

Г.Газизнең бер-ике битлек, иң күп дигәндә ун-унбер битлек хикәяләрен укыганда, «алар бик вак мәсьәләләргә багышланганнар түгелме, артык «бытовойлар» түгелме?» дигән кебегрәк сорау туа төсле. Чыннан да, менә аның, 1910 нчы елны язылган «Исерек» исемле ике битлек хикәясе.

Болай караганда язучы исерекнең портретын мәзәк өчен генә бирә кебек. Саран, ләкин төгәл һәм оста сызыклар белән исерекне бөтен кыланышлары, килеш-килбәтләре белән коеп куя. Бу типны моннан да оста биреп булмас дип уйлыйсың! Әмма эш анда гына түгел, – укучы алдына тигезлексез иске җәмгыятьнең, ярлылыктан, кызыксыз, ачлы-туклы тормыштан үзен исереклек пәрдәсе белән яшереп юанырга, кайгы-хәсрәтен аракы белән басарга күнеккән типик бер шәхес килеп баса. Дәмин ни өчен әчә? Вакытын, акчасын кая куярга белмиме? Байлыгына чыдаша алмыймы? Һич тә алай түгел. Үзенең әчүе турында исерек баштан бик аек фәлсәфә сатып, Дәмин болай ди: «Мин бу әчүдән бик туйдым инде, менә, валлаһи, ташлар идем, билләһи... Бит бер файда да юк... Юк, ташламыйм, тагы уйлыйсың, ни хозур бар соң? Тагы нишләргә кирәк?...»

Нәкъ менә эшнең асылы да шунда: ни хозур бар дөньясында? «Иртәдән кичкә кадәр» бил бөгеп кәвеш тек! Ә шулай да «шәһәрнең җәһәннәм асларындагы урамында ике бүлмәдә ике гаилә тора торган фатир«ында хатының һәм балаң «иртәгә икмәккә акча юк» дип, тилмереп утырсын! «Хәзер ягарга бер нәрсәң» дә булмасын! «Ни хозур бар соң?!»

Капиталистик җәмгыять, аны идарә итүчеләр адресына ачы сүзләр әйтелмәгән булса да, язучының бу кечкенә әсәре үзенең художество көче белән укучыда үз кул көче белән көн күрүче түбән катлауны кызгану, аңа теләктәшлек итү хисләре тудырмый калмый. Шул ук вакытта: «Нигә болай соң?» дигән сорауны куеп, аңа җавап эзләргә мәҗбүр итә.

Г.Газизнең иҗаты критик реализм юнәлешендә үсә. Ул русның атаклы язучысы Антон Павлович Чехов әсәрләрен яшьли үк бик яратып укый торган була. Һәм нәкъ менә Чехов йогынтысында яза башлый. Аның тәүге әсәрләреннән үк чынбарлыкны, кешеләрне һәм табигатьне дөрес чагылдырырга, кыскалыкка, гадилеккә һәм төгәл сурәтләүгә омтылганын күрәбез.

Язучы егерменче йөз башы татар тормышындагы тискәре якларны тәнкыйть итә. Җәмгыятьтә булып тора торган зур вакыйгаларда алыш-бирешe булмаган, үзеннән, үзенең тар бер тирәлегеннән башка бернине дә күрмәгән һәм күрергә дә теләмәгән, үзенең вак дөньясында казынып яткан обывательләр, фанатик-динчеләр, мулла-мунтагай, тиенләп табыш алу кайгысы белән күзе тонган вак сәүдәгәрләр – менә Г.Газиз әсәрләренең геройлары. «Урта халык» дип йөртелгән бу халыкның психологиясен язучы искиткеч яхшы белә һәм укучының күз алдына аны бөтен кайгы-хәсрәте, шатлыгы-куанычы белән, уй-фикере һәм омтылышы-талпынышы белән китереп бастыра.

Менә «Җомга көн» хикәясе. Галим хаҗи җомга көнне, күптән үлгән элекке хатынының каберенә аны искә алырга бара. Ахирәт турындагы уйлардан аның күңеле шулкадәр нечкәргән ки, ул хәтта чыжлап агач башыннан очып киткән каргага да сәлам биреп, «әссәламегаләйкем, әй, изге җирләрдән килгән мәхлук!» – дип кала. Әмма хатынының кабере янына гына яңа бер кабер казылганың, анда ир-ат күмеләсен белгәч, хаҗиның күңелендәге дини хисләр, ахирәт хисләре бердән оча. Аңарда хәзер «нәмәхрәмгә» дошманлык уты ялкынлана. Язучы, бер яктан, хаҗиның дини фанатиклыгыннан көлсә, икенче яктан, аның хатын-кызга чын карашын да бик ачык күрсәтә.

Автор, бик оста итеп, күңелсез социаль күренешкә дә ымлап китә. «Җомга көн» хикәясендә, мәсәлән, мондый бер урын бар:

«Әкрен-әкрен янә зиратка рәван булды.

– Бабай, бер тиен! Ятим бала идем... Атам юк...

– Менә карагыз, кулым юк... ашарыма юк... шәфкать...

– Рәхмәт, морадыгызны бирсен...

– Галим абзый, миңа да, миңа да! Ятим идем... – дигән тавышларны зиратка килеп керүгә карга тавышлары алыштырды.

Галим хаҗи бер-ике хәерчегә сәдака бирде дә, башкасына илтифат итмичә, ишетмәгәнгә салынып, зияратның тимер капкасын ачып, әчкә таба юнәлде...»

«Хәзрәт икегә бүлә», «Тирләргә килгән» һ. б. күп кенә хикәяләрендә Г.Газиз җәмгыятькә бер генә дә файдасы булмаган, юкны уйлап һәм юкны сөйләп көн үткәрүче паразит типларны сурәтли.

1912 нче елны Г.Газиз чагыштырмача зуррак әсәре булган «Олуг ләгънәт» хикәясен яза. Ләкин аны, язучы үзе әйткәнчә, «цензура аркасында хөррияткә кадәр матбугатка чыгара алмый». Ул тик 1917 нче елны гына «Аң» журналында басылып чыга.

Хикәядә шәһәр мәктәбендә тарих укытучы бер мөгаллим алына. Ул үз эшен сөйгән кеше, тарих буенча китаплар да яза. әмма ишле гаиләсен мөгаллимлектән килгән эш хакы белән чак туйдырып бара. Шулай да, ул шушы тормышыннан риза. Менә бервакыт аны жандарм башлыгы чакыртып, доносчы-провокатор булырга өнди. Әмма Әхмәт моны кире кага. Ләкин жандарм башлыгы, хәзер үк кулга алу белән куркытып, мөгаллимне үз ихтыярына буйсындыруга ирешә. Шулай итеп, Әхмәт провокатор булып китә. Аңа үзен бөтен җирдә ләгънәтлиләрдер, «Әнә ул – провокатор!» дип бармак төртеп күрсәтәләрдер шикелле тоела. Бер яктан, ул жандарм башлыгына гаепсез кешеләр өстеннән донослар ташыса, икенче яктан, аны вөҗданы газаплый. Хикәянең буеннан-буена Әхмәтнең вөҗдан газабында януы сурәтләнә. Моңа түзә алмыйча, ул акылдан шашу дәрәҗәсенә җитә, докторлар кушуы буенча авылга ял итәргә китә. Ләкин вөҗдан газабы аны эзәрлекләвендә дәвам итә. Нинаять, Әхмәт асылынып үлә.

1905-1907 нче елгы революция чорында кызылланып йөргән, революция җиңелеп, кара реакция башлангач, революцион идеаллардан ваз кичкән, патша хөкүмәтенең котырынуыннан, көрәшчеләрне аямавыннан коты очып, үз шәхесе иминлеген саклап калу өчен вөҗданын да, көрәштәш иптәшләрен дә саткан мөртәтләр аз булмады. Әхмәт образында без нәкъ менә шундый типларның берсен күрәбез. Әхмәт тә беренче рус революциясе чорында, халыкның көчле агымына кушылып, аңлымы-аңсыз рәвештәме, азмы-күпме «активлык» күрсәткән. әмма андый эшләргә ул күптән инде кул селтәп, вафасыз «тыныч тормышка» күчкән. Әлбәттә, ул бер вакытта да революциянең утын-суын кичкән чын көрәшче булмаган: шуңа күрә дә ул жандарм башлыгы алдында бик тиз йомшап, тетрәп төшә дә.

Дөрес, тәкъдимне кабул итү-итмәү турында «уйлар өчен» жандарм начальнигы 12 сәгать вакыт биргәч, Әхмәт, аулак сыраханәләрнең берсенә кереп утырып, сыра кружкасы артында башыннан төрле уйлар кичерә: «Соң адәм (үз) шәхесе өчен генә тормаса, ни өчен бер кеше, көймә батканда тотынырга бер такта гына калгач, улын – үзенең яраткан улын – төртеп төшергән дә, үзе шуңар ябышып котылган? Ни өчен ул җәмгыять төзелгән? Шул шәхесләрнең рәхәт яшәүләре өчен түгелме? Әгәр шул шәхесләргә каршы килсә, ник аңар хезмәт итәргә?» Әйе, чыннан да, ни өчен ул җәмгыять төзелгән? Әлбәттә, шәхесләрнең, шушы җәмгыять әгъзаларының рәхәт яшәүләрен тәэмин итү өчен! Ләкин капиталистик җәмгыять – берәүләр икенчеләрнең көченнән файдалануга, кешене кеше изүгә корылган җәмгыять – бу изге функцияне үти аламы? Әсәрнең герое Әхмәтнең фикерләре менә

шушы төп мәсьәләгә барып җитә алмый. Әйтергә кирәк, иҗатының бу чорында язучы үзе дә әле бу мәсьәләне анык кына чишә алмый. Шулай да Г. Газизнең аны көн тәртибенә куюы яхшы. Җәмгыять һәм аның функциясе турында Әхмәтне уйландыруы, аңардан фикер йөрттерүе укучыны да бу турыда уйландырырга, бу мөһим мәсьәләгә аның игътибарын юнәлдерергә мәҗбүр итә.

«Әгәр шул шәхесләргә каршы килсә, ник аңар хезмәт итәргә?» Әхмәт үз-үзенә шушы сорауны куя. Аның бу соравы шул ук вакытта үзен борчыган уй-фикерләренә җавап та булып тора. Шәхесләргә каршы килгән җәмгыятькә ник хезмәт итәргә?! Хезмәт итмәскә кирәк! Ә хезмәт итмәү нәрсә дигән сүз? Ул – я аңа каршы китәргә, аның белән көрәшергә, я булмаса аның золымнарына баш иеп, язмыштан узмыш юк дип, диңгез дулкыннары ихтыярында максатсыз чайкалган йомычка кебек, чайкалып гомер үткәрергә. Юк, Әхмәт тегесен дә, монысын да сайламый. Ул өченче бер юлны сайлый: «Юк, мин язам, язам! Барысын да күрсәтәм, барысын да әйтәм! Мин, һәммәсеннән дә югары күтәрелеп, аннан соң, көләрмен!» дип, ул донос язарга, провокатор булырга карар итә. Карарны үзенчә акларга да тырыша: «Бит әле язмасаң, минем балаларым ач калырга кирәк; аларны җәмгыять карармыни? Карар! Бер сынык икмәк тә бирмәсләр!» Шулай итеп, мөгаллим Әхмәт үз интересыннан чыгып, кешене бер телем икмәк белән дә тәэмин итә алмый торган, шәхеснең дошманы булган җәмгыятькә, ягъни «кеше – кешегә бүре» дигән законга нигезләнгән җәмгыятькә хезмәт итәргә, аның ялчысы булырга карар бирә, халкына, милләтенә хыянәт итә. Бөтен халыкның олуг ләгънәте менә шушы хаинга инде.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, Г.Газиз «халык» төшенчәсенә җәмгыятьнең барлык катлауларын да кертә. Провокатор Әхмәтне мәдрәсә салдырган бай да, җәдит мөгаллим дә, мулла да һәм шәкерт тә – барысы да ләгънәтли. Язучы җәмгыятьнең капма-каршы сыйныфлардан торуын төшенеп җитми, шул сәбәпле сыйныфлар көрәшен иҗатында да чагылдыра алмый. әсәрдән капиталистик җәмгыятьтә хәрәкәт итүче көч сыйныфлар көрәше түгел, бәлки яхшы кешеләр белән яман кешеләр арасындагы көрәш булып аңлашыла.

Әмма Г. Газизнең бу хикәясен язганда үз алдына куйган төп бурычы – провокаторның чиркәнеч тибын укучы күз алдына китереп бастырудан, аңа карата тирән нәфрәт уятудан гыйбарәт. Менә шул бурычын язучы уңышлы башкарып чыга. Г. Газиз Әхмәтнең психологик кичерешләрен оста тасвирлый, җәмәгатьчелектән, халыктан аерылып, хыянәтчелек сазлыгына баткан типның сынын килеш-килбәте, кыланыш-хәрәкәтләре белән күз ал-

дына китереп бастыра, укучыда андый хәшәрәт шәхесләргә карата көчле нәфрәт уята.

Галиәсгар Камал үзенең драма әсәрләрендә иске татар тормышындагы тискәре типларның бөтен бер галереясен биргән булса, Г.Газиз шундый ук тискәре типларны кыска хикәя жанрында күрсәтте. Голәмага акыл сатучы, «ил башы» надан муллалар, карый булырга, Коръәни хафиз булырга, атасы урынын алырга омтылучы сәләтсез һәм томана мәхдүмнәр, эшсезлектән бөтен гомерен талчоктан иске сәгать сатып алу һәм шуларда казыну белән үткәргән яки мөселманнар өчен «табиплар кушканча, мәшһүр, файдалы, форточкалы, сайрый торган кәләпүш» уйлап чыгару белән җенләнгән обыватель һәм вак һөнәрчеләр, «нич кирәкмәгәнгә ыңгырашып, бер дә юкка, әллә нәрсәгә рәнҗеп, атлаган саен сыкранып», гомере буе авыруга сабышып йөргән карчыклар, «әченнән, әллә кай җиреннән чалбарга аеруча дошман» булган кадим хәзрәтләр, вак сәүдәгәрләр, «зылылы»ланып йөрүче буржуа яшьләре, ягъни ялган интеллигентлар һ. б. лар җыентыкны укыганда бер-бер артлы укучы күз алдыннан үтәләр. Аларның барысы да оста юмористик һәм сатирик каләм белән язылганнар.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң Газиз Гобәйдуллинга үзенең сөйгән эшенә ныклап тотынырга мөмкинлек туа. «Бары тик Октябрь революциясе һәм Казанның чехлардан азат ителүе генә миңа аспирантурага кереп укырга, яраткан тарих фәнен тирәнтен өйрәнергә юл ачты», – ди ул үзенең автобиографиясендә.

Чиксез энергияле, өлгер характерлы Г.Газиз, вузда уку-укыту, шул ук вакытта зур фәнни тикшеренүләр алып бару белән бергә, совет оешмаларының эшендә дә җиң сызганып һәм актив катнаша.

Г. Газиз, шушы рәвешле бик зур эшләр алып баруына да карамастан, язучылык эшен дә ташламый, Киресенчә, аның иҗаты тагын да тирәнәя һәм актуальләшә бара. Хәзер инде язучы үзенең сатира угын һәртөрле юллар белән яшь Совет властена каршы көрәшүче эчке дошманнарга юнәлдерә.

«Әхмәтҗан абзый үзенең йортындагы подвалында, шәм яндырып, чыра пычак белән үзе казый, үзе яңа гына башак ашаган сыер төсле мышкылдый иде. Өстә кечкенә генә бер аяк авазы булды исә, шәмен сүндереп, сулышын кисеп, бер почмакка барып поса иде.

Күп азапланды ул. Нинаять, карчыгы Шәмси абыстай да түзмәде, идәнгә тезләнеп, подвалга башын тыгып карап:

– Менә билләһи, булмаган кеше соң инде син! – ди башлаган иде, Әхмәтҗан абзый тиз генә шәмен сүндерде дә:

– Һич таба алмыйм, кая соң әле монда кыярың? Чүлмәктәме, кисмәктәме? – дип сораган булды. Карчыкның ачуы тагын да кабарды:

– Кыланган булма инде шунда, кәмитшек күк! Мин ич монда... тизрәк бетер дим!

– Ә, ә, кем бар? Кыяр әзлим, кыяр! –диде Әхмәтҗан абзый».

1921 нче елны язылган «Күмгән иде» хикәясеннән китерелгән бу өзек советтан яшереп базга акча күмгән сәүдәгәрнең психологиясен Г. Газизнең саран гына сызыклар белән, ләкин оста һәм төгәл ачып бирүен күрсәтүче бер үрнәк була ала.

«Әхмәт байның тәһарәте» (1922), «Бу милләт ничек тәрәкъкый итсен!» (1919), «Фаҗигале төннәрдә» (1923), «Бер көтүнең тарихы» (1927), «Дәҗҗал көткәндә» (1928), «Ул мактанмыйдыр иде» (1928), «Кәрим абзыйның хыялы» (1929), «Әчке эмигрант» (1929) һәм башка хикәяләрендә дә язучы иске тормыштан «мирас» булып калган һәртөрле типларны сатира чыбыркысы белән камчылады.

Шулай ук ул, тәнкыйтьче Гали Рәхим белән берлектә, татар әдәбияты тарихында беренче мәртәбә буларак, «Татар әдәбияты тарихы»н (дәреслек-хрестоматия) төзи.

Кыска хикәя остасы Г. Газизнең якты иҗаты хәзерге көндә дә укучылар өчен кызыклы, файдалы һәм хикәячеләребезгә яхшы үрнәк була ала. Һәм ул татар әдәбияты тарихында үзенә лаеклы урынны алырга тиеш.

(Мәкалә «Г. Газиз. Хикәяләр.– Казан: Татар. китап нәшр., 1958.– 195 б.» китабыннан кыскартылып алынды).

Хәй Хисмәтуллин
Әдип, журналист, тарихчы

Газиз Гобәйдуллинның тормышка беренче тапкыр аяк басуын күрергә теләгән кеше Ф.Әмирханның «Яшьләр» пьесасын укып карарга тиеш, чөнки андагы газизләр, йосыфлар өчен Газиз Гобәйдуллин прототип була ала, ул да нәкъ шул чорда, сәүдәгәр семьясында туып, меңбәла белән гимназиядә имтихан биреп, зур түземлек, чиксез тырышлык, табигый сәләт ярдәмендә, Казан университетының тарих-филология факультетында тарих бүлеген тәмамлап чыга.

Яңа тормышка аяк басу аны шул заманның алдынгы кешеләре: Габдулла Тукай, Г.Коләхмәтев, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов һ.б. белән, шулар аркылы әдәбият белән якынлаштыра.

Шәһәр татар тормышының иң вак, иң нечкә, иң яшерен якларын белеп үскән, мещанлык тарлыгына иң тирән нәфрәт хисе саклаган бу талант үзенең каләмен шул мещан ваклыгына, мещанлык идиотизмына каршы юнәлдерде. Кыска гына хикәяләр-новеллаларда кечкенә бер штрих, вакыйга аркылы мещанлыкның иң вак детальләрен сатирик һәм юмористик алымнарда үткен тәнкыйть итә белүче Антон Павлович Чехов әсәрләре Газиз Гобәйдуллинның әдәби остазы булды, әлбәттә, ул А.П. Чеховны кабатламады, бәлки, остаздан алган белемне иҗади файдаланып, татар тормышын сурәтләде.

Газета битләре сыйдырмаганга күрә, бер-ике мисал белән чикләник.

Казан руханилары, мещаннары арасында чалбар балагын «чыгарып йөрү дөресме, түгелме?» дигән «мәсьәлә» күтәрелә, шау-шу китә. Бу инде безнең сатирикларыбыз, юмористларыбыз өчен азык була. Газиз Гобәйдуллин да моннан читтә калмый: «Чалбар» исемле юмористик новелла мәйданга килә.

«Яшьләр» пьесасындагы Газиз өстәл янында дәрес әзерләгәндә, кәләпүшен салып, яланбаш утыра, әтисе килеп керү белән, тиз генә аны алып кия. «Яланбаш йөрергә ярыймы, юкмы?» «мәсьәләсе» ул заманда бик шау-шулы иде. Яшьләр: «Кәләпүш

кисәң, баштан һава чыга алмый, шуңа күрә кәләпүш кию зарарлы», – дигән «дәлил»гә таяналар. Ә искелек яклылар: «Яланбаш йөрү кяфергә охшау була» – диләр. Кәләпүшчеләр «мәсьәлә»не үзләренчә чиштеләр: түбәсенә берничә тишек куйган кәләпүшләр әшләп чыгара башладылар. Бар, бәйләнеп кара! Газиз Гобәйдуллин бу көлкеле вакыйганы күрми кала алмый. Ул моңа «Фурточкалы кәләпүш» хикәясе белән җавап бирә...

Газиз Гобәйдуллинның бу елларда язган барлык хикәяләре дә татар тормышын кызыксындырган нинди дә булса бер мәсьәләгә багышлана. Шуңа күрә алар шул дәвер тормышын өйрәнү өчен ышанычлы чыганак та. Кайбер тәнкыйтьчеләр Газиз Гобәйдуллинның шундый «вак мәсьәләләр» белән мавыгуын яратып бетермәделәр. Ләкин бу дөрес түгел иде. Без социалистик революция ясадык. Хәзер коммунизмга барабыз. Әмма мещан ваклыгы, обывательлек, «мин-минлек» әле һаман бетеп җитми. Хәтта кайберәүләр шундый обывательлектән гыйбарәт булган күренешләрне «милли традиция» дип атарга да чамалыйлар. Шуңа күрә А.М.Горький иске тормышны яхшы белүчеләрне андагы мещанлык баткаклыгын фаш итәргә һәм аларны кыйнап бетерергә чакырды. Г.Гобәйдуллин хикәяләренең социаль әһәмияте дә, бер яктан, югарыда әйтелгәнчә, үз заманының тормыш-көнкүрешенең кайбер якларын, этнографиясен дөрес күрсәтүдә булса, икенчедән – мещанлык калдыкларын, кечкенә вакыйга аркылы көчле художество образлары тудырып, оста фаш итә белүдә, Гогольчә әйткәндә, ачы көлү, масхәрәләү аркылы аларны юк итәргә хезмәт итүдә.

Газиз Гобәйдуллинның күп кенә әсәрләре зур иҗтимагый-политик мәсьәләләрне күтәрә. Ул патша жандармериясенең кабәхәтлеген, алар тозагына эләккән кешеләрнең әчке рухи газаплануларын һәм халыкның андый кешеләргә мөнәсәбәтен дә күрсәтә һәм «кеше җәмгыятьтән читтә, жәмгыятькә, халыкка дошман булып яши алмый» дигән олы хакыйкатьне күрсәтә («Олуг ләгъәнәт»). Икенче бер әсәрендә ул: «Кеше ничек явыз язмыш кулыннан котыла ала соң?» дигән сорауга да жавап бирә. «Әгәр без, – ди иранлы бер карт, – дөньяда бәхет, дөньяда сәгадәт эзләсәк, үзебезнең авылларыбызны, басуларыбызны дошманнарыбызның каннары белән сугарырга кирәк... Шул заман безнең бакчаларыбызда да кып-кызыл гөлчәчәкләр үсәрләр, шул гөлчәчәкләр өстенә кунып, былбыллар сайрый башлар...» («Кызыл гөлләр ничек яратыла», 1929).

Бәхет өчен көрәшкә кирәкле көчнең кайдан киләсе дә әйтелә. «Кара, – диде карт, – күрдеңме? Төньяктан килгән бу рәхәт салкын жил диңгездә нинди көрәш тудырды. Шул яктан килгән

яңа фикерләр дә безгә мәңгелек тормыш суы бирәчәкләр». Иранның акыллы карты яшь, көчле, ләкин жәберләнгән егеткә шундый сүзләр сөйли. Иранга төньяктан килгән рәхәт һәм бәхетле тормыш бирәчәк жилнең нинди җил икәнен әйтеп тору артык.

Аз гына мисаллар дә, тормыштагы вак мәсьәләләрне да, зур социаль проблемаларны да әдипнең тирәнтен аңлавын, аларны художество әсәрләрендә яктырта белгәнен раслыйлар.

Мин Газиз Гобәйдуллин белән беренче тапкыр 1917 елның маенда очраштым. Урта буйлы, чандыр йөзле, җиңел йөрешле һәм хәрәкәтчән бу кеше беренче күрүдә үк үзенә мәхәббәт тудырды.

Октябрь социалистик революциясеннән соң ул атаклы профессор, бик күп гыйльми жәмгыятьләрнең члены, журналист, армый-талмый хезмәт итүче жәмәгать эшлеклесе булды. Аның гражданнар тарихы һәм әдәбият тарихы өлкәсендә дә хезмәтләре бар. Миңа аның тарих буенча сөйләгән күп кенә лекцияләрен тыңларга туры килде. Матур телле, тирән белемле лектор-педагог булып, ул хәзер дә күз алдында тора. Аның хәтере гаҗәп яхшы иде. Лекцияләрен бер чакта да нинди дә булса конспекттан яки дәфтәрдән карап укымый, туктаусыз сөйли, тарихның бик чуалчыклы вакыйгаларын, даталарын, кешеләрен хәтердән белә иде.

Ул безгә әдәби әсәрләр белән бергә, тарихи, иҗтимагый, әдәби темаларга татар, рус һәм азәрбайҗан телләрендә язылган күл санлы китапларын, аерым мәкаләләрен калдырды.

Талантлы галим, әдип, жәмәгать эшлеклесе Газиз ага Гобәйдуллинны бүген, тууына 75 ел тулган көндә без хөрмәт белән искә алабыз.

(«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1962.– 27 июнь).

Ибрагим Аитов*

Воспоминания о Г.С.Губайдуллине

В 1909-10 годах я учился в Казанском коммерческом училище в 4-5 классах, что равняется 6-7 классам современной десятилетки. Моими ближайшими друзьями по классу были Шайхулла Алкин, Гали Рахим и несколько русских учеников. Мы в классе составляли свою особую, маленькую дружную группу. Эту компанию связывали какие-то одинаковые интересы, необъяснимые симпатии, а нас троих еще и общая национальность. Бывали друг у друга на дому и иногда вместе готовились к весенним, переходным экзаменам, и совершали совместные поездки.

Оба моих друга часто упоминали имя Газиза абы, рассказывали о своих посещениях и отзывались о нем восторженно, рисуя его с глубокой симпатией и уважением, как замечательного, высоко и разносторонне образованного молодого человека, веселого собеседника и талантливого рассказчика. Я видел его на улице и знал в лицо. Оба моих друга стали уговаривать меня близко познакомиться с Газизом абы, посетить его на дому. Слыша такие уговоры, я заочно проникся к нему симпатией и уважением, меня потянуло к нему, но, будучи робким юношей, долго не решался на этот шаг. Наконец, преодолев свой стеснительный характер, я согласился, и мы с Шайхуллой в обусловленный день отправились к Губайдуллиным, которые жили от нас через два квартала.

Красивый каменный двухэтажный дом Губайдуллиных, не так давно построенный, находился в тихом переулке татарской части города. Комнаты были светлые, высокие, со вкусом оклеенные и убраны европейской мебелью. У каждого из двух братьев и у сестры Марьям апа, высокой, красивой девушки с черными волосами и мелкими пушинками над верхней губой, были отдельные комнаты. Она училась в высшем учебном заведении.

---

* Ибрагим Аитов – сын известного казанского купца и мецената Сулеймана Мухаметзяновича Аитова.– *Примечание составителей*.

В обширной комнате, занимаемой Газиз абы, у стен стояли шкафы с какими-то измерительными инструментами, черепом и многими хорошо переплетенными книгами на русском, татарском и арабском языках, которыми он владел в совершенстве. В шкафу находились еще книги на одном из западных языков.

Меня представили Газиз абы. Представ перед таким авторитетом, я вначале чувствовал себя сильно смущенным, с трудом боролся со своей робостью, наблюдал и молча слушал разговоры, пока одно небольшое событие не сняло мою скованность.

Оказалось, Газиз абы с воодушевлением занимался антропометрическими измерениями и сразу потребовал представить в его распоряжение мою голову для определения соответствующей группы. Не скажу, чтобы я охотно согласился на эту процедуру, ибо мне казалось, что такое измерение может обнаружить какие-нибудь дефекты в строении моего черепа и я потеряю его уважение. Но волей-неволей пришлось подчиниться. Череп мой был измерен в разных направлениях и полученные данные внесены в карточку. Как я упоминал, этот эпизод снял мою скованность и я почувствовал себя легко среди друзей.

Газиз абы оказался молодым человеком приятной наружности, невысокого роста, худощавый, несильного телосложения, с аскетическим лицом, с глазами на выкате, густыми бровями и пристальным, открыто и прямо смотрящим на собеседника взглядом.

Характер у него был мягким, доброжелательным. Говорил негромко, как-то задушевно, дружелюбно и держал себя просто, гостеприимно и искренне.

Происходил он из богатой татарской семьи с размеренным бытом, со строгими жизненными устоями. Казалось, в такой семье должны были родиться дети крепкие духом, с сильным телом, люди жизнеспособные, волевые. Только казалось, но не случилось. Младший брат Кадыр был тихим, болезненным, добрым, приятным человеком. Сестра Марьям отличалась крепким здоровьем, но оба рано сошли в могилу. Отец их, Салих абзы, среднего роста, плотного здорового сложения. Старик был старого закала, человек с узким взглядом, фанатизмом, любовью к стяжательству и в деле обогащения не разбиравшийся в средствах. Под духовным влиянием своих детей эти жесткие черты его характера со временем несколько сгладились.

В молодости Газиз абы очень любил шутить, смеяться, обладая богатым юмором, и был центром нашего товарищества. Слушать его было одно удовольствие, он был талантливым рассказчиком. Кроме того, он обладал и большим актерским талантом,

богатой мимической способностью, чему помогало его подвижное лицо. Он искусно передавал характерные жесты, мимику изображаемого им субъекта и нам трудно было удержаться от смеха, когда он, используя выразительные свои глаза, богатую мимику лица, отличную координацию движений, гибкого своего тела, стоя за столом и слегка нагнувшись над ним, изображал некоторые смешные, жалкие типы учителей и шакирдов старорежимного медресе, выхватив их из своего богатого запаса воспоминаний. Ему не трудно было это сделать, потому что он сам был долгие годы шакирдом в одном из худших дореформенных медресе «кадым», где даже употребление черных классных досок, как цвет шайтана, считалось греховным делом, а ученики сидели прямо на полу, обходились без парт.

Но мне неизвестно, чтобы Газиз абы принимал участие в любительских спектаклях, да и его остальные товарищи совершенно не участвовали в таких спектаклях. Эти представления, его живые рассказы и исторические темы возбуждали у нас интерес к литературе. Нас покоряло ощущение богатства его внутреннего мира, его яркая личность, глубокие знания, богатство передачи, эрудированность и логика.

Перлы своего духовного богатства, короткие, часто необыкновенно смешные, талантливые рассказики, он щедрой рукой рассыпал кругом. К сожалению, никто из нас не фотографировал их и не вел им учет.

Моя жена Шафика ханум вспоминает о посещениях Газизом абы дома ее отца Хади Максудова, редактора газеты «Юлдуз», известного татарского просветителя, по букварям и учебникам которого обучалась основная масса татарской молодежи, реформировавшего татарский алфавит, введя в него 6 гласных букв. Шафике ханум тогда было 12-13 лет, и она старалась во что бы то ни стало присутствовать при этих посещениях, находиться в комнате и слушать часами беседу отца с гостем, необыкновенно интересные и живые рассуждения и рассказы Газиза абы. Отец ее, следуя господствующей традиции, считал нежелательным присутствие девочки и часто удалял ее из компании. Но это не помогало, магнит оказывался слишком сильным, она опять проскальзывала в компанию слушать необыкновенно занимательного гостя.

У Газиз абы, как и у многих талантливых людей, были своего рода ребячества, чудачества. Он был большим охотником употреблять в беседе, бытуемые в простонародье терпкие, грубоватые выражения, поговорки, называл их «семейный сюз» и тем оправдываясь. Большой искусницей таких народных выражений

была моя бабушка Маудюдя, которая их привезла из г. Троицка на Урале, где она родилась, имела их неисчерпаемый запас и употребляла по всякому бытовому поводу и некоторые из этих выражений приводили своей терпкостью и меня, привыкшего к ним, в содрогание. Услышав эти сочные словца из уст такого великого интеллигента, да еще в кругу сестры я в начале был несколько шокирован. Очень сожалею, что в свое время не собрал этот своеобразный, оригинальный фольклорный материал, не записал их. Он бы составил толстую, сильно поисперченную, увлекательную книжку.

Газиз абы также любил пострелять, но я не помню, чтобы он приносил охотничью добычу.

Позже всех явился закадычный друг Газиза абы Кулахметов. Этого худого, высокого роста, необыкновенно привлекательного человека с ясным, лучистым взглядом я всегда встречал у Газиза абы. С партийной его работой я совершенно не знаком, а несколько знаю его лишь по быту. Встречи и беседы с этим замечательном человеком с кристально чистой душой, добрым сердцем, влияли на меня облагораживающим образом, и у меня осталось о нем самое светлое воспоминание, как о настоящем хорошем человеке.

Через пару лет после нашего знакомства Газиз абы организовал литературный кружок, куда входили Гали Рахим, Ш.Алкин, мой младший брат Юсуф, я и наш общий друг – гимназист Галимджан Шараф. В кружке делались доклады на литературные темы, читались авторские рассказы. Я в то время был сильно увлечен спортом, был неизменным посетителем катка, членом спортивного общества и особо активного участия в работе кружка не принимал. Наши собрания происходили на дому у Газиза абы или у нас, Аитовых. Мы изучали там литературу, произведения Ф.Амирхана, Тукая. Газиз абы делал доклады по истории татарской литературы, читал свои короткие рассказы, Гали Рахим и Ш.Алкин делали свои первые литературные пробы пера. По-видимому, эти занятия под руководством Газиза абы и заложили прочную основу будущей литературной и научной деятельности Гали Рахима, Ш.Алкина и Г.Шарафа.

Благодаря Газизу абы сохранились кое-какие выдержки из двухтомных мемуаров *in folio* моего дедушки Мухамметжана Аитова, широко используемых советскими историками. Газиз абы у меня брал эти рукописи для изучения и опубликовал выдержки из них в печати. Особенно широкое распространение получил эпизод, рисующий отношения татарского городского населения к Пугачеву, захватившему город Казань. К сожалению, эти книги,

хранимые мною в несгораемом шкафу, в мое отсутствие в Казани, примерно в 1930 годах, были увезены ГПУ со шкафом и уничтожены. Наши с Шагидом Ахмадиевым и Галимджаном Ибрагимовым совместные поиски этих ценных исторических рукописей не имели успеха.

Остался в памяти устроенный примерно в 1920-21 годах совместно с Газизом абы пикник. Газиз абы с женой, с малолетним сыном Салманом и я с женой в один жаркий, ясный, летний день сели на мою двухпарную лодку и решили прокатиться по озеру Кабан. На озере в те времена движение было небольшое. То там, то сям скользили парные, одиночные ялики, так называемые «московки», сработанные из узких тонких, деревянных планок, сшитых между собой медными заклепками или же грубо сколоченные, просмоленные дощаники.

Газиз абы сел за руль, а я – за весло и, вспомнив старину, былое участие на лодочных гонках, принимался иногда грести сильными рывками, от чего лодка делала скачок, а сидящих откидывало назад. Ну, конечно, такая танцующая езда никому не понравилась, меня быстро призвали к порядку и заставили вести ялик ровными взмахами весел.

День был жаркий, летний, ясный, лишь чуть заметный ветерок вызывал мелкую рябь, и скользить быстро по спокойной воде на легком ялике было одно удовольствие. С невысоких берегов озера на нас поглядывала старая деревянная Казань с одно- и двухэтажными домиками и кое-где с леском. Мы вспомнили о бытуемом среди татар предании о существовании кладов на дне озера, брошенных сотни лет назад населением, осажденным московским воинством Иоанна Грозного. Газиз абы рассказал о неосуществленных проектах извлечения этих ценностей со дна озера.

г. Ростов-на-Дону. Апрель 1962 г.
(Рукопись хранится в личном архиве С.Г. Губайдуллина).

Губайдулла Губайдуллин*

Воспоминания о профессоре Газизе Губайдуллине

1927 год. Мне 18 лет. Получил диплом об окончании кооперативного отделения Махачкалинского индустриально-экономического техникума. Надо было начинать самостоятельную жизнь, и я поехал в Баку устраиваться на работу.

На квартиру в Баку я устроился у земляка моего отца, в районе Шемахинской улицы. В этом районе города жило много татар, и там же находилась татарская школа-девятилетка. В этой школе я временно работал счетоводом.

В то время в Баку жили мой однофамилец – профессор Азербайджанского госуниверситета Газиз Губайдуллин с семьей и мой двоюродный дядя – доцент Педагогического института Наджиб Хальфин, который был женат на сестре Газиза Губайдуллина Марьям-апа. Она также преподавала в университете. Я часто бывал у них в квартирах. Семья профессора проживала по Коммунистической улице, рядом с Баксоветом. Как помню, в одной из комнат на столе стояла пишущая машинка. Печатал на машинке сам профессор. Он иногда прерывал прием пищи и, не закончив завтрак или ужин, переключался на печатание. При этом он, как правило, печатал не с рукописи, а сразу без черновика. Меня это очень удивляло, и я поражался его такой способности.

Однажды мне пришлось слушать популярную лекцию Газиза Губайдуллина на татарском языке в одном из клубов города на историческую тему. В то время популярные лекции научных работников практиковались довольно часто. Лекция была очень интересная и доходчивая слушателям. Помню, на лекции Екатерину II он назвал «Әби патша» (старая царица). В народе ее именно так и называли. Читая лекцию простым языком, без за-

* Губайдулла Губайдуллин (1909-1995) – сын известного уральского купца Садыка Губайдуллина.– *Прим. сост.*

писок, профессор быстро расположил к себе всю аудиторию. В конце лекции были даже бурные аплодисменты.

Профессор был очень вспыльчивым человеком. Иногда он повышал голос не только на домашних, но и на посторонних.

Многие научные работники Баку летом выезжали за город или в район Минеральных Вод. Летом 1928 года Газиз Губайдуллин и Наджиб Хальфин с семьями выехали в Ессентуки и Кисловодск. Ключи от обеих квартир они оставили мне. Целое лето я одновременно жил в двух квартирах. Правда, квартиру на Коммунистической улице я использовал рационально для занятий по физике с одним отстающим учеником татарской школы. Учитель физики Исмаил Наврузи получил на это разрешение от профессора. Мальчик был очень упрям и не выполнял домашних заданий. Я был вынужден для этой цели оставлять его после уроков у себя. Осенью мальчик сдал экзамены и был переведен в следующий класс. Исмаил Наврузи похвалил и ученика, и меня. О моих педагогических способностях он передал и профессору. На самом деле мои педагогические успехи были связаны со свободной квартирой и возможностью не отпускать упрямого ученика домой, пока он не выполнит домашнее задание.

В то время найти подходящую постоянную работу в городе было довольно трудно. Существовала Биржа труда. Наконец, один из бывших студентов Газиза Губайдуллина помог мне устроиться в Азербайджанскую государственную библиотеку на должность контролера. Здание библиотеки было очень красивое, построенное в восточном стиле. Народ называл это здание «Исмаилия». Я был очень горд, что работаю в таком здании, хотя получал небольшую зарплату.

– Доволен ли работой в библиотеке? – как-то спросил меня профессор.

– Да, доволен, за исключением зарплаты, – ответил я откровенно. Действительно, в то время библиотечные работники оплачивались плохо. Отсутствие возможности как-то улучшить свое материальное положение заставили меня покинуть Баку и возвратиться снова в Дагестан.

В январе 1929 года меня, как окончившего Махачкалинский индустриально-экономический техникум, Дагестанский Союз потребительских обществ направил в селение Араканы Хунзахского района Дагестана для работы в Араканском потребительском обществе. Там я работал ответственным счетоводом. В то время бухгалтером не принято было называть, должностей экономиста или плановика вообще не было. Должность ответственного счетовода в кооперативе считалась самой высокооплачивае-

мой. Я получал зарплату одинаковую с председателем правления кооператива. Мне дали там самую лучшую в ауле отдельную комнату.

Летом 1929 года я получил отпуск и поехал в Кисловодск, где тогда отдыхал Наджиб Хальфин с женой. В это же время в Ессентуках проводил лето Газиз Губайдуллин с семьей. Туда же к Губайдуллиным приехал из Казани известный татарский писатель Гали Рахим, написавший совместно с профессором Губайдуллиным «Историю татарской литературы» в двух томах (4-х книгах). По случаю приезда Гали Рахима профессор пригласил Хальфина с женой и меня в гости. Мы втроем пригородным поездом поехали в Ессентуки. По случаю нашего приезда в саду под деревом накрыли стол, вокруг которого мы все и расселись. Прежде всего, Газиз абы представил меня Гали Рахиму, сказав: «Этот молодой человек приехал из горного Дагестана и может рассказать нам много интересного. Думаю, что его нужно об этом попросить». Все согласились.

Вначале я очень смутился. Ведь мне 20-летнему юноше, впервые в жизни предстояло что-то рассказывать такой высокой аудитории. Но тут мне помог Газиз абы. Он попросил, чтобы я рассказывал о своей жизни и работе, но главное внимание в рассказе уделил быту, обычаям и языкам разных народностей, встреченных мною в районах Дагестана.

Я начал свой рассказ с того, что наше потребительское общество имело 8 магазинов в разных горных аулах, в том числе в ауле Гимры –родине имама Шамиля и в ауле Ципукуль – родине революционера Махача Дахадаева, чьим именем названа столица Дагестана. Далее я рассказывал о каждом из 8 аулов, более подробно останавливаясь на интересующих моих слушателей вопросах. Например, об ауле Араканы, где я в то время проживал и работал. Говорил примерно так. Моя комната располагалась на самом бойком месте – площади аула, где обычно собирались для бесед старики. Через эту площадь проходила дорога к знаменитому Араканскому ущелью и далее – на Буйнакск. Араканское ущелье известно тем, что в 1920 году там происходили жестокие бои между Красной Армией и белобандитами. Мимо моих окон по площади проходили женщины с кувшинами на плечах, направляясь к роднику и обратно. Аул Араканы, где находились правление кооператива и головной магазин, специализировался на выращивании абрикосов. Сады здесь располагались на террасах по склонам гор. Летом в ауле организовывали временное кустарное производство по варке абрикосового пюре. Готовое пюре упаковывалось в металлические 3-х килограммовые

банки и запаивались. Крестьяне сдавали абрикосы в приемный пункт. Рынка в ауле не было. Свежие абрикосы приходилось жителям часто везти и на рынок в Буйнакск. Расстояние от Араканов до Буйнакска по колесной дороге составляло около 40 км. При этом приходилось преодолевать 2-х километровый горный перевал по серпантинной дороге. Обычно ездили на фаэтоне, запряженном парой лошадей, или верхом по горным тропинкам. В пути следования встречались чаще мужчины, а также женщины-крестьянки в длинных шароварах, сверх которых обычно одевают платье. Чем ближе к Буйнакску, тем шаровары у женщин становились короче, местные шутники по этому признаку определяли оставшееся расстояние до города.

Примерно так я рассказывал о каждом ауле. По окончании рассказа мне задавали массу вопросов, на которые я старался отвечать по мере своих знаний. Марьям апа, как этнограф, интересовалась, в основном, вопросами, связанными с пищей, одеждой, обычаями, Гали Рахима и Газиз абы – языки кумыков и аварцев. Они даже попросили меня продемонстрировать произношение нескольких аварских слов. Я помню, как с характерным для аварцев щелканьем произнес слова «по», «киго», «лчабго», «ункчо», «шуго», «анлгго» и т.д. Также я сосчитал по-аварски от единицы до десяти.

Я был очень доволен встречей в Ессентуках.

Брата профессора, Кадыра Губайдуллина, на этой встрече не было. Я с ним встретился позднее. Долго он расспрашивал меня о жизни в Дагестане. Возможно, мои рассказы подействовали на него, так как он через несколько лет вместе с отцом, Салихом Губайдуллиным, переехал в Махач-Калу и работал там в Дагестанском государственном музее научным сотрудником.

Москва, 1987 г.
(Рукопись хранится в личном архиве С.Г. Губайдуллина).

Зариф Бәшири

[Газиз Гобәйдуллин турында]

... Тамбов һәм Пенза губерналарында ул чагында аз җирле вак алпавытлар шактый иде.

Фәхрелисламнар* авылына якын гына булган менә шундый алпавытлардан берсенең Маргарита исемле матур гына бер кызы була. Шул кыз белән Фәхрелислам яшьтән үк бер-берсенә мәхәббәт бәйлиләр.

Фәхрелисламның агасы Таһир мулла белән әнисе, мин барган саен, зарланалар иде:

– Табынды бит шул урыс кызына! – диләр.– Шуңа гына өйләнмәсә ярар иде! Сихерләде бит балабызны мәльгунә, кяфирә!

Мин китәр алдыннан алар зур шатлык белән шушы хәбәрне әйттеләр:

– Фәхрелислам Суфия Коләхмәтевага өйләнә икән,– диделәр.

Аларның моңа шатланулары Суфия туташның әйбәт, укымышлы, тотнаклы бер кыз булуы ягыннан түгел иде, әлбәттә. Алар шуңа шатланалар:

– Суфия татар, мөселман кызы... Кяфирә, мәльгунә түгел!..

Фәхрелислам яшереп тора алмады, серне ачып, төшендереп сөйләп бирде:

– Дөрес, – диде,– без Маргарита белән нык сөештек, аны онытуы миңа авыр, әлбәттә. Шулай да мин, агай-әне, дуслар белән киңәшә торгач, Суфия туташка өйләнергә булдым. Бу мәсьәләдә миңа нык тәэсир иткән кеше Газиз Гобәйдуллин булды. Аның Маргаритага өйләнүемә каршы булуы «кяфирә, мәльгунә» булуына карап түгел иде. Ул гаилә тормышы, бала-чага тәрбиясе, халык хезмәтләре ноктаи нәзарыннан чыгып үгетләде мине:

– Син ничаклы гына киң карашлы, хөр фикерле булма, һәрхәлдә, син – татар баласы,– диде.– Син татар тормышы, татар милли гадәтләре белән сугарылып үскән; син үзең тырышкан хәлдә дә әнә шул татарлыгыңны, татар гадәтен чыгарып ташлый

---

*Фәхрелислам Агиев (1887–1938) – язучы, журналист, 1913-16 елларда «Ак юл» исемле татар балалар журналының мөхәррире.– *Төз. иск.*

алмыйсың. Син һәрбер мәсьәләгә татар булып карыйсың, татар булу ягыннан чыгып эш итәсең, үз халкыңа татар баласы булып эшләргә омтыласың. Һәм шулай булганда гына, син үз халкыңа нәтиҗәле хезмәт итә аласың.

Менә бит син хәзер нинди шәрәфле бер эш артыннан – балалар өчен «Ак юл» журналын чыгарам дип йөрисең. Шөбһәсез, бер изге эш бит бу!.. Татар матбугат вә әдәбияты тарихында саф Идел буе татарлары телендә беренче тапкыр балалар журналын оештыру дигән сүз бит бу!.. Әйе, коры сүз генә дә түгел, татар матбугат вә әдәбияты тарихында масаюлы бер урын ала торган эш бит бу!..

Инде килик синең матур Маргаритаңа. Ничә әйтсәң дә, ул да шулай ук урыс кызы булып, урыс милли гадәте белән тәрбияләнеп, шуның белән сугарылып үскән. Нык ышанып әйтә алам: ул бөтен җаны, тәне, рухы белән урыс!.. Чөнки ул – иске урыслык горуры сөягенә сеңгән алпавыт кызы, аксөяк, барып чыккан аристократ! Ул бүген Фәхрелисламны ярата. Ләкин синең халкыңны – син сөйгән, син хезмәт итәргә теләгән татар халкын түгел!.. Ул синең сөйгән халкыңа, урыс аристократлары күзе белән «түбән бер хайван» дип карый. Шөбһәсез, синдә аз гына бер татарлык гадәте күрендеме, ул сиңа да иртәгә үк шулай итеп карый башлаячак. Менә мин сиңа бардым, ди. Без әлеге «Ак юл» журналы һәм аңа керәчәк нәрсәләр турында татарча сөйләшеп утырабыз. Ә ул инде шунда борын җыера да:

– Мин сезнең «каля-баля»гызны аңламыйм, минем алдымда урысча сөйләшегез!– ди. Шулай итеп, син үз гаиләндә үз милли мәсьәләң, үз милли мәдәниятең турында да үзеңчә сөйләшә алмыйсың!.. Шулай булдымы инде – гаиләндә җәнҗал, Маргарита мәхәббәте багана башына кунган йонга әйләнә... Аннары соң, менә шунысын гына да нык игътибарга алырга кирәк: авылда садә табигатькә өйрәнеп үскән, саф авыл егете белән аристократлык тәрбиясен алып үскән Маргарита арасында чын тату тормыш була алыр микән?! Мин әле урыс аристократларыннан чыккан Маргарита белән түгел, татар морза кызы Мәрьямнәр белән дә гади, садә тормыш төзүгә ышана алмыйм! Шуның өчен дә әйтәм: әгәр дә мин, университет бетереп чыгып, татар халкына хезмәт итәргә телим икән, өйләнү мәсьәләсенә килгәндә, шөбһәсез, әнә шул яктан карап эш итәчәкмен! Әгәр дә минем эш юлыма ярарлык гали белемле кыз табылмый икән, һич булмаганда, авылга кайтып, алача күлмәкле бер кыз алып киләчәкмен, һич булмаганда, әнә шуны тәрбия итәчәкмен!..

Фәхрелислам Агиев, Газиз Гобәйдуллинның шушы карашларын сөйләгәннән соң:

– Бай баласы булуына да карамастан, искитмәле демократ фикерле, гали табигатьле кеше ул,– дип куйды.

– Шуңа күрә дә Гафур Коләхмәтев белән дус булгандыр шул ул!.. Гафур агай: «Мохит юк түгел, аны таба белергә, табу юлын карарга кирәк!»– дип белми әйтмәгәндер!

Аннары соң шундый бер фикергә килдем:

– Газиз Гобәйдуллин, Гафур агай белән дуслашканчы демократ булганмы-юкмы, анысы икенче мәсьәлә. Ләкин, шунысы ачык, ул, Гафур агай тирәсендә булуы аркасында, демократлык тәэсирен алган.

***

Галимҗан [Ибраһимов] мине Газиз Гобәйдуллин белән таныштырды:

– Гафур Коләхмәтевнең якын дусты булганы шикелле, минем дә ышанычлы, якын дустым,– диде ул.– Бай баласы булса да, конфет суырып үскән байбәтчәләр катарына куярга ярамый аны, эчкерсез, интригалардан саф кеше!

Ул бу сүзләрен Газиз белән таныштырган вакытта, аның үзе алдында ук әйтте. Газиз әллә ничек кыенсынган, пошынган рәвештәрәк күренде.

– Туйдым инде шуңардан,– диде.– Килә дә бит шул «бай баласы» дигән сүз кысыла. Ничек итеп этине урам себерүче ясарга соң инде?!

Шушы танышудан соң мин Газиз Гобәйдуллинны еш кына очрата һәм аның белән утырыша торган булдым. Мөлаем, кечелекле, бер генә мәсьәләгә дә бай баласы булып түгел, ә табигате белән гади кешеләрчә каравы, шуның белән бергә уен-көлкеле сүзләрне эч катып көләрлек итеп оста сөйләве – кешене үзенә бик нык тарта, якынлаштыра иде. Аның Һади Максуди һәм аңа охшарга тырышкан Гариф Латыйпов булып кыланулары әле дә булса минем күз алдымда күңелле булып җанлана.

Газиз Гобәйдуллин Галимҗанны ничек яратса, Тукайны да шулай ук тәкъдир итә. Шунлыктан ул алар арасында килеп чыккан аңлашылмаучылыкка нык пошына.

1967

(Истәлекләр Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган автор кулъязмасыннан алынды.)

ноктаи нәзар – караш
гали – югары

Җан өшеткеч документ

